АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
имени ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА

Из сокровищницы научных экспедиций

# НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Татары Иркутской области*

КАЗАНЬ 2021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән

# МИЛЛИ-МӘДӘНИ МИРАСЫБЫЗ

*Иркутск өлкәсе татарлары*

КАЗАН 2021

УДК 398+811.512.145
ББК 82.3(2Рос.Тат)+81.2Тат
М 48

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла*

«Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау (2020–2024)»
ТР Дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә

**Редколлегия:**
***К.М. Миңнуллин*** *(рәис),*
***О.Р.Хисамов*** *(фәнни мөхәррир),* ***И. Г. Гомәров***

**Төзүче һәм җаваплы мөхәррир**
филология фәннәре докторы ***И. Г. Закирова***

**М48 Милли-мәдәни мирасыбыз: Иркутск өлкәсе татарлары.** – Казан, 2021. – 392 б. – (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән; Егерме беренче китап).
ISBN 978-5-93091-398-9

«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» дигән сериясендә дөнья күргән әлеге китап Иркутск өлкәсендә яшәүче милләттәшләребезнең тарихы, тормышы, рухи дөньясы турында мәгълүмат бирә. Китапта халыкның фольклоры, гореф-гадәтләре, йола поэзиясе һәм сәнгать дөньясы белән танышырга мөмкин. Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренең тикшеренүләренә нигезләнгән әлеге басма киң катлау укучыларда кызыксыну уятыр, дип ышанабыз.

**ISBN 978-5-93091-398-9**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2021

*Тел – уйлауның коралы, уйның – калыбы...*
*Миллият бинасының нигез ташларыннан*
*иң ныклысы – тел... Телнең эчендә халыкның рухы,*
*моңы, уй һәм тойгысы яшеренгән.*

Галимҗан Ибраһимов

*Язык – это инструмент мышления,*
*форма мысли… Самый прочный камень*
*в фундаменте бытия нации – язык… В языке*
*сокрыты душа народа, его мысли и чувства.*

Галимджан Ибрагимов

# КЕРЕШ

Һәр төбәкнең табигать тә, анда гомер сөрүче кешеләр дә, аларның ышанулары һәм дөньяга карашлары да йогынты ясый торган язмышы, йөзе, рухи үзәге-асылы бар. Шушы үзенчәлекне тою-аңлау өчен, әлеге төбәктә яшәү, һич булмаса, андагы тормышны өйрәнү һәм халык белән аралашу кирәк. Болар төбәкнең хәзерге хәл-халәтен күзалларга мөмкинлек бирә.

Үткән-тарих исә күпмедер күләмдә чыганакларда саклана; аларны археологик тикшеренүләр үткәреп тергезәләр; архив документларыннан һәм тарихи һәйкәлләрдән, ташъязмалардан эзлиләр. Археолог-галимнәр борынгы кешеләр турында мәгълүмат сакланган урыннарда разведка уздыра, казу эшләре оештыра һәм, табылдыкларга нигезләнеп, бик ерак тарих хакында төгәл мәгълүматлар бирә. Археологик тикшеренүләр вакытында эралар-чорлар да, шул заманнарда билгеле бер урында яшәгән кешеләрнең кайсы халыкка каравы, көнкүреше, һөнәрләре, нинди технологияләргә ия булуы, ышанулары да, күпмедер күләмдә зәвыгы, мәдәни казанышлары да ачыклана. Алар язма тарихи чыганаклар булмаган ерак заманнарны кабат күзалларга мөмкинлек тудыра, архив материаллары, документлар, эпиграфик һәйкәлләр һ.б. исә безгә якынрак чорлар хакында сөйли.

Алар да күрсәтә алмаган бик күп сәхифәләрне шәҗәрәләр һәм гаилә истәлекләре дә; төбәк кешеләре хәтерендә буыннан-буынга тапшырылып килгән мифлар һәм легендалар, җырлар һәм бәетләр дә; халыкның тел-сөйләм, әдәби фикерләү хасиятләре, көнкүреш һәм мәдәни үзенчәлекләре; матди һәм мәдәни кыйммәтләр дә үзендә саклый. Боларны күрә, аңлый, өйрәнә һәм аңлата белергә генә кирәк. Гаҗәеп күренеш: археологик һәм тарихи чыганакларда сакланмаган мәгълүматлар еш кына кешеләр хәтерендә, төбәкнең тормыш-көнкүрешендә яшәвен дәвам итә!

# ВВЕДЕНИЕ

У каждого региона есть свой неповторимый облик, своя судьба, особая духовная составляющая, которые формируются под влиянием местной природы, живущих там людей, их мировоззрения, привычек и верований. Чтобы понять и почувствовать это своеобразие, необходимо здесь пожить или хотя бы понаблюдать местное жизнеустройство и пообщаться с людьми. Только так можно получить представление о современном состоянии региона.

Страницы прошлого в какой-то степени раскрываются в исторических источниках, их восстанавливают посредством археологических исследований, находят в архивных документах и исторических памятниках. Ученые-археологи проводят исследования в местах, сохранивших следы пребывания древних людей, организуют раскопки и, опираясь на сделанные находки, способны представить точную информацию об очень далеких эпохах. Во время археологических изысканий выясняются возраст рассматриваемых объектов, принадлежность населения данной местности к тому или иному народу, особенности их повседневного быта, используемые технологии и ремесла, их верования, эстетические предпочтения и культурные достижения. Археологи дают возможность представить те далекие времена, о которых нет исторических источников.

Исторические источники (архивные материалы, документы, эпиграфические памятники и др.) рассказывают о ближайших к нам эпохах. Многие страницы истории, которые не получили отражение в источниках, сохранились в родословных, семейных преданиях; в передаваемых из поколения в поколение мифах и легендах, песнях и баитах, в специфике разговорной речи и литературного мышления; особенностях повседневной жизни и культуры; в материальных и культурных ценностях населения данного региона. Нужно только увидеть, понять, изучить и правильно интерпретировать эти явления.

Аларны төрле тармак галимнәре төбәкләргә экспедиция-сәфәрләр уздырып барлый, таба, өйрәнә... Аннары бу материаллар кабат халыкка кайта, шушы урынның, төбәкнең һәм бердәм татар милләтенең тарихи-мәдәни байлыгына әйләнеп яшәвен дәвам итә.

Татарстандагы академик фән, тарихи, археологик тикшеренүләр белән бергә, төбәкләргә чыгып, урыннарда халыкның яшәешен, көнкүрешен, матди һәм мәдәни хәл-халәтен өйрәнү белән һәрвакыт шөгыльләнә. Мондый тикшеренүләр XIX–XX гасыр чикләрендә үк аерым татар зыялылары инициативасы белән уздырыла башлый: бик күп татар җырларын, әкиятләрен, мәкальәйтемнәрен, миф-легендаларны язып алырга, татарларның телсөйләм үзенчәлекләрен ачыкларга ярдәм итә. Мәсәлән, К. Насыйри беренчеләрдән булып татар халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю, тарихи-этнографик тикшеренү эшен башлап җибәрә, 1871 елдан үзенең «Казан календаре»нда фольклор үрнәкләре бастыра. Бу эшкә Р.Ф. Фәхреддин, Г.Н. Әхмәрев, Х.Б. Бәдигый, Җ.Җ. Вәлиди һ.б. бик күп фикер ияләре кушыла.

XX гасырның аерым чорларында мондый тикшеренүләрне оештыруда активлык күзәтелә. 1920–1930 елларда – бигрәк тә Гыйльми үзәк эшчәнлеге белән бәйле махсус экспедицияләр фәнни нигездә уздырыла башлый. Н.И. Воробьев, А.С. Башкиров, Ф.И. Терегулов, М.С. Гобәйдуллина, К.С. Гобәйдуллин, С.Г. Вахиди һ.б. тарафыннан Арча, Әлки, Балык Бистәсе, Мамадыш, Минзәлә, Спас, Чаллы, Чистай төбәкләрендә шундый кыр тикшеренүләре үтә; аларда этнография, фольклор, сәнгать, тарихи-мәдәни мираска караган материаллар туплана.

Мондый эшчәнлек хәтта Бөек Ватан сугышы чорында да тукталмый. 1940–1980 елларда аерым тармак галимнәренең махсуслаштырылган экспедицияләргә чыгуы киң тарала. Бигрәк тә эпиграфик (Һ.В. Йосыпов), археографик һәйкәлләрне (С.Г. Вахиди, М.И. Әхмәтҗанов, М.Г. Госманов һ.б.), диалектларны (Л.Җ. Җәләй, Л.Т. Мәхмүтова, Н.Б. Борһанова, Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова һ.б.), төрки-татар фольклорын (Х.Х. Ярмөхәммәтов, И.Н. Надиров, Х.Ш. Мәхмүтов, Л.Ш. Җамалетдинов һ.б.) җыю-барлау максатыннан, Татарстанда һәм аннан читтә татарлар яшәгән авыл һәм шәһәрләрдә тикшеренүләр уздырыла. Экспедицияләрдә тупланган материал

Удивительно то, что материалы, не сохранившиеся в археологических и исторических источниках, часто продолжают жить в памяти людей, в повседневном жизненном пространстве населения данной местности! Ученые и специалисты в различных областях знаний во время экспедиций в регионы находят, собирают, изучают эти особенности… А затем эти материалы, после комплексного изучения, возвращаются к народу и продолжают жить, став частью общего историко-культурного наследия татарского народа и данного региона.

Академическая наука Татарстана, наряду с историческими и археологическими изысканиями, всегда держала в центре своего внимания изучение жизни, быта, особенностей материального и культурного состояния татарского народа, проживающего в том или ином регионе. Подобные исследования проводились во время экспедиционных выездов по инициативе представителей татарской интеллигенции, на рубеже XIX–XX веков было записано много татарских песен, сказок, пословиц и поговорок, мифов и легенд; зафиксированы местные особенности татарского языка и речи. Например, К. Насыри одним из первых начал собирать материалы по устному творчеству татарского народа и по исторической этнографии; с 1871 года он регулярно публиковал образцы фольклора в своем «Казанском календаре». К этой работе присоединились Р.Ф. Фахретдинов, Г.Н. Ахмеров, Х.Б. Бадиги, Дж.Дж. Валиди и другие представители татарской интеллигенции.

В отдельные периоды XX века наблюдалась особая активность в организации подобных исследований. В 1920–1930-е годы начинают проводиться специальные научные экспедиции, что было связано с деятельностью созданного Академического центра. Подобные полевые исследования осуществляли Н.И. Воробьев, А.С. Башкиров, Ф.И. Терегулов, М.С. Губайдуллина, К.С. Губайдуллин, С.Г. Вахиди и др. в Арском, Алькеевском, Рыбно-Слободском, Мамадышском, Мензелинском, Спасском, Челнинском, Чистопольском районах, собирая при этом материалы по этнографии, фольклору, искусству, историко-культурному наследию данных регионов.

Эта работа не прекращалась даже в годы Великой Отечественной войны. В 1940–1980-е годы широкое распространение получили специализированные экспедиции. В Татарстане и за его пределами, в местах компактного проживания татар, проводились исследова-

«Татар халык иҗаты» (1951, 1954), «Татар халык әкиятләре» (2 томда. 1946, 1956), «Татар халык җырлары» (1965), «Татар халык иҗаты», 12 томда (1976–1988), «Татар халык сөйләшләре» (2 томда. 2008), «Татар теленең диалектологик сүзлеге» (2009), «Татар халык сөйләшләренең атласы», «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» (1967) кебек фундаменталь хезмәтләр, мәдәният-сәнгать тарихы, милли һөнәрчелек, кульъязма һәм басма китап тарихы һ.б. өлкәләр буенча күпсанлы китаплар нигезендә ята.

XXI гасыр башында, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең системалы эшчәнлеге нәтиҗәсендә, бу эш яңа баскычка күтәрелә: һәр елны милләттәшләребез яшәгән төбәкләргә комплекслы экспедицияләр оештырыла башлый. Комплекслы рәвештә өйрәнгәндә, тел, әдәбият, фольклор, сәнгать юнәлешенең төбәк хәзинәсендә булган барлык төр байлыгы – буыннан-буынга тапшырыла килгән авыз иҗаты үрнәкләре, бәйрәмнәре, йола-гадәтләре, музыкасы, бәйләү-чигү кебек кул эшләре осталыгы, йорт-каралты бизәкләре, кием-салымы, тел үзенчәлекләре, эпиграфик һәм археографик мирасы – һәрберсе барлана-туплана һәм җентекләп анализлап бәяләнә. Татарстанда Актаныш (2009), Апас (2010), Кукмара (2011), Чүпрәле (2012), Мамадыш (2013), Арча, Әтнә (2016), Минзәлә, Мөслим (2017), Азнакай, Буа (2019) һәм 2021 елда яңадан Азнакай районнарындагы татар авыллары һәм поселокларында шундый кыр тикшеренүләре уза.

Татарстаннан читтә: Түбән Новгород, Курган, Оренбург өлкәләре (2010), Мари Илендәге Бәрәңге районы (2011), Удмуртия Республикасы (2012), Пермь краендагы Барда районы һәм Әстерхан өлкәсе (2013), Омск һәм Самара (2014), Оренбург һәм Томск (2015), Чиләбе өлкәләре, Казакъстан Республикасы (2016), Новосибирск өлкәсе, Башкортстан Республикасының Стәрлебаш районы (2017), Ульяновск (2017, 2018), Иркутск һәм Киров (2018), Пенза, Төмән өлкәләре, Үзбәкстан Республикасы (2019), Төмән өлкәсенең Саз ягы (2020), Төмән, Пенза өлкәләре, Кыргызстан Республикасы (2021) җирләрендә булып, анда яшәүче милләттәшләребезнең тел-сөйләш үзенчәлекләрен, тормыш-көнкүрешен, мәдәниятен, сәнгатен, кульъязма һәм ташъязма мирасын барлау, аларны фәнни эшкәртү, тикшерү эше җайга-системага салына.

ния по сбору эпиграфических (Х.В. Юсупов), археографических (С.Г. Вахидов, М.И. Ахметзянов, М.Г. Усманов и др.) памятников, изучению диалектов (Л.Дж. Заляй, Л.Т. Махмутова, Н.Б. Бурганова, Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова и др.), образцов тюрко-татарского фольклора (Х.Х. Ярмухаметов, И.Н. Надиров, Х.Ш. Махмутов, Л.Ш. Замалетдинов и др.). Собранные в экспедициях материалы легли в основу таких фундаментальных трудов, как «Татарское народное творчество» (1951, 1954), «Татарские народные сказки», в 2-х томах (1946, 1956), «Татарские народные песни» (1965), «Татарское народное творчество», в 12 томах (1976–1988), «Татарские народные говоры», в 2-х томах (2008), «Диалектологический словарь татарского языка» (2009), «Атлас говоров татарского народа», «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» (1967) и многочисленных книг по истории культуры и искусства, народных ремесел, истории татарской рукописной и печатной книги и др.

В начале XXI века, благодаря системным усилиям Академии наук Республики Татарстан, эта работа вышла на новый уровень: началась организация комплексных экспедиций в регионы проживания представителей татарского народа. В ходе комплексного изучения собираются, тщательно оцениваются и анализируются все богатства духовной сокровищницы региона: язык, литература, фольклор, искусство, то есть все то, что передавалось из поколения в поколение – образцы устного творчества, праздничные традиции, обрядовая культура, музыка, искусство вышивки, убранство домов, одежда, особенности языка, эпиграфическое и археографическое наследие. В Татарстане подобного рода полевые исследования были проведены в деревнях и селах Актанышского (2009), Апастовского (2010), Кукморского (2011), Дрожжановского (2012), Мамадышского (2013), Арского, Атнинского (2016), Мензелинского, Муслюмовского (2017), Азнакаевского, Буинского (2019), Азнакаевского (2021) районов.

За пределами Татарстана также налажена системная работа по сбору, научной обработке, изучению особенностей говоров, повседневного быта, культуры, искусства, рукописного и эпиграфического наследия татар, проживающих в Нижегородской, Курганской, Оренбургской областях (2010), Параньгинском районе Марий Эл (2011), Удмуртской республике (2012), Бардымском районе Пермского края и Астраханской области (2013), Омской и Самарской (2014), Орен-

Экспедициядә җыйган материалларны тикшерү, өйрәнү, фәнни әйләнешкә кертү белән бергә, шушы вакыттан Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивында 1940–2000 елларда шул ук төбәкләргә, авылларга уздырылган экспедиция материалларын барлау, яңа кайткан мәгълүматлар белән чагыштыру башкарыла. Шул җирлектә фәнни хезмәтләр әзерләнә. Әйтик, бүген инде галимнәребез «Татар халык иҗаты»ның 25 томлыгын төгәлләү алдында тора.

Элегрәк җыелган һәм яңа гына алып кайтылган материалларны бергә туплау «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә «Милли-мәдәни мирасыбыз» гомуми исеме астында фәнни-популяр китаплар әзерләү эшен башлап җибәрергә этәргеч була. Бу эшнең максаты – халыкның рухи байлыгын үзенә кайтару, аны популярлаштыру, тарихка кертеп калдыру, шушы мәгълүматлар ярдәмендә татар халкының милли үзаңын ныгыту.

Бүген инде бу сериядә 21 китап дөнья күрде, яңаларын әзерләү дәвам итә. Китапларда экспедиция үткән һәр төбәкнең мәдәни тарихы, танылган нәселләр, авыллар-шәһәрләрнең үткәне, гореф-гадәтләре һәм тел үзенчәлекләре төрле яктан яктыртыла. Шулай ук шәҗәрәләр, җирле кул осталарының эш үрнәкләре, кызыклы экспонатлар турында бай мәгълүмат бирелә.

Татар халкының рухи асылын, тарихи-мәдәни сыйфатбилгеләрен бербөтен итеп күзаллау һәм тергезүнең иң нәтиҗәле һәм ышанычлы ысулы булып фәнни экспедицияләр, кыр тикшеренүләре тора. Чөнки бу яшәеш бик борынгыдан килә, татар халкы Евразиянең гаять киң территориясендә формалашкан! Төрле табигый, тарихи, конфессиональ шартларда, төрле этник тирәлектә (төрки халыкларның төрле төркемнәре, фин, угор, славян этнослары янәшәсендә) татарларның этнотерриториаль (Идел-Урал буе, Себер, Әстерхан татарлары), субэтник (Казан, Касыйм татарлары, мишәрләр), субконфессиональ (керәшеннәр, иштәкләр, нагайбәкләр) төркемнәре барлыкка килгән. Бу төркемнәр, кайда яшәвенә карамастан, гомумтатар милли үзаңына ия. Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты уздыра торган экспедицияләр материаллары нәкъ шул хакта сөйли, һәр сәфәр шушы фикерне куәтли.

бургской и Томской (2015), Челябинской областях и Республике Казахстан (2016), Новосибирской области и Стерлибашевском районе Республики Башкортостан (2017), Ульяновской (2017, 2018), Иркутской и Кировской областях (2018), Пензенской, Тюменской областях и Республике Узбекистан (2019), Тюменской (2020), Пензенской и Тюменской областях и Республике Киргизия (2021).

Наряду с исследованием, изучением и введением в научный оборот материалов, найденных в экспедициях, ведется работа по сопоставлению новых сведений с материалами, которые были собраны в этих местах ранее – в 1940–2000-х годах и хранятся сейчас в архиве ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. На их основе готовятся серьезные научные труды. К слову, на сегодняшний день завершается работа над фундаментальным 25-томным сводом «Татарское народное творчество».

Проведенные исследования на основе объединения всего комплекса собранных материалов позволили начать работу по подготовке научно-популярных книг под общим названием «Национально-культурное наследие» из серии «Из сокровищницы научных экспедиций». Возвращение народу духовного наследия, популяризация и сохранение его в анналах истории способствует укреплению национального самосознания татарского народа.

На сегодняшний день увидели свет 20 книг из этой серии, продолжается подготовка новых. В книгах представлены обширные сведения по истории региона, прошлом известных татарских родов, деревень и городов, а также об обычаях, традициях и языковых особенностях татар. Вместе с тем в книгах дается богатая информация о родословных, работах местных умельцев и других интересных экспонатах.

Единственно надежным и достоверным способом составления общего представления о духовных основах и историко-культурных особенностях татарского народа является организация научных экспедиций и полевых исследований. Это связано с тем, что образ жизни татар формировался с древних времен и на очень обширной территории Евразии. Различные этнотерриториальные (татары Волго-Уральского региона, сибирские, астраханские татары), субэтнические (казанские, касимовские татары, мишары), субконфессиональные (кряшены, иштяки, нагайбаки) группы татар сформировались

Әлбәттә, уртак милли үзаңның нигезен татар теле тәшкил итә. Төрки телләрнең кыпчак төркеменә караган татар теле иң борынгы телләрдән санала. Татар теленең төп лексик, фонетик, грамматик үзенчәлекләре борынгы төрки телдә үк формалаша. Шуңа күрә дә дөньяның төрле кыйтгаларында яшәүче татарларның, төрле сөйләш вәкилләре булсалар да, тел-сөйләмнәре уртак лексик, фонетик, грамматик калыпларга-кануннарга нигезләнә. Шуңа күрә без борынгы рун язулы истәлекләрне укып, эчтәлегенә төшенә алабыз, казакъ, үзбәк, азәрбайҗан һ.б. төрки телләрне дә аңлыйбыз, татар теленең төрле диалектларында да зур аермалар сизмибез.

Татар милли әдәби теле исә XIX–XX гасырлар чигендә Казанда, Уфада, Оренбургта, Троицкида, Әстерханда һ.б. шәһәрләрдә һәм алар тирәсендәге авылларда гомумхалык теле булып оешып җитә. Тукай теле, Туфан теле, Еники теле – барыбыз өчен дә уртак байлык. Татар әдәби теленең үсеше барышында кайбер традицион хасиятләр һәм формалар югала, әмма алар сөйләшләрдә сакланып кала. Димәк, төрле урыннарда компактлы яшәгән татарларның сөйләшләре борынгы уртак телебезнең үзенчәлекләрен югалтмавы белән дә кадерле. Экспедицияләр материалы безгә шул хакта да сөйли.

Татарларның мәҗүси заман ышанулары, ислам дине белән бәйле күзаллаулары белән беррәттән, бүген дә халык арасында яши. Бигрәк тә безнең халкыбыз тарихында мең еллык урыны булган ислам диненең һәм матди, һәм мәдәни тормышка йогынтысы халыктан җыелган материалларда аермачык күренә. Каберташ язмалары, борынгы китаплар һәм кульязмалар, шәкерт дәфтәрләре, күчереп язылган текстлар, әдәп-әхлак кагыйдәләре, йола-гадәтләр, ышанулар һәм күзаллаулар, бәйрәмнәр һәм ырымнарда татар халкының барлык этник төркемнәре өчен уртак булган мәдәни мирас чагылыш таба. Ислам мәдәнияте гадәти көнкүреш һәм кеше тормышындагы иң мөһим вакыйгаларга (туу, исем кушу, өйләнү, гаилә, бакыйлыкка күчү) бәйле йолаларда этник мәдәнияткә үрелеп китә. Вакытны күрсәткән азан тавышы, намаз-догалар, җомга көнне бәйрәм дип карау белән бергә, татар халкының мәдәни хәтеренә бәетләр, мөнәҗәтләр, дини-суфичыл текстлар кереп урнаша. Традицион йолалар һәм бәйрәмнәр: Сабан туе, Җыен, Корбан гаете, Ураза гаете, өмәләр, Карга ботка-

в разнообразных природных, исторических, конфессиональных условиях и в сложном этническом окружении (рядом с разными группами тюркских народов, финно-угорскими, славянскими этносами). Несмотря на то, что данные группы татар проживают на различных территориях, они все объединены общетатарским национальным самосознанием. Каждая экспедиция ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ и собранные материалы неуклонно подтверждают это.

Разумеется, фундаментом общего национального самосознания является язык. Татарский язык, относящийся к кипчакской группе, считается одним из самых древних языков. Основные лексические, фонетические, грамматические особенности татарского языка сформировались уже в древнетюркском языке. Именно поэтому татар, проживающих в разных местах и являющихся представителями разных говоров, объединяет единая основа – общие лексические, фонетические, грамматические закономерности. Благодаря этому мы можем понять самые древние рунические письмена, понимаем казахский, узбекский, азербайджанский и другие языки, не ощущаем большой разницы между диалектами татарского языка.

Становление татарского литературного языка в качестве общенародного происходит на рубеже XIX–XX веков в городах Казань, Уфа, Оренбург, Троицк, Астрахань и др., а также окружающих их селах. Язык Тукая, язык Туфана, язык Еники – это наше общее богатство. В ходе развития татарского литературного языка теряются некоторые его традиционные свойства и формы, но они сохраняются в говорах. Поэтому говоры татар, компактно проживающих на разных территориях, ценны для нас сохранением особенностей нашего древнего общего языка. Материалы экспедиций говорят именно об этом.

В народе и сегодня продолжают сосуществовать древние домусульманские верования татар и представления, связанные с исламом. Материалы экспедиций особенно ярко демонстрируют влияние ислама на материальную и культурную жизнь нашего народа на протяжении его тысячелетней истории. Общее культурное наследие всех этнических групп татар ярко выражены в надгробных памятниках, древних книгах и рукописях, тетрадях шакирдов, списках литературных произведений, нравственно-этических нормах, обрядах и обычаях, представлениях и поверьях, праздниках и верованиях. В

лары һәм Яңгыр боткалары – болар да уртак байлыгыбыз һәм татарлыгыбызның аерылгысыз билгеләре.

Комплекслы экспедицияләр вакытында төрле җирлекләрдә кием-салым, һөнәрләр, азык-төлек әзерләү рәвеше, архитектура, музыка сәнгате буенча да күзәтүләр ясала. Әйтик, төрле җирләрдә яшәүчеләрнең киемнәрендә үзгәлекләр булса да, татарларның традицион гомуммилли өс киеме Казан татарларыныкы йогынтысында формалашкан дигән фикер безнең материаллар белән дә тагын бер тапкыр раслана. Татарлар кайда гына төпләнмәсен – мәчет торгыза. Халкыбызның һәрчак белемгә омтылышы, балалар тәрбияләүгә зур әһәмият бирүе, олыларга аерым бер хөрмәт белән каравы, туган җир һәм нәсел-ыруның һәр кешене саклаучы-яклаучы көч дип санавы, шигърияткә-иҗатка тартылуы да кыр тикшеренү нәтиҗәләрендә чагылыш таба.

Республикабыздагы күтәрелеш татар дөньясының җанлануына, милли үзаң уянуга, татарларның үзләрен бердәм халык итеп тоя башлавына китерде. Хәтта элек-электән туган җирләре, ватаннары бик еракта – әйтик, Польшада яки Литвада, Әстерханда яки Иранда, Уралда яки Себердә, Кытайда яки Финляндиядә булса да, уртак тарих, уртак мәдәният һәм Казан, Татарстан татарларны берләштереп торган үзәк булып кала.

Һәр милләт булып җитешкән бердәмлек төрле мәдәниятләрнең хасиятләрен үзенә туплый. Бу – аксиома. Көчле мәдәният үз тирәсенә башкаларны тарту сәләтенә ия. Алтын Урда чорында ук «татар казаны» күп кабиләләрне кайната, шул исәптән болгарларны да татар политонимына юнәлдерә.

Татар тарихы сикәлтәле, б.э.к. III гасырдан башлап язма истәлекләрдә эз калдыра. Шул ерак гасырлар чоңгылында Бөек кытай диварыннан төньяктарак төрки телле һуннарның империясе төзелә. II гасырда ул хәзерге Казакъстан далаларына күченә. Идел һәм Урал арасында угорлар белән укмаша, IV гасырда Европага юнәлә, халыкларның Бөек күчешен башлап җибәрә. Һуннарның нәсел тамгасы – казан – безнең башкалабыз Казанның да үзәгендә, Казансу буеннан милләттәшләребезне сәламли.

V гасырда Һун империясе таркала – Бөек кытай диварыннан Дунайга кадәр җирләрдә Бөек Төрки каганлык калкып чыга. Аның җимерелүеннән соң исә Болгар цивилизациясе чәчәк

моменты самых важных событий человеческой жизни (рождение, имянаречение, свадьба, семейная жизнь, похороны) традиции исламской культуры тесно переплетаются с обрядами этнической культуры. Наряду со звуками азана, по которым определяли время, с молитвами, с обычаем считать пятницу праздничным днем и т. д. в культурную память татарского народа вошли баиты, мунаджаты, религиозно-суфийские тексты. Наши традиционные обряды и праздники: Сабантуй, Джиен, Курбан байрам, Ураза байрам, коллективные помочи (өмә), обряды вызывания дождя и встречи весны – все это тоже наше общее наследие и то, что делает нас татарами.

Во время комплексных экспедиций в различные места проживания татар изучаются одежда, ремесла, традиции приготовления пищи, архитектура, музыкальное искусство и т. д. Например, наши материалы ещё раз подтвердили мысль о том, что, несмотря на некоторые различия в одежде татар разных регионов, очевидно, что традиционная национальная татарская одежда сформировалась под влиянием казанских татар. Где бы ни селились татары, они воздвигали мечети. Стремление народа к знаниям и просвещению, большое внимание, которое они уделяют воспитанию детей, особое уважение к пожилым, почитание родной земли и своего рода – как оберегающих и защищающих сил, склонность к поэтическому творчеству – все это отражается в материалах полевых исследований.

Разумеется, современная жизнь татар, где бы они ни жили, связана с Татарстаном. Общественный и духовный подъем в нашей республике способствовал оживлению татарского мира, пробуждению национального самосознания, осознанию татарами себя как единого народа. Даже для татар, чьей родиной давно является Польша или Литва, Астрахань или Иран, Урал или Сибирь, Китай или Финляндия, средоточием общей истории, общей культуры и единым связующим звеном остаются Казань и Татарстан.

Каждая общность, достигшая уровня нации, вбирает в себя свойства различных культур. Это – аксиома. Сильная культура обладает способностью консолидировать вокруг себя другие. В эпоху Золотой Орды в «татарском котле» перекипели многие племена, по той же причине название «булгары» стало татарским политонимом.

Перипетии татарской истории нашли отражение в письменных источниках, начиная с III века до нашей эры. В те далекие времена

ата. Көнчыгышта куәтле татар халкы үзенең дан-шөһрәтен яңгырата. Алтын Урда таркалгач, аның варислары ханлыклар төзи. Бүген алар касыйм, әстерхан, себер татарлары, мишәрләр, керәшеннәр, нагайбәкләр һ.б. атамалар белән исемләндереп йөртелгән төркемнәр буларак билгеле. Аларны бер тел, бер югары мәдәният – Мәрҗани фәһеме, Тукай шигырьләре, Сәйдәш музыкасы, Урманче сурәтләре берләштерә.

Татар асылын, аның рухи үзәген, татарлыкның гомуми һәм үзенчәлекле сыйфатларын аңлау-төшенү өчен, һичшиксез, тарихи барышны гына түгел, бәлки халыкның хәтерендә яшәгән рухи кыйммәтләрне дә барларга, өйрәнергә кирәк. Татарстан Фәннәр академиясе, аның институтлары, шул исәптән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре әлеге юнәлештә эшлиләр. Дөрес, татарлар элек-электән күпләп яшәгән барлык урынчылыклар да өйрәнелгән дияргә иртәрәк әле. Димәк, бу эш дәвам итәргә тиеш.

Фәнни күзлектән караганда, борынгы һәм бай тарихлы, үз әдәби теле, профессиональ әдәбияты һәм сәнгате булган бердәм татар милләте без. XX гасырда татар мәдәнияте, мәгариф һәм фән югары үсеш ала. Бу процесста төрле җирләрдә яшәгән, төрле этнографик төркемнәргә караган татарларның өлеше зур. Безнең көчебез – бердәмлектә!

**_Ким Миңнуллин,_**
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты директоры,*
*Татарстан Фәннәр академиясенең*
*мөхбир әгъзасы*

к северу от Великой китайской стены формируется тюркоязычная империя хуннов. Во II веке они переселяются в степи современного Казахстана. Сплотившись с уграми между Волгой и Уралом, они устремились в Европу, начав процесс Великого переселения народов. Неслучайно родовая тамга рода хуннов – казан – сегодня приветствует наших соотечественников на берегу реки Казанки в центре Казани.

В V веке Хуннская империя распадается, и на землях от Великой китайской стены и до Дуная возникает Великий Тюркский каганат. После его распада получает расцвет Булгарская цивилизация. Могучий татарский народ во весь голос заявляет о себе на востоке. После распада Золотой Орды её наследники создают отдельные ханства. Сегодня их потомки живут как касимовские, астраханские, сибирские татары, мишари, кряшены, нагайбаки и другие группы. Их объединяют общий язык, общая высокая культура – интеллект и разум Марджани, поэзия Тукая, музыка Сайдашева, творения Урманче.

Для понимания сути народа, его духовной сущности, общих и специфических особенностей татарства, безусловно, надо изучать не только историю, но и сохранившиеся в памяти народа духовные ценности. Академия наук Татарстана, её институты, в том числе ученые ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, работают в данном направлении. Естественно, ещё не все местности и регионы исторического проживания татар охвачены и изучены. Значит, эта работа должна продолжаться.

Если судить с научных позиций, то мы – единая татарская нация с древней и богатой историей, имеющая свой литературный язык, профессиональную литературу и искусство. В XX веке культура, просвещение и наука татарского народа достигли очень высокого уровня. В этом процессе незаменима роль татар, проживающих в разных регионах и представляющих различные этнографические группы. Ведь наша сила – в нашем единстве!

***Ким Миннуллин,***
*директор Института языка, литературы*
*и искусства имени Г. Ибрагимова,*
*член-корреспондент Академии наук*
*Республики Татарстан*

# СҮЗ БАШЫ

«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә дөнья күргән чираттагы китабыбыз Иркутск өлкәсендә яшәүче милләттәшләребезнең рухи мәдәниятенә багышлана.

Институт галимнәре 2018 елгы экспедиция вакытында Иркутск, Ангарск, Усолье-Сибирское, Шелехов шәһәрләрендә һәм Заларинск районының район үзәге Залари, шушы районга караган Троицк, Чирмешән, Сенная Пядь, Холмогой, Аларск районына кергән Кутулик поселогында, Шаховский һәм Новоселово авылларында, Бохан районының Хохорск, Усольск районының Биликтуй авылларында материал туплады. Галимнәр Иркутск өлкәсендә яшәүче милләттәшләребезнең тарихын, рухи мирасын, мәдәни кыйммәтләрен, сөйләм үзенчәлекләрен, тормыш-көнкүрешен, халык авыз иҗатын, мәдәниятен, сәнгатен, эпитафик истәлекләрен өйрәнде, кулъязма һәм гарәп язмалы китапларны барлады.

Иркутск өлкәсе татарлары, нигездә төрле чорларда күчеп килгән Казан татарларыннан тора. Алар арасында җир җитмәү сәбәпле барып урнашканнар да, ачлык елларында киткәннәр дә, Столыпин елларында күчерелгәннәр дә, каторгага җибәрелеп яшәп калучылар да бар. Иркутск якларына вербовка белән эшчеләр җибәрү XX гасырның 70 елларына кадәр дәвам итә. Югары белем алганнан соң юллама белән килгән яшь белгечләр арасында да татар кыз-егетләре була. Шул рәвешле, төрле сәбәпләр белән килеп чыккан халык бүген, берләшеп, тирә-яктагыларга дуслык, чисталык, тырышлык үрнәге булып тормыш кичерә. Кайсы гына авылда булсак та, информантларның иң беренче сүзе – авыл халкының дус-тату булуы, традицияләрне сак-лап яшәве.

# ПРЕДИСЛОВИЕ

Очередная книга из серии «Из сокровищниц научных экспедиций» посвящена духовной культуре татар, проживающих в Иркутской области.

Ученые института во время экспедиции 2018 года работали в городах Иркутске, Ангарске, Усолье-Сибирском, Шелехов, в поселке Залари, в селах Троицк, Черемшанка, Сенная Падь, Холмогой Заларинского района, в селах Кутулик, Шаховский и Новоселово Аларского района, в селе Хохорск Боханского района, селе Биликтуй Усольского района. Ученые изучали историю татар, проживающих в данном регионе, духовное наследие, культурные ценности, особенности быта, устное народное творчество, народные промыслы, искусство, эпитафии, рукописные и дореволюционные книги, изданные на арабской графики.

Татары Иркутской области состоят в основном из переселившихся в разное время и по разным причинам казанских татар. Среди них есть и переселившиеся из-за нехватки земли, и в голодные годы, и переселенные в столыпинские годы, и сосланные на каторгу. Вербовка и отправка рабочих в Иркутск продолжалась до 70-х годов XX века. Татарские девушки, юноши были и среди молодых специалистов, приехавших по направлению после получения высшего образования. Таким образом, татары, переселившиеся в Иркутскую область, сегодня живет примером дружбы, гостеприимства и трудолюбия  для других народов. В какой бы деревне мы ни находились, первым словом информантов было то, что жители деревни живут очень дружно, сохраняют традиции предков.

Основу этого издания, которое предлагается вашему вниманию, составляют материалы, собранные во время этой экспедиции. Это – устные предания, информация о традициях и обычаях,

Сезнең игътибарыгызга тәкъдим ителә торган бу басманың нигезен шушы экспедиция вакытында тупланган материаллар – Иркутск өлкәсендә гомер иткән татарлар хәтерендә сакланып калган көнкүреш йолалары, мәдәни ядкярләр, фольклор һәм тел турында әңгәмәләр, кульязма истәлекләр, аларны өйрәнеп язылган мәкаләләр тәшкил итә. Җыентыкта экспедиция вакытында төшерелгән фотосурәтләр дә урын алды.

Шул ук вакытта, Иркутск татарлары тарихын тулырак күзаллау өчен, аларга багышланган, әмма киң катлау укучыларга таныш түгел хезмәтләрдән дә өземтәләр бирәбез. Гаять кызыклы шәхес, Иркутск шәһәре меценатлары Шәфигуллиннарның замандашы Габдерәшит Ибраһимовның «Галәм-е Ислам» китабыннан китерелгән өзектә Иркутск мәчете, шул вакытта Габдерәшит Ибраһимов очрашкан кешеләр, муллалар, Иркутскиның татар мәктәпләре һәм каторжаннар тормышы турында мәгълүмат бар. Автор Шәйхулла Шәфигуллин белән очрашуы турында яза. Бу өзекне җыентык өчен филология фәннәре кандидаты Асия Рәхимова әзерләде.

Иркутск галиме Г. И. Бобкова хезмәтеннән алынган өзек тә татарларның XIX–XX гасырларда Байкал буйларына килеп урнашулары турында архив материалларына, ревизия кенәгәләренә һәм башка документаль чыганакларга нигезләнеп язылган. Галим татар авылларының кайдан һәм ничек килеп урнашулары, аларның шөгыльләре, мөселман общиналары турында кызыклы мәгълүматлар бирә.

Залари районының Туган якны өйрәнү музее директоры Бибигайшә Макогон мәкаләсендә Залари районы татар авыллары, халыкның бергә килеп төпләнүе, аерым гаиләләр тарихы, яшәү шартлары, тормыш-көнкүреше төрле яклап ачыла.

Җыентык экспедиция җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директорының фән эшләре буенча урынбасары Олег Хисамов һәм халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы Илсөяр Закированың Иркутск өлкәсе татарларының тарихына һәм күзәтү ясаган мәкаләсе белән башланып китә. Мәкалә

описания обрядов, быта, музыкальный фольклор, образцы устной речи. В издании также представлены фотографии, сделанные учеными во время комплексной экспедиции.

В сборник также включены посвященные татарам Иркутской области произведения, которые не известны широкому кругу читателей. В отрывке книги Габдрашита Ибрагимова «Дәүре галәм», современника меценатов города Иркутска Шафигуллиных, рассказывается об истории Иркутской мечети, о людях, с которыми Р. Ибрагимов встречался во время прибывания в Иркутске, о муллах, о татарских школах Иркутска и о жизни каторжан. Автор пишет о встрече с Шайхуллой Шафигуллиным. Этот отрывок для сборника подготовила кандидат филологических наук Асия Рахимова.

В монографии Иркутского ученого-историка Г. И. Бобковой «Татарские общины Иркутской губернии (конец XIX – начало XX вв.)» история татар, проживающих в Иркутской области, исследуется на основе архивных материалов, ревизских книг и других документальных источников. Ученый дает информацию о возникновении татарских деревень, о мусульманских общинах, о жизни татар. В отрывке из этой монографии исследуются возникновение и развитие этнически однородных татарских поселений на территории Иркутской губернии в конце XIX – начале XX вв.

В статье директора Краеведческого музея Заларинского района Бибигайши Макогон всесторонне раскрываются история татарских деревень, история отдельных семьи Заларинского района, условия жизни и быта населения.

Сборник, вобравший в себя богатый материал, открывается статьей руководителя экспедиции, кандидата филологических наук, заместителя директора Института по научной работе Олега Хисамова и главного научного сотрудника отдела народного творчества, доктора филологических наук Ильсеяр Закировой с обзора истории татар Иркутской области. Статья написана на основе анализа материалов, собранных во время экспедиции и данных, хранящихся в письменных источниках. В статье этих же авторов, написанной в соавторстве с заведующим Центром письменного и музыкального наследия Института, кандидатом филологических

экспедиция вакытында халыктан җыелган материалларны һәм язма чыганакларда сакланган мәгълүматларны анализлап язылган. Шушы ук авторларның Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире, филология фәннәре кандидаты Илһам Гомәров белән берлектә язылган мәкаләсендә Иркутск тарихында зур эз калдырган шәхес, иганәче Шәйхулла Шәфигуллинның тормышы һәм эшчәнлеге турында сүз бара. Авторлар әлегә кадәр укучыларга мәгълүм булмаган архив материалларын файдаланып, Шәфигуллиннарның тормышының билгесез якларын ачалар.

Илсөяр Закированың Иркутск өлкәсендә яшәүче милләтәшләребезнең фольклорына багышланган мәкаләсендә халыкның мифологик ышанулары, гореф-гадәтләре буенча мәгълүматлар бирелә, үрнәкләр китерелә. Автор халык хәтерендә сакланган легендаларны, гаилә-көнкүреш йолаларын, риваятьләр, мифологик хикәятләр, тыюлар, ышанулар, җыр үрнәкләрен туплаган. Мәкаләдә Иркутск өлкәсендә яшәүче татарларның халык иҗатына анализ ясала, аларның барлык регионнарда яшәгән милләттәшләребезнеке белән утак үзенчәлекләргә ия булуы күрсәтелә.

Диалектолог, филология фәннәре кандидаты Алинә Хөсәинованың халыкның тел үзенчәлекләрен күзәтүгә багышланган мәкаләләре, телчеләрдән тыш, халык өчен дә шактый кызыклы һәм мәгълүматлы булыр. Ул Иркутск өлкәсендә яшәүче халыкның тел үзенчәлекләрнә анализ ясый, аны этнолингвистик аспектта, халык традицияләренә нигезләнеп тикшерә. җирле сөйләш үзенчәлекләрен яктыртуга багышланган мәкаләсендә исә авыллар тарихы, гореф-гадәт, йолаларга караган этнолингвистик материалларны һәм кызыклы, үзенчәлекле лексик берәмлекләрне табарга мөмкин.

Сәнгать белгече, сәнгать фәннәре кандидаты Наталья Герасимова Иркутск өлкәсе татарларына хас кәсепләр, һөнәр төрләрен һәм аларның бүгенге көндәге торышын тикшерә. Экспедиция кул осталары белән очрашырга, аларның уникаль эшләрен өйрәнергә һәм теркәргә мөмкинлек бирде. Күп гаиләләрдә өлкән буыннан истәлек буларак саклана торган әйберләр дә бар. Бу – чигү

наук Ильхамом Гумеровым, рассказывается о жизни и деятельности человека, оставившего большой след в истории Иркутска, о меценате, купце первой гильдии Шайхуллы Шафигуллине. Авторы, используя архивные материалы, которые до сих пор неизвестны читателям, раскрывают неизвестные стороны жизни Шафигуллиных.

В статье Ильсеяр Закировой, посвященной народному творчеству татар, проживающих в Иркутской области, анализируются мифологические рассказы, верования, традиции и обычаи народа, приводятся примеры фольклорных произведений. Автором были зафиксированы сохранившиеся в народной памяти легенды, семейно-бытовые обряды, предания, запреты, поверья. В статье исследуется народное творчество татар, проживающих в Иркутской области, показано, что они имеют общие черты для татар, проживающих во всех регионах.

Статья диалектолога, кандидата филологических наук Алины Хусаиновой, посвящена изучению языковых особенностей населения и будет интересна и информативна не только для языковедов, но и для широкого круга читателей. Автор анализирует языковые особенности населения Иркутской области, исследует его в этнолингвистическом аспекте. В статье, посвященной особенностям местных говоров, можно найти этнолингвистический материал по истории, обычаям, традициям деревень и интересные, самобытные лексические единицы.

В своей статье кандидат искусствоведения Наталья Герасимова представила традиционные для татар Иркутской области промыслы, виды ремесел и их современное состояние. Экспедиции дала возможность встретиться с мастерами, увидеть и зафиксировать их уникальные работы. Есть вещи, которые хранятся бережно в семьях, как память о родителях, о старшем поколении. Эти работы – вышивки, национальная одежда, работы краснодеревщиков и т.д. передаются следующим поколениям и воспитывают гордость уникальными традициями народа. Статья дополнена фотографиями, где представлены образцы творчества мастеров.

үрнәкләре, милли кием-салым, агач эшләнмәләре һ.б., алар яшь буында халыкның уникаль традицияләре белән горурлану уята. Автор алтын куллы осталарның иҗат үрнәкләрен фоторәсемнәр белән тулыландырылган язма тәкъдим итә.

Фәнни сәяхәтебез көннәрендә халык музыкасы хәзинәләрен туплап өйрәнү белән музыка белгече, педагогика фәннәре кандидаты Найлә Нургаянова шөгыльләнде. Музыкаль фольклор буенча материаллар фәнни кыйммәткә ия һәм алар музыкаль татар фольклорының чыганак базасын тулыландыралар. «Иркутск өлкәсе татарларының полиэтник киңлек шартларында этномәдәни тәңгәллеген саклау формасы буларак музыкаль традицияләре» дигән мәкаләдә Иркутск якларында саклаган халык җырларының яңгыраш үзенчәлекләре анализлана.

Иркутск өлкәсе мәдәни мирасына элеккеге елларда да игътибар булган. 1971 елда халык иҗаты бүлеге фәнни хезмәткәрләре туплап кайткан материалның да бер өлеше китапта урын алды. Бу материаллар арасында тылсымлы һәм көнкүреш әкиятләре, борынгы җырлар, йола поэзиясенә караган үрнәкләр, ышанулар бар.

Бу сәфәр Иркутск өлкәсе җитәкчеләре, җирле администрация җитәкчеләре, халык белән очрашуларга бай булды.Ул як кешеләренең ачык йөзле, тәмле сүзле, кунакчыл булуы эшебезне җиңеләйтте, яңа материалларга баетты. Урман-сазлар арасында утрау булып утырган авылларның, тайга һәм Байкал күленең гаҗәеп аурасы энергия һәм көч бирделәр. Мәгълүмат җиткергән һәр кешегә, экспедициянең башыннан ахырынача безне озатып йөргән Фәгыйлә Хәсәновнага, Залари туган якны өйрәнү музее директоры Бибигайшә Кәлимулла кызына, Иркутск өлкәсе татар милли-мәдәни үзәге әгъзаларына олы рәхмәтебезне белдерәбез. Иркутск өлкәсенә уздырылган экспедиция татар авылларының матурлыгы, халыкның кунакчыллыгы һәм ачык күңелле булуы белән дә Институт галимнәренең күңелендә якты, матур тәэсирләр калдырды.

***Олег Хисамов,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фән эшләре буенча директор урынбасары.*

В ходе нашей научной экспедиции собиранием и изучением сокровищ народной музыки занималась музыковед, кандидат педагогических наук Найля Нургаянова. Материалы по музыкальному фольклору представляют особую научную и художественную ценность, они пополнили источниковую базу музыкального татарского фольклора. В статье «Музыкальные традиции как форма сохранения этнокультурной идентичности татар Иркутской области в условиях полиэтнического пространства» анализируются особенности звучания народных песен, сохранившихся в Иркутской области, исследуется песенное и танцевальное творчество.

Учеными Института духовному наследию татар Иркутской области уделялось внимание и в прежние годы. В книгу включен материал, собранный научными сотрудниками отдела народного творчества в 1971 году во время фольклорной экспедиции. Среди этих материалов есть волшебные и бытовые сказки, старинные песни, образцы обрядовой поэзии, верования.

Поездка была насыщена множеством встреч – с руководством Иркутской области, руководителями администрации населенных пунктов, с жителями. Радушие и гостеприимство жителей области облегчили ученым работу. Невероятная аура таежных деревень, тайги, Байкала, заряжали энергией и дарили силы. Выражаем огромную благодарность сопровождавшей нас от начала и до конца экспедиции Фагиле Хасановне, директору Залиринского Краеведческого музея Бибигайше Калимулловне, членам Иркутского областного татарского национально-культурного центра, и конечно, всем нашим информантам. Экспедиция в Иркутскую область оставила большое количество приятных впечатлений – не только от красоты татарской деревни с её размеренным бытом, но и от доброжелательности, открытости, гостеприимства местных жителей.

***Олег Хисамов,***
*заместитель директора по научной работе*
*Института языка, литературы и*
*искусства им. Г. Ибрагимова*
*Академии наук Республики Татарстан.*

# ИРКУТСК ТАТАРЛАРЫ ТАРИХЫ (2018 ЕЛГЫ ЭКСПЕДИЦИЯ МАТЕРИАЛЛАРЫ НИГЕЗЕНДӘ)

*Илсөяр Закирова*
*Олег Хисамов*

Иркутски Сибириянең бөек бер пайтәхете,
башкаласы дисәк тә ярый торгандыр.
*Габдерәшит Ибраһимов*

Байкал күленнән ерак түгел, Ангара елгасының ике ярына урнашкан Иркутск шәһәрен татарлар Өркет дип атыйлар. Бу атама хәзерге вакытта онытыла бара. Сүз уңаеннан, Ангараның да татарча Әнгәр дигән атамасы булганын искә төшереп китү дә урынлы булыр.

Иркутск шәһәрендә һәм бу өлкәнең төрле авылларында яшәүче татар халкының зур тарихы бар, өлкә тарихында лаеклы урыны, башка халыклар алдында ак йөзе, дәрәҗәсе бар. Иркутск татарларыннан рәссамнар да, язучылар да, галимнәр дә чыккан. Татар халкы тарихның һәр сәхифәсен язуда катнаша. Белемгә омтылыш, чисталык-пөхтәлек, ярдәмчеллек, уңганлык – халкыбызның шушы сыйфатлары биредә дә яхшы чагыла. Кайсы гына (кайвакыт берничә татар гаиләсе генә яшәгән) авылга барсак та, Бөек Ватан сугышында катнашучыларга куелган һәйкәл-обелискларда ил азатлыгы өчен көрәшүчеләр исемлегендә йөзләрчә татар фамилиясе язылган.

Иркутск шәһәрендә һәм шушы өлкәгә караган авылларда 2010 елгы Бөтенроссия халык санын алу (нәтиҗәләре буенча 22882 милләттәшебез көн күрә). Күпчелек халык Ангарск (2427 кеше), Братск (2011), Черемхово (1518), Иркутск (1499), Усолье-Сибирск (1260), Тайшет (878) шәһәрләрендә, Залари, Нукут, Чун, Осинск районнарында яшиләр.

Татарларның бу якларга күпләп килә башлавы XIX гасыр башларына карый. 1835 елгы халык санын алу мәгълүматлары буенча, Иркутскида 350 татар кешесе яшәгән. Иркутск татарларының Октябрь революциясенә кадәрге тарихы шушында туып үскән журналист һәм язучы, тарих фәннәре кандидаты Галия Ивановна Бобкова (1950–2011) тарафыннан өйрәнелә. Галия Бобкова үзенең XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында Иркутск губернасындагы татар общиналарын тикшерүгә багышланган монографиясенең[1] керешендә туган телгә булган мәхәббәтен аңлатып, «Кечкенәдән истә калган иң ягымлы сүзләр татар телендә иде. Бу телдә минем әни ягыннан әбием белән бабам сөйләште»[2], дип яза. Шунда ук ул әби-бабаларын, әти-әниләрен җылы сүзләр белән искә ала, алар турында язганнары монографиянең эчтәлеген ачуга хезмәт итә: «Томанлы гына булып моңсу җырга охшаган, мин аңламаган догаларның мәкамнәре искә төшә. Әтием офицер иде, шул сәбәпле безнең гаилә, еш кына бер гарнизоннан икенчесенә күчеп, хәрби шәһәрчекләрдә яшәде. Кайда гына яшәсәк тә, артыбыздан әбидән серле гарәп язулы хатлар килеп торды. Әти бу хатлар турында «чираттагы шифровка килде», дип шаярта иде. Еш кына әни янына таныш булмаган кешеләр, бигрәк тә хатын-кызлар килә иде. Алар татар телендә язылган хатларны, фотосурәтләр артындагы язмаларны, китапларны укып бирүне яки тәрҗемә итүне сорыйлар. Ул вакытта болар барысы да гадәти һәм табигый тоелган. Олыгайгач кына ярлы крестьян катламыннан булган, ятим үскән әбиемнең ике телдә – рус һәм татар телләрендә грамоталы булуы турында уйлана

---

[1] *Бобкова Г. И.* Татарские общины Иркутской губернии (конец XIX – начало XX в.): моногр. / Г. И. Бобкова. Иркутск: Изд-во Иркутского гос. ун-та, 2009. 219 с.

[2] *Бобкова Г. И.* С. 4.

башладым. Медицина институтын тәмамлап, врач булып эшләгән әнием татар язуының өч вариантын да – гарәп графикасын, латиницаны һәм кириллицаны яхшы белә иде. Болар берсе дә безнең гадәти аңыбызда формалашкан мескен надан мөселман хатын-кызы образына туры килми иде. Шул рәвешле, татар халкы тарихы белән кызыксыну башланды» [1]. Галия Бобкованың хезмәте беренче чиратта архив материалларына, татарлар тормышының аерым сәхифәләрен яктырткан документларга, ревизия документларына һәм башка документаль чыганакларга таянып язылган. Автор, татарлар яшәгән район-авылларга чыга, халык белән аралаша, китапта бу материаллар да урын алган. Бу хезмәт Иркутск татарлары тарихын өйрәнү өчен төп чыганак булып тора.

Г. И. Бобкова язуынча, Идел буеннан күченгән мөселманнарның Иркутск өязендәге беренче общиналары XIX гасыр урталарында гына барлыкка килә. Бу караш алдарак чорларга караган һәм татарлар турында мәгълүматны саклаган язма чыганакларның булмавы белән аңлатыла.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Иркутск өлкәсендә яшәүче татарларның рухи мәдәниятен өйрәнү максаты белән оештырылган комплекслы фәнни экспедициясе әгъзалары биредә яшәүче халык белән якыннан аралашты, архив-музейларда документларны өйрәнде, истәлекләрне тыңлады. Бу мәкаләдә экспедиция вакытында тупланган материаллар нигезендә, аларны башка чыганаклар белән чагыштырып, Иркутск татарлары тарихына, аларның үткәненә һәм бүгенгесенә күзәтү ясарга телибез.

Мәгълүм булганча, Идел буендагы корылык һәм ачлык елларында крестьяннар гаиләсе, нәсел-нәсәбе белән генә түгел, хәтта авылы-авылы белән Себергә күченәләр. Себер тимер юлы салына башлагач, татар халкының Себергә, шул исәптән Иркутск якларына күченүе тагын да җанланып китә. Тимер юл буйлап күп кенә татар авылларына нигез салына. Татарлар Сенная Падь, Залари, Усолье-Сибирское, Биликтуй, Тайшет, Алгаш, Зима,

---

[1] *Бобкова Г. И.* С. 4.

Алзамай, Колтоши, Тымбыр, Каракүл, Бланка, Голуметь, Тулун, Талый Ключ, Марга, Хингуй, Черемхово, Култук торак пунктларында яшиләр. Үзләре барып урнашканчы нигез салынган бу авылларны татарлар да шулай атап йөрткәнме, аларның татарча атамалары булганмы? Бу кадәресе билгеле түгел. Шулай да бу территорияләрдә төрки халыклар бик борынгыдан яшәгәнгә күрә, топонимнарның төрки телләрдән алынганнары да бар. Мәсәлән, Каракүл авылының исеме татарча яңгыраса, Биликтуй авылы *белек* – белем, язу, язма, гыйлем кебек мәгънәләрне аңлаткан борынгы төрки сүздән ясалган.

Информантлар рус телендәге атамаларга өйрәнгән, еш кына авыл исеменең татарчасын искә дә төшерә алмыйлар. Мәсәлән, Залари поселогында яшәүче Нәгыймә апа Вәлиева бик тырышса да: «*Синепядьның татарча исемен оныттым. Бар иде авылның исеме»*, – дию белән чикләнде.

Бу чорда халыкның төп шөгыле игенчелек була.

«Аграр мәсьәләләрне» хәл итүгә юнәлтелгән Столыпин реформасы белән бәйле рәвештә, XX гасыр башында крестьяннарны Себергә күчерү планлы төс ала. Иркутск өлкәсендәге татар авылларының күпчелегенә шул елларда нигез салына. Бу авыллар үтмәс тайга эчендә, сазлыклар арасында, юлсыз җирләрдә урнашкан була. Благодатный, Күлиш (Кулиш), Тәрия (Тарея), Чирмешән (Черемшанка), Федоровск, Черная речка, Харагун, Русь, Чичиков, Шаховский, Новоселово авыллары шул елларда барлыкка килә.

Чирмешән авылына нигез салучылар турындагы оныклары саклаган хатирәләр Иркутск якларына килеп чыгучыларның ничек барып урнашуын, нинди шартларда яшәвен бәян итә.

Хәзерге вакытта искиткеч матур җирдә, урман аланында урнашкан Чирмешән авылының тарихын халык түбәндәгечә искә төшерә.

Салкыннар башланып киткән ноябрь аенда поезд күченеп килүчеләрне ялан кырда, бернинди станция дә, ут та булмаган урында бушатып китеп бара. Халыкның хәлен күзаллар өчен, Иркутск өлкәсендә ул елларда ноябрь аеның уртача температурасы турында мәгълүмат бирәбез. Мәсәлән, 1910 елда ул – 22,6, 1911 елда – 21,9, 1916 елда 27,8 градус була.

Ирләр гаиләләрен, бигрәк тә яшь балаларны саклап калырга омтылып, землянка казыйлар, аннан, көч җиткән кадәр агач егып, йорт салырга керешәләр. Мең газап белән килеп җиткән халык салкын тиюдән кырыла башлый. Балаларны саклап кала алмыйлар.

Күпмедер вакыттан соң кечкенә генә берничә йорт салынып бетә. Ауга йөреп, туенырга кәсеп табып,ияләшә-тынычлана башлаганда гына, яз җитә. Кар эри башлау белән булачак авылның селкенеп торган сазлыкта утырганлыгы күренә. Тизрәк барлыюклы әйберләрен биегрәк урынга күчереп, яңадан йорт салырга керешәләр. Чирмешән авылы тарихы әнә шулай башлана.

Информантлар бу җирләрне ничек үзләштерүләре, эшкәртүләре хакында ата-бабалары сөйләгәннәрне хәтерлиләр. Урман төпләү, җир ачу бик авыр хезмәт була, йөзьеллык агачларны кул пычкысы белән кисәргә генә түгел, тамырларын төпләргә дә кирәк була. Бөтенесе кулдан башкарыла.

Иркутск өлкәсендәге татар авылларында яшәүче информантларыбыз шул елларда ата-бабаларының туган җирләреннән аерылып, туган нигезләрен ташлап, җир, бәхет эзләп бирегә килеп урнашуларын буыннан буынга күчеп килгән риваять итеп хәтерләрендә саклыйлар.

Чирмешән авылында яшәүче иң өлкән информантыбыз Шәехзаман абзый бабаларының бәхет эзләп чыгып китүләре турында ата-бабаларыннан ишетеп үскәннәре белән болай дип уртаклашты:

«*Безнең бабай Мөхәммәтнасыйп исемле була. Иркутск ягына 1911 елда шул бабай күченеп килә.*

*Аның туган авылы Үрмәттә собрание була. Мир җыены җыеп карт әткәйне, ул бик видный кеше була, җибәрәләр Себергә, күреп кайтырга, яңа җирләр карарга. Картәти Мөхәммәтнасыйп исемле була. Аны халык җибәргән. Алар помещик җирендә торганнар. Аның белән килгәннәрне белмәем. Алар Башкортстанның Бакалинский районы Үрмәт авылыннан. Министр Столыпин вакытында бу. Алар 5–6 кеше килгәннәр. 1910 елларда чыгып киткәннәр.*

*Монда урман булган. Әткәйләр биш бала – ир малай булган: Шәйхелимам, Шәйхелгали, Әхмәтгали, Мөхәммәтнәфыйк, Мөхәммәтшәех. Алар монда бала гына булып килгәннәр.*

*Тирә-якта тайга, тибрәлеп торган сазлык була. Бабайлар монда җир ачалар, урман төплиләр. Икмәк уңмый. Беренче уңыш алганчы, алты ел үтә. Бары 30–40 елларга гына урманнарны төпләп бетереп әйбәт уңыш ала башлыйлар. Баштарак халык тайгада туклана, шулай исән кала. Ирләр ауга йөри, хатын-кыз, бала-чага җиләк, чиремшә җыеп, шуны саталар. Чирмешәне вакытында тозласаң, ул озак саклана. Төрле җиләк – кара җиләк, брусника, зәңгәр җиләк, саз җиләге җыялар. Зур сазлар бар монда.*

*Карагайдан сагыз топить итәләр»* (*Насыйпов Шәехзаман Шәйхелимам улы (1921 елгы), Федоровка авылында туган).*

Себер үзләштерелә башлау белән бу якларда сөргенгә җибәрелгән татарлар да күп була. Алар да Иркутск җирләрендә төпләнеп кала. Сөрелгән татарлар арасында җинаять юлына баскан кешеләр дә, баш күтәрүчеләр дә, сәяси тоткыннар да шактый очрый. Илдәге тәртипләрдән риза булмаган, патшага тел тидергән сәяси тоткыннар, шул чорның алдынгы карашлы кешеләре була. Мәсәлән, 1878–1879 һәм 1885 елларда Казан губернасындагы крестьян хәрәкәтләрендә катнашучыларны Иркутск якларына да сөрәләр. Каторжаннарны Иркутск шәһәрендә урнашкан һәм Александровск авылындагы «Александровский централ» дип тарихка кергән төрмәләргә, Черемховода урнашкан копьрудникларга, Заларига поселениегә һ.б. җибәрәләр.

Сөрелгәннәр артыннан аларның гаиләләре күченгән очраклар да булган. Каторжаннар төрмәләр урнашкан шәһәр-поселоклар тирәсендә яшәп калган. Октябрь революциясенә кадәр илдән сөрелгән әлеге катлау турында информантлардан мәгълүмат таба алмадык. Бу күренешнең сәбәбе бик гади: татар халкы, Себергә сөрелү сәбәбе нинди генә булмасын, каторжан булуны мактаулы гамәлләрдән санамый. Шулай булган очракта да, бу турыда онытырга тырыша. Әлбәттә, татарлар арасында да илдәге вазгыятьтән риза булмаган, режимнан ризасызлык белдерүче, революцион карашлы кешеләр булган. Алар бу якларга да сөрелгән.

Иркутск татарларының әлеге катлавы турында Габдерәшит Ибраһимовның «Дәүре галәм» җыентыгында шактый мәгълүмат бар. Бу өзек Иркутск татарларының тарихын яхшырак күзалларга мөмкинлек бирә. Анда сүз алдарак телгә алынган «Александровский централ» төрмәсе, Усолье турында бара:

«*Бер тапкыр сәяхәтем барышында Иркутскида туктаган чагым иде: Александровский завод имамы Мифтахетдин мулла белән таныштык. Шәйхулла Шәфигуллин җәнабларының ханәсендә, ике атнага кадәр аралашып тордык. Азактан бу кеше бер көн безне Иркутскидан илле чакрым ераклыктагы Усолье дип аталган карьянең мәктәпләрен күрсәтергә алып барды. Шул заманда без мөхтәрәм Мифтахетдин мулла илә бик күп сөйләшеп, ислам милләтенең киләчәге хакында үзара фикер алыштык. Менә шушы булдыклы Мифтахетдин мулла, милләте хезмәте юлында, Усолье карьясендә мәктәп ачылсын өчен, никадәр гайрәт иткәнлеген вә Усолье мөселманнарының һәммәсе каторжаннар булганлыгын сөйләде. Соңра үзенең дә шул каторжаннардан булуын әйтеп, миңа каторга хакында берникадәр мәгълүмат бирде.*

*Асыл Иркутскида каторга өчен билгеләнгән җир Александр карьясе имеш: каторжаннар өчен үзәк төрмә шул авылда булып, һәр елны бу хәбесханәгә (төрмәгә) унсигез меңнән егерме өч меңгә кадәр каторга җеназасына хөкем ителгән җинаятьчеләр килә икән. Бу хәбесханәдә даими мәхбүсләр (тоткыннар) уналты меңнән ким булган заман һич юктыр. Димәк, биредәге хәбесханә гадәттәгедән зуррак бер шәһәрдер.*

*Хәзер шул хәбесханә эчендә, хөкүмәтнең мәгърифәте белән һәртөрле матур сәнгать ясау өчен хосусый эшчәнлек даирәләре бар икән. Һәммә җинаятьче нигә маһир, ни нәрсә эшләргә белә, һәркөн билгеле бер сәгатендә шул эшне башкалар белән бергә эшләр.*

*Әгәр һөнәре булмаса, кара эшкә җибәрәләр, һәммә җинаятьчеләр, шул үзләренә судның хөкем карары кылган вакытны тутырганчы, әйтеп кителгән хәбесханәдә хезмәт итәләр. Хөкүмәт бу адәмнәрнең хезмәтләре өчен махсус хак билгеләгән. Боларның һөнәр һәм сәнгатьләренә карап, билгеләнгән акча өчкә бүленә: бере – хәзинәгә, икенчесе – хәбесханә чыгымнарына, өченчесе – бу адәмнең*

*үзенә бирелүе өчен, гамәл вакыты тәмам булганчы хәзинәдә саклана. Бу адәмнең гамәл вакыты тәмам булды исә – хәбесханәдән чыгарылыр, шулвакыт моның тупланган акчасын үз кулына биреп чыгарырлар . Хәтта бәгъзе адәмнәр, вакытларын тутырып каторгадан чыккан чакларында дүрт-биш тәңкә вә бәгъзеләре ике-өч мең тәңкә алып чыгалар, ди. Каторга хезмәтен тутырып, үз ихтыярларына чыкканнан соң, Сибириядә бер волость җәмәгатенә языла да, соңыннан теләгән җирендә урнаша. Акчасы бар, йорт-җир ала да теләгән эшенә тотына. Менә Усольеда да биредәге башка карьяләрдә булган халыкның һәммәсе шул каторга хәбесханәсеннән чыккан адәмнәр икән.*

*Хәзерге вакытта яшәүләре бик яхшы, кәсеб-эшләре бик әйбәт, хәтта боларның күбесенә асыл ватаннарына кайтырга да ирек бирәләр, ләкин үзләре кайтырга риза булмыйлар. Чөнки кайтсак, бу кәсеб, бу рәхәтлек юк, диләр.*

*Шушы каторжаннарның инсафлылары һәр елны үзенең Русиядәге карендәшләренә никадәр ярдәм вә булышлык итеп, акчалар җибәреп торалар, вә бәгъзеләре ике-өч елга бер кайтып киләләр, вә бәгъзеләре анда калган карендәшләрен алып киләләр.*

*Мин бу адәмнәр илә күп аралаштым, боларның әхвәл вә күренешләрен ярыйсы гына күзәттем. Болар арасында үзенең хәленнән шикаять кылганнары (зарланганнары) һаман юк дәрәҗәсендә. Бары тик шуны гына сөйлиләр: «Әүвәл килгәндә балачагаларымны юкка гына алып килмәгәнмен. Һәм каторгага килгән кеше хатын, балаларын алып килергә кирәк икән», – диләр.*

*Хәзер дә шул каторжаннар яшәгән карьяләрнең һәммәсендә берәр мөгаллим бар, балаларына Исламны өйрәтәләр. Менә шулай каторжаннарның хәлләре»*[1].

Г. Ибраһимовның «Дәүре галәм» китабы беренче тапкыр 1908 елда басылган, бу әсәрдә шушы чорларга кадәр булган вакыйгалар тасвирлана. Гражданнар сугышы һәм Октябрь революциясеннән соңгы чорда хәлләр кискен үзгәрә. Иркутск төрмәсе чын мәгънәсендә зинданга әверелә.

---

[1] *Ибраһимов Г.* Дәүре галәм. Казан: Иман, 2001. Б. 75–77.

Иркутск төрмәсенең Колчак белән бәйле еллары татар халкының «Зиндан моңы» дип аталган җырына да кергән. Җыр халыкта бик популяр булган «Ай, былбылым» көенә башкарылган. Анда мондый мондый юллар бар:

**Зиндан моңнары**

*Ангараның буйларында*
*Иркут салган каласын.*
*Ризык дигән кайда кертми*
*Без тик адәм баласын.*

*Кушымта:*

*Ай былбылым, вай былбылым,*
*Ангараның агышы.*
*Ике битем тик саргая,*
*Бар да төрмә сагышы.*
*Ангараны чыккан чакта*
*Күрәм суда ташларын.*
*Төрмә саен өстерәлде*
*Минем газиз башларым.*

*Иркутск төрмәсендә,*
*Йозагы бүлмә бүлмәсендә.*
*Без күргәннәр гыйбрәт булсын*
*Башкаларга күрмәсенгә.*

Иркутск төрмәсе – Аклар хәрәкәтенең башында торган, иң каршылыклы шәхесләрнең берсе, адмирал А.В. Колчакның соңгы көннәре узган урын.

Иркутск татарларын тәшкил иткән тагын бер катлау, илдә барган үзгәрешләрдән качып чыгып киткән. Шундый бер гаилә – үзенең ата-анасының тарихын Залари поселогында яшәүче Нәгыймә апа болай дип сөйли:

«*Әти-әни Казаннан килгәннәр. Минем әни Галимә Заһидуллина. Вәлиев Һади – әтием. Алар килгәндә әни-әтинең ике малай булган инде анда.*

*Әни Кукмара районы Сәрдегән авылыннан*[1].

*Әнинең әтисе Гарфулла бай булган анда. Бик бай булган. Әтисе түгел, аның хатыны әнинең әнисе белән бертуган теткасы булган. Ул Гарфулла бай әнинең атасы урынына була, ул үстергән аны. Әни сүләй торган ие. Ак өй безнең бар ие, аш өе бар ие, кунаклар йорты бар ие. Бик бай торганнар. Бер йорттан икенче йортка кашык кермәде дип сөйли ие. Тәлинкәләр, савыт-саба күчмәгән. Завод-фабрикалары булган Гарфулла байның. Ул кызын Мәскәүгә биргән кияүгә. Бик байга, Мәскәү баена биргән. Железный дорога салды диде шул Гарфулла бай, дип сүләй ие әни.*

*Әти безнең җәтим үскән, ул хәерче булган. Гармунчы булган. Гел гармунын тотып уйнаган инде. Гармуны бар иде Казаннан апкилгән. Бик матур уйнайдыр ие, бик матур җырлайдыр ие безнең әти.*

*Алар бер-берсен бик ератканнар. Гарфулла байны раскулачивать иткәннәр.*

*Әти белән әни 1918 елда киткәннәр монда. Апкилгән алар монда Гали абзыйны, 1912 елгы малаен. Хәлил дигән малае Казанда үлеп калган. Рәсәйдә әнинең бертуган браты – Билал дигән абзые калган. И, энекәемне күрсәм иде, бер күрсәм иде, дип гел сөйләде шуны. Менә хәзер карыйм Зөфәр Билаловны, минем Бари дигән абыйның улларының берсе Ренат исемле. Суйган да каплаган Зөфәр Билалов инде. Карыйм, әллә туган микән безгә. Без дә, өч сестра – Габидә, Әминә, Нәгыймә бик матур җырлайдыр идек. Әни Галимә Заһидуллина. Үз әтисе Заһидулла булды микән?» (Вәлиева Нәгыймә Һади кызы (1932 елгы), Новоселово авылында туган).*

Нәгыймә апа сөйләгәннәрнең нигезендә шул болганчык елларның бер трагедиясе ята.

Сөйләгәннәрдән бай җизнәсендә үскән иркә кызның ятим, хәерче гармунчы егет белән ератышып өйләнешкәннәре аңлашыла. Бай гаилә бу кызны ничек хәерчегә биргәндер, анысы безгә мәгълүм түгел. Күрәсең, Гарфулла бай аларны ярдәмсез калдырмаган, гаилә

---

[1] Сәрдегән авылы Балтач районына керә. Кукмара районында Сәрдек авыллары бар.

аякка баскан, тернәкләнгән. 1918 елда бу гаилә дә тәвәккәлләп юлга кузгала. Гарфулла бай турында мәгълүмат таба алмадык. Әмма Балтач районы Сәрдегән авылының иң зур бае Гарифулла турында мәгълүмат сакланган. Нәгыймә апа сөйләгән Гарфулла бай белән Гарифулла бай бер үк кеше булырга мөмкин. Гарифулла бай исеме Сәрдегән авылы тарихына да кергән. Авыл тарихыннан алынган юлларда, 1927 елда колхоз төзелгән вакытта, Гарифулла байның колхозга тартып алынган милке дә телгә алына: «*Колхозның төп утары – Гарифулла бай йорты. Аның итек басу цехлары ат, сыер, дуңгыз абзарлары итеп үзгәртелә. Колхозның 90 баш аты, 30 лап сыеры, 30 лап дунгызы, 100 баш сарык, күпмедер тавыклары Гарифулла бай каралтыларына урнаша. Байның үзе яшәгән йортын Кукмарага алып барып салалар. Ә байның бөтен учет эшен алып баручы, эшкә җитәкчелек итүче Арча районы Ташкичү авылы кешесе Хәкимнең торак өен колхозның идарә бинасы итәләр. Бу йорт әле дә исән, авылда терлекчеләр йорты булып тора*».

Нәгыймә апа әтисенең оста гармунчы булуын, матур җырлавын сөйли. Иң яраткан җыры Гражданнар сугышы еллары афәтен тасвирлаган «Авыл читендә, бабай йортында» җыры булган. Күрәсең, бу җыр аның кешеләргә сөйләп бетерә алмаган серләренең, гомере буе борчыган, хәл итәргә мөмкин булмаган мәсьәләләренең бер чишелеше булгандыр. Җырда Гражданнар сугышы елларында баррикаданың ике ягында калган туганнар турында сүз бара. Абыйлы-энеле кардәшләр бер-берсенә корал күтәрәләр, берсе советларны яклап, икенчесе аклар ягында калып, һәрберсе үзен хаклы саный. Җырда мондый юллар бар:

*Атма, туганкай, куй мылтыгыңны,*
*Мин синең энекәең бит.*
*Юк минем энем,*
*Энем түгел син,*
*Бүгенге көндә без – дошман.*

Нәгыймә апа Вәлиева гаилә тарихыннан шактый истәлекләрне искә төшерде. Бу истәлекләрдә гаилә тарихы илдә барган вакыйгалар белән бергә үрелеп бара.

*«Монда 1923 елда Колчак торган Заларида. Әтиләр колхоз төзеп ятканнар монда, Красное поле дип атала. Красное Поле дигән авыл бар. Шунда коммуна төзегәннәр. Шунда Колчак кереп, бөтенесен атып үтергәннәр. Әти бәрәңге арасына, ботва арасына качып калган. Әни шул 1923 елны Зәки абыйны тапкан. Ул сугышта үлде. Өч брат минем сугышта үлде.*

*Әти белән әнинең тугыз малай, өч кыз була. Алар 70 ел бергә торганнар. Мин башка шулкадәр гыйшык, матур ярату күрмәдем. Шулкадәр матур тордылар алар. Әнисез әти чәй эчми иде. Иртә белән «Карчык, тор, чәем кайнады инде, әнисе, әйдә тор, чәем кайнады», дип әнине уята ие.*

*Сугыш вакытында без башакка барадыр идек. Анда бодай башагы җыябыз инде, арыш башагы да. «Шул башакны анагызга апкайтыгыз, куырып апкайтыгыз», дип тора иде. Шулкадәр тату торганнар».*

Бер гаилә бәхет эзләп үзе чыгып китсә, икенчеләре алдарак күчеп киткән туганнары, якташлары янына барып урнашкан. Урман төпләп, җир ачып, авыр хезмәт белән интексәләр дә, биредә кешене рәнҗетү, түбәнсетү булмаган диярлек. Татарлар берләшеп, бер-берсенә ярдәм итеп яшәргә омтылган. Илгә язылган хатлар, килеп җиткән хәбәрләр аша, Иркутск якларында яшәгән туганнарының, таныш-белешләренең тормышлары көйләнүен ишетеп, халык килә торган.

Алар районындагы Шаховский авылына 1912 елда Столыпин реформасы белән бәйле рәвештә күчеп килүчеләр нигез сала[1]. Авыл исеме шул авылда җирләрне бүлеп бирүче кешенең фамилиясеннән алынган. Беренче елны килгән кешеләр землянкаларда яшиләр. Бай бурятларга ялланып эшлиләр. Икенче җәйдә кечерәк кенә булса да йортлар салына, үз көчләре белән көн итә башлыйлар. Тормыш җайлана бара. Үз яннарына туганнарын да чакыралар.

---

[1] Большая история маленькой деревни Шаховская / сост. Х.Г. Тухватулина. Кутулик, 2015.

Шаховскига нигез салган татарлар беренче көннән мәчет булдыру уе белән яшиләр. Авыл халкы барысы да – динле-өммәтле халык, алар арта тора, шуңа күрә ислам таләпләрен һәм йолаларын үтәү, һәм бигрәк тә балаларга дини белем бирүне үз өстенә алган мәчет кирәк була.

Мәчет төзелеше халык көче белән 1913 елда башлана, авылга терәлеп торган урманнан ирләр кыш көне бүрәнә әзерли, һәркем көченнән килгән кадәр тырыша, бу олы эштән хатын-кызлар, бала-чага, картлар да читтә калмаска тырыша. Мәчет төзелешенә кирәкле агачларны кышын кисәләр, чөнки кышын әзерләгән агач иң сыйфатлы төзелеш материалы булып саналган. 1915 елның көзенә мәчет әзер була. Шаховскиның беренче мулласы Әхмәтханов Әхмәтхан яңа мәчеттә мөселманнарны намазга чакырып азан укый. Авылның беренче имамы итеп расланган Әхмәтхан мулла тиз арада Шаховский мәчетен ислам һәм мәгърифәтчелек үзәгенә әйләндерә. Биредә мөселман балалары өчен китапханә һәм мәдрәсә оештырыла. Ураза, Корбан гаете укыла, халыкны намазга чакырып, азан яңгырый, ирләр җомга намазына ашыга.

Мәчет бинасы агачтан, ике катлы итеп төзелгән, аның манарасы Казан мәчетләренекеннән аерылмый. Бу табигый дә, Иркутскида Казан ягыннан күчеп киткән татарлар күпчелекне тәшкил итә. Беренче катта гыйбадәт заллары, ә икенче катта уку бүлмәләре урнашкан.

Мәдрәсәдә ислам дине нигезләре, гарәп теле, дөньяви фәннәрдән арифметика, география һәм башка предметлар укытыла.

1931 елдан мәчет бинасында мәктәп эшли һәм 2012 елдан бина яңадан мәчет буларак файдаланыла башлый.

Экспедиция вакытында шушы мәчеттә авыл халкы белән очраштык. Ул хәзерге вакытта да үзенең сакраль энергетикасын саклый.

Шаховскида яшәүче информантыбыз Галиева Фәйхүнә апа әтиләре Иркутскига күченгәндә бишек баласы була. Әтисе Камалетдинов Зыятдин гаиләсе белән 1936 елда Балтач районының Карыш авылыннан биредә яшәүче ир туганнары янына күчеп килә. Фәйхүнә апа: *«Авыл халкы сугышка кадәр рәхәт яшәделәр. Сугыш*

*барысын да алды. Авыл көпшә-балтырган ашады, кычыткан ашады»*, – дип сөйли. Фәйхүнә апа әти-әнисенең туган җирне сагынып яшәүләрен, бөтен җырларының сагыну, туган җир турында булуын искә төшерде. Хәтта яхшы яшәсәләр дә, тормышлары җайланып китсә дә, күчеп килүчеләрнең беренче буыны үзләрен бәхетле санамый. Татар халкы өчен җирсү дигән сүз зур мәгънәгә ия. Туган туфрагын сагынып яши алар. Иркутск өлкәсендә язып алынган җырларда да сагыну, җирсү мотивы бер тексттан икенчесенә күчеп, төрле яктан ачыла. Фәйхүнә апа әнисенең гомер буе Агыйдел буйларын сагынып җырлаган җырларын искә төшерде:

*Агыйделне аша чыктым*
*Балан табалмаганга.*
*Кычкырып җырлап җибәрәм*
*Ямьнәр табалмаганга.*
*Утырдым поезд читенә,*
*Төтен сирпә битемә.*
*Елыйм, сөртәм күз яшемне*
*Кулъяулыгым читенә.*

XX гасыр башларыннан Иркутск губернасына тайга төпләп җирләрне үзләштерү, шахта-рудникларда эшләр өчен «вербовка» белән дә татарлар күпләп килә. Вербовка XX гасыр башында башланып, 70 елларга кадәр дәвам итә.

Иркутск якларына Чирмешән авылында яшәүче Халисә апаның әтисе Мөхәммәтгалим абый гаиләсе 1937 елда вербовка буенча килгән: «*Әти 1937 елда по вербовке килгән, семьясы белән. Кукмара районы Өркеш авылыннан. Алар теплушкаларда 2–3 ай килгәннәр. Юлда ике балалары үлгән. Башта Заларига килгәннәр. Аннан Карлукка күченгәннәр. Заларидан 3 километрда мост бар, шунда булган Карлук. Татар авылы булган ул. Керәшеннәр дә торганнар Карлукта. Картыебыз русча белмәгән. Җиләк күп булган, ул җиләк вакытында көн саен җиләккә йөргән. Капка төбендә тәмәке көйрәтеп утырган урыслар, «опять татарка пошла», дип сөйләнеп калганнар. Мондагы халык җиләк җыя белмәгән.*

*Татарлар үзара бик дус яшәгән гомер-гомергә, йозак бер кешедә дә юк, бер кеше бикләмәгән бер нәрсәне. Авыл халкы матур яшәгән. Кичләрен ирләр белән балалар лапта уйнаганнар. Хатын-кызлар скамьядә карап утырганнар.*

*Мал күп булган һәр хуҗалыкта. Ирләр бабки уйныйлар иде» (Хафизова Халисә Мөхәммәтгалим кызы, (1958 елгы)).*

Новоселово авылында яшәүче Әминә апаның бабалары 1932 елда Казаннан килгәннәр. Әминә апа бабалары турында болай дип сөйли: «*Бабайны раскулачивать иткәннәр. Ул бик бай булган. Раскулачивать ителгәннән соң да, бөтен байлыгын алганнар, шулай да җай табып бер вагон ат алып килгән. Монда алар килгәндә тайга булган. Бабай Хәбибуллин Галәү Низам улы булган. Авылның беренче кешеләре Нигъмәтуллин, Вәлиев Һади, Мугинов, Нургаян карт булган. Галәү бабайның балалары күп була. Ике улы Шәйхулла белән Галләм сугышта үлә. Башка балалары – Гайшә, Гаффә, Хафизә, Нәфисә, Гыйльми һәм Зәкүш үсеп җитәләр. Тагын бер баласы, беренче Зәкүш бала чагында үлә*».

Новоселово авылының җырлары да ирексездән илдән чыгып китү, туган җирне сагынып яшәү турында.

*Безнең авыл борма-борма,*
*Бер бормасы зирексез.*
*Туган-үскән, торган җирдән*
*Без китәбез ирексез.*
*Сандугачлар су эчәләр*
*Күлнең тирән җиреннән.*
*Кемнең китәсе килсен соң*
*Үзе туган җиреннән.*
*Без барасы илләргә,*
*Бодай чәчкән җирләргә.*
*Бодай түгел, алтын булсын,*
*Җитми туган илләргә.*

Иркутск өлкәсендә татар халкы бер яктан чисталыгы, эшчәнлеге белән башкаларга үрнәк булса, икенче яктан динле булуы,

белемгә омтылып яшәве белән дә күпләрне сокландырган. Һәр авыл, төзелүенең беренче елында булмаса да, икенче яки өченче елында мәчет салырга һәм мәдрәсә ачарга тырышкан.

Г.И. Бобкова туплаган мәгълүмат буенча, Иркутск губернасында Октябрь революциясенә кадәр 23 мәчет булган[1]. Бу Новоямское, Биликтуй, Усолье-Сибирское, Голуметь, Залари, Кутулик, Слюдянка, Александровск, Олонки, Манзурка, Тайшет, Нижняя Слобода, Тракт Кавказ, Нижнеудинск, Черемхово, Кулиш, Тарея, Чирмешән, Чернореченский, Чичиковский, Ново-Утямишинский, Харагун, Шаховский мәчетләре.

В.П.Паршинның 1849 елга караган «Иркутскидан Мәскәүгә кадәр юл тасвирламасы» дигән сәяхәтнәмәсендә шул вакытта ук Биликтуй авылында агач мәчет булганлыгы искә алына[2]..

Иркутскиның үзендә мәчет XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башында Иркутскида яшәгән беренче гильдия купец Шәйхулла Шәфигуллин тырышлыгы белән ачыла. Тумышы белән Казан губернасының Акъегет авылыннан булган Шәйхулла һәм Заһидулла Шәфигуллиннар Иркутскида сәүдә белән шөгыльләнә, аларның «Бертуган Шәфигуллиннар» дигән сәүдә йорты тотулары, баштарак җиләк-җимеш, төгәлрәге алма, соңрак мехлар, кием-салым белән сату-итүләре мәгълүм.

Шәйхулла Шәфигуллин 1887 елда Иркутскиның Саломат урамында ике мең сумга бер катлы бина сатып ала һәм ул бина мәчет, дөресрәге намаз йорты буларак файдаланыла башлый. 1890 елда бертуган Шәфигуллиннар Иркутск губернаторына шәһәрдә мәчет ачарга рөхсәт сорап мөрәҗәгать итәләр. Беренче үтенеч кәнәгатьләндеререлми, аннан соң да алты ел дәвамында кат-кат үтенеч язулары белән мөрәҗәгать итәләр. Бары 1896 елда гына Шәйхулла Шәфигуллинга үзе сатып алган йортны, яңа бина төзелгәнгә кадәр, мәчет буларак файдалану мөмкинлеге турын-

---

[1] *Бобкова Г. И.* Татарские общины Иркутской губернии (конец XIX – начало XX в.): монография / Г. И. Бобкова. Иркутск: Изд-во Иркут. гос. ун-та, 2009. С. 134.

[2] *Паршин В.П.* Описание пути от Иркутска до Москвы, составленное в 1849 г. М., 1851. С. 14

да рөхсәт бирелә[1]. Яңа җамигъ мәчетенең беренче бинасы 1897 елның декабрь аенда ачыла. Бу турыда Иркутскиның шул чоры тасвирланган елъязма авторы Н.С. Романов болай дип яза: «Саламатово урамында мөселман мәчете төзелеп бетте, әлегә кадәр мәчет булып гадәти йорт хезмәт иткән. Хәзер мөселманнар мәзиннең яңгыравыклы тавышы белән көнгә биш тапкыр намазга чакырыла»[2].

Иркутскида яшәүче информантларыбыз биргән мәгълүмат буенча, шәһәрнең үзендә мәчет ачылганга кадәр дә татарлар дин кануннарын үтәп яшәгәннәр, алар гаетләргә һәм җомга намазына Пивовариха (село Новоямское) авылында төзелгән мәчеткә йөргәннәр. 1901 елда агач мәчет белән янәшә таш мәчеткә нигез салына һәм ул 1905 елның декабрь аенда сафка баса. Шунысын да әйтү урынлы булыр, бу биналар барысы да, нигездә, бертуган Шәфигуллиннар акчасына төзелә[3].

Мәчет янындагы мәдрәсә дә, кызлар өчен мәктәп тә була.

Экспедиция Усолье шәһәрендә эшләгән вакытта шушы шәһәрдә яшәүче Мөхәммәдиева Мәүлидә апа берничә фото алып килде.

Беренче фоторәсемдә 1926 елда Иркутск мәчетендә имтихан биргән укучылар һәм имтихан алган укытучылар сурәтләнгән[4]. Фотода укучылар да, укытучылар да өстәлләр артына тезелеп утырган. Уртада имтиханның датасы һәм имтихан алучыларның исем-фамилиясе язылган плакат эленгән. Бу язмада имтиханның һәм фотоның датасы да күрсәтелгән: 1926 сәнә 16 май. Фотога кергән тагын бер плакатта Коръәннең өченче сүрәсе – «Әл- Гыймран»дагы Мәрьям Ана искә алынган 37 аятьтән өзек язылган.

Мәүлидә апада Иркутск татар клубы каршында оешкан драмтүгәрәк әгъзаларының 1929 елгы сурәте, Усолье татар крестьян-

---

[1] *Бобкова Г. И.* Татарские общины. С. 140.

[2] *Романов Н. С.* Летопись города Иркутска за 1881–1901 гг. Иркутск, 1993. С. 378.

[3] Иркутская летопись 1661–1940 гг. / Сост., автор предисл. и примеч. Ю.П. Колмаков. Иркутск, 2003. С. 181.

[4] Бу турыда чираттагы мәкаләдә язылган.

нарының 1925 елның 15 февралендә узган I район конференциясе, Усолье татарларының 1926 елның 1 мартында узган II район конференциясе, 1978–1990 елларда Иркутск мәчете имам-хатыйбы булып торган Галиәхмәт Мөхәммәдиевнең һәм башка фоторәсемнәр сакланган. Бу фотолар Иркутск татарларының тормышын төрле яклап ачарга булыша. Аларда халыкның белемгә омтылуы, актив яшәеше, сәнгатькә мөнәсәбәте чагыла.

Иркутск – үзенең үзенчәлекле йөзе булган, тыныч, яшел шәһәр. Анда бер яки ике катлы агач йортлар күп сакланган. Заманында бу күренешкә В.П. Паршин үзенең «Описание пути от Иркутска до Москвы, составленное в 1849 году» дигән сәяхәтнамәсендә дә игътибар итеп, таш йортларда һәрвакыт дымлылык саклангамга, Иркутск халкының аларны сәламәтлеккә зыянлы дип санавын яза[1].

Иркутск өлкәсе татарлары хәзерге вакытта да дус-бердәм булып, аралашып яши. Халык бергәләп Сабан туйларын бәйрәм итә, юбилейларны, гаилә бәйрәмнәрен дә уздыра.

Экспедиция вакытында тагын бер күренешкә тап булдык. Иркутск өлкәсенең туган як музеенда, татарлар шәһәр һәм өлкә тарихында бернинди эз калдырмаган, аларның бер генә мәгълүм кешеләре дә булмаган, дигән фикер ишетергә туры килде. Музей хезмәткәрләре Иркутск татарлары тарихын, алар белән бәйле тарихи урыннарны белми. Мәсәлән, өлкә музеенда Иркутск мәчетен салуда башлап йөргән бертуган Шәфигуллиннарның эшчәнлеген яктырткан, төбәкнең башка атаклы татарлары турында материалларны, шулай ук татар клубы, татар мәктәбе биналарын, татарлар яшәгән йортларны һ.б. ачыклау һәм күрсәтү дә яхшы булыр иде. Бу биналарда Иркутск өлкәсендә яшәүче татарларның тарихтагы ролен чагылдырган элмә library такталар урнаштыру яшь буынны үз халкын белергә, кызыксынырга этәрер иде. Татар клубы, анда эшләгән драмтүгәрәк, татар мәктәбе турында мәгълүмат юк дәрәҗәсендә. Иркутскида татар клубы революциягә кадәр үк оешкан, аннан соң да эшчәнлеген туктатмаган. 1971 елда Иркутскида булган вакы-

---

[1] *Паршин В.П.* Описание пути от Иркутска до Москвы, составленное в 1849 г. М., 1851. С.8.

тында фольклорчы Флора Әхмәтова[1] аның Тимерязев урамындагы Алексеев йортында урнашканлыгын, 1971 елда бу йортта Офицерлар йорты булуын яза. Иркутск татар драмтүгәрәге күренекле татар режиссеры, актриса Кәшифә Тумашева исеме белән бәйле. Кәшифә Тумашева хәзерге Балтач районына караган Нөнәгәр авылында туса да, биш яшендә аны туганнары Иркутскига алып китәләр. ул Өркет шәһәрендәге туганнарында яши. Зирәклеге белән аерылып торган кыз шунда якшәмбе мәктәбендә русча укый башлый. Җитезлеге һәм зирәклеге, белемгә омтылышы турында ишетеп, фабрикант Шәфигуллиннар аны кызлар өчен 1912 елда ачылган җәдит ысулы белән укыта торган мәдрәсәгә укырга чакыралар. Бераздан гимназиядә дә укып, кыз татарча да, русча да яхшы белем ала[2]. Кәшифә Тумашеваның биографиясе аша Иркутскида гимназиядә татар балаларының да укуы ачыкланды.

Алдынгы карашлы укытучылары Кәшифәне әдәби-музыкаль кичәләргә тарталар. Революциядән соң шәһәрдә татар драма түгәрәге оеша. Аның белән укымышлы егет Рәхим Тумашев җитәкчелек итә. 1919 елдан Кәшифә дә шушы түгәрәккә актив йөри һәм сәхнәгә Кәшифә Зауральская исеме белән чыга.

Романов елъязмасында 1921 елда татар телендә «Яшь көчләр» спектакле куелу турында теркәлгән: «5 янв[аря]. В Сов[етском] нар[одном] д[оме] мусульм[анский] раб[очий] клуб им. Муллануpa Вахитова поставил спект[акль] на татар[ском] языке «Новые силы» (Яшь Кучлар)[3].

Флора Әхмәтова Иркутск драмтүгәрәгенең режиссеры Ибраһим Тинский булган дип яза, актерлардан Гаишә Мендееваның исемен атый. Гаишә Мендееваның соңыннан укытучылык итүен һәм 1971 елда лаеклы ялда булуын әйтеп уза. Фольклорчы галимә әлеге ханым белән аралашып, кайбер мәгълүматны аның үзеннән дә алган булырга мөмкин.

---

[1] Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фольклор фонды материаллары.

[2] Татарская энциклопедия. Казань: Ин-т татар. энцикл., 2010. С. 697.

[3] *Романов Н. С.* Летопись города Иркутска за 1881–1901 гг. Иркутск, 1993. С.214.

Шушы ук язмада Флора Әхмәтова Иркутскида яшәгән татар зыялылары турында болай ди: *«Татар интеллигенциясе бар. Художниклар фонды директоры Закиров Әнвәр Шакир улы, художник. Аның энесе Әкрам университетта философия укыта, доцент. Ильясов – мединститутта укыта. Тау инженеры Сахабов, Урманчеев һ.б. Язучы Хәерниса Сафина Иркутск татарлары тормышыннан романнар яза. «Гульшира» дигәне 1968 елда басылган, икенчесе чыгарга тиеш шул елларда. Үзе пенсиядәге укытучы»*.

Иркутскида татар язучы Якуб Зәнкиев туган. Мәшһәр биюче Рудольф Нуриевның туган җире булып, гәрчә үзе поездда тууына басым ясаса да, Иркутск шәһәре язылган.

Иркутск татарлары арасында мәгълүм исемнәр тагын да бар: 1939–1948 елларда ТАССР халык комиссары, Халык мәгарифе министры У.Т. Контюков, СССРның дәүләт премиясе лауреаты Р.А. Хәбибулхакова, 1938–1951 елларда ТАССР Югары Советы Президиумы рәисе, өч тапкыр Ленин ордены кавалеры Г.А. Динмөхәммәтов, генерал-лейтенант М.А. Сулькевич һ. б.

Хәзерге вакытта да милләттәшләребез татар мәдәниятенә, халык моңына битараф түгел. Өлкәдә 15 ләп татар ансамбльләре һәм фольклор коллективы эшли: «Бүләк» (1991 елдан, Иркутск), «Чишмә» (Ангарск), «Агыйдел» (2004 елдан, Усолье-Сибирск), «Туган тел» (Чирмешән), «Йолдыз» (Залари), «Дуслык» (2000 елдан, Яңа Нокыт поселогы) һәм «Туган авылым» (1984 елдан, Хареты авылы, 2003 елдан) – икесе дә Нокыт районында, «Туган Як» (Нокыт), «Туган авылым» (2003 елдан), «Туган Як» (2000 елдан), «Туган авылым» (2004 елдан), «Туган як» (1988 елдан, Оса районы Оса авылы, 2014 елдан – халык театры), «Умырзая» (Бохан районы Тараса авылы) һ. б.

Халык бөтен шартын туры китереп Сабантуй, Каз өмәсе, Корбан бәйрәме, Ураза бәйрәме, Татар мәдәнияте һәм татар киносы көннәре һ.б. үткәрә. 2010 елдан башлап даими уздырыла торган «Ангара таңнары» татар һәм башкорт сәнгате фестиваль-конкурсы турында да горурланып сөйлиләр. Вакытлы матбугат битләрендә алар барысы да яктыртыла.

Иркутск татарларының милли ризыклары турында да искә алмасак, мәкалә тулы булмас иде. Биредә милли ризыкларыбыз барысы да әзерләнә, аерма да юк кебек. Әмма бу беренче карашка гына. Биредә – татар халкының онытыла барган милли ризыклары саклана. Бу, әлбәттә, газ кермәү, зур мичләрнең саклануы белән дә бәйледер, икенче яктан, ул традицияләрнең онытылмавы, әби-бабайлар рухына хөрмәт булып аңлашыла. Мич кабартмалары, мичтә пешкән җимешле бәлешләр безне дә балачакка кайтарды. Әйе, гөбәдия түгел, төрле җимешләр белән дөгедән генә торган бәлеш, аның өстен, капкачын ачып, эреткән атланмай салып, капкачын кисеп бирәләр. Ачык бәлешне агач кашык белән уртадан үрелеп ашыйлар. Соңыннан бәлеш төбе дә бүленә. Бу рәвешле җимешле бәлеш пешерү, аны шулай ашау күптән очраганы юк иде.

Табын түренә чәк-чәк, кош теле, бәлеш, пәрәмәчләр куела. Сөт, каймаклы катык, май чыгарыла. Әлбәттә, Иркутскидагы тормыш шартларына бәйле рәвештә, күрше халыклар йогынтысында башка ризыклар да формалашкан. Бу – күпләп чиремшә, абага тозлау, аларны куллану, балык ризыклары һ.б.

Тормышлары матур, өстәлләре мул, йөзләре ачык, сыйлары тәмле милләттәшләребезнең.

Иркутск татарларының, Октябрь революциясеннән соңгы иҗтимагый һәм мәдәни тормышы өйрәнүне көтә. Бу турыда архив материаллары, язма истәлекләр бар, ишетеп белгән кешеләр исән. Архив, шул чорда дөнья күргән вакытлы матбугат, елъязмалар аша да күпмедер тарихны торгызырга мөмкин булыр иде.

Иркутск татарларына багышланган әдәби әсәрләр бар. Алар да халык тормышының аерым мизгелләрен торгызырга ярдәм итә. Мәсәлән Кәшифә Тумашеваның кызы Зөмәррә Халитованың «Җилгә каршы» («Против ветра») документаль романында Өркет татарларының тормыш-көнкүреше турында кызыклы мәгълүматлар урын алган. Зиннур Хөсниярның «Хуш, авылым» повестенда Иркутск өлкәсенең Кулиш авылына сөрелгән татар кешеләре турында сүз бара.

Бу язмабыз Иркутск татарлары тарихы белән кызыксынучыларга эзләнүләргә бер этәргеч булыр дип өметләнәбез.

# ВОЗНИКНОВЕНИЕ И РАЗВИТИЕ ЭТНИЧЕСКИ ОДНОРОДНЫХ ТАТАРСКИХ ПОСЕЛЕНИЙ НА ТЕРРИТОРИИ ИРКУТСКОЙ ГУБЕРНИИ В КОНЦЕ XIX – НАЧАЛЕ XX В.[1]

*Галия Бобкова*

Аграрный вопрос занимал важнейшее место в социально-экономической и общественно-политической жизни России. Существенной составной частью аграрной политики Российской империи являлось содействие переселению малоземельных крестьян на свободные земли. Одним из районов переселения стала и Иркутская губерния, куда устремились крестьяне из Европейской России. Наряду с русскими переселенцами, которых было, несомненно, большинство, в Сибирь потянулись представители различных народов царской России. Именно благодаря сельскохозяйственному переселению на территории Иркутской губернии появились компактные поселения украинцев, белорусов, немцев, поляков, чувашей, татар. Однако если в целом по теме сельскохозяйственного переселения в Иркутскую губернию есть отдельные глубокие исследования, то национальный аспект этой проблемы еще не изучен.

О масштабах переселения татар можно судить, сопоставив разные источники – данные архивов и полевые материалы, собранные автором в селах и деревнях Иркутской области, изыскания краеве-

[1] Отрывок из монографии «Татарские общины Иркутской губернии (конец XIX – начало XX в.).

дов на местах. Также можно выявить некоторые особенности жизни и хозяйствования крестьян-переселенцев этой национальности[1].

Размещение переселенцев на территории Восточной Сибири постепенно менялось. Первоначально они подселялись в селения старожилов или размещались на безлесных территориях. Когда легко поддающиеся освоению земли закончились, пришлось отвоевывать землю для пахоты у леса, тайги. В Иркутской губернии это произошло раньше, чем в Западной Сибири. Освоение тайги могли наиболее успешно осуществлять те переселенцы, которые имели опыт и навыки ведения хозяйства в лесной зоне.

Задачи освоения новых земель в Сибири привели к необходимости создания переселенческих участков в таежных районах, где не было до того времени места для пашен. Однако и такие места были востребованы, но заселены, правда, в последние годы планового переселения – 1912–1914 гг. В числе этих отважных переселенцев были и татары, основавшие этнически однородные селения[2].

Становление переселенческих хозяйств в Сибири было сопряжено с большими трудностями. Переселенцы, прибывшие в Сибирь с разрешения правительства, поселялись на участках, расположенных далеко от обжитых мест, на совершенно новых, неосвоенных землях. В наделах, получаемых переселенцами из расчета 15 десятин на душу мужского пола, на долю угодий, непосредственно необходимых для крестьянского хозяйства (пашни, сенокосы, выгоны), приходилась сравнительно небольшая часть. Остальная земля находилась под лесом.

Нами изучены некоторые особенности формирования татарского населения губернии конца XIX – начала XX в. в рамках планового переселения, конкретнее – этнически однородные поселения, появившиеся на рассматриваемой территории в результате сельскохозяйственного переселения. Выявлены три группы этнически однородных татарских деревень. Первая – на территории Алза-

---

[1] Полевые материалы. С. 3, 7.

[2] ГАИО. Ф. 171. Оп. 1. Д. 70; Прил. 3. Полевые материалы автора. С. 3–13.

майской волости Нижнеудинского уезда, вторая – в Заларинской волости, третья – в Хор-Тагнинской волости Балаганского уезда. Таким образом, сложились уникальные сообщества жителей нескольких деревень, объединенных одной культурной традицией, языком, связанных между собой семейными, дружескими, хозяйственными, религиозными отношениями. Других групп татарских поселений подобного рода на территории Иркутской губернии в исследуемый период не было. Имелись лишь отдельно стоящие деревни или села, где компактно проживали татары, переселившиеся в различные годы.

Среди исследователей переселенческого дела в Сибирь сложилось мнение, что большинство переселенцев стремились устроиться в таких географических условиях, которые были сходны с местом их выхода (лесная, таежная, степная зоны)[1].

Разумеется, этой закономерности нельзя придавать абсолютного значения, так как она часто нарушалась. Не подтверждает эту мысль заселение земель Балаганского и Нижнеудинского округов Иркутской губернии (ныне территория Заларинского района), а также Канского округа Енисейской губернии (ныне территория Чунского района). В 1897–1913 гг. сюда прибыли татары-переселенцы из Уфимской, Казанской, Пермской и других губерний. Земли Уфимской и Казанской губерний считаются «промежуточными», где степная и лесная зоны с точки зрения ведения хозяйства для людей в равной степени привычны. Выходцы из Поволжья и Башкирии распределялись по волостям по времени и количественно постепенно. Уход в тайгу был заключительным аккордом в освоении сибирских земель.

К 1 января 1911 г. по общим результатам зачисления долей угодий в районах по губерниям выхода переселенцев (с учетом зачисленных в предыдущие годы) данные выглядели так (всего зачислено 18 840 долей):

Казанская – 153 (доли),

---

[1] *Воробьев В. В.* Формирование населения Восточной Сибири: Географические особенности и проблемы. С. 175.

Уфимская – 26,

Симбирская – 227,

Пензенская –338,

Пермская – 122.

Количество реально водворенных было меньше. В отчетном году водворилось 2 652 семьи на 7 216 долей, что вместе с водворенными прежде с учетом выбывших составляло к 1 января 1911 г. 9 907 семей и 30 954 доли.

Этнически однородные поселения появились на территории Иркутского переселенческого района в начале XX в. Пик приходится на 1910–1914 гг. В это время заселялись места, отдаленные от железной дороги, с более сложными условиями жизни.

В «Делах заведующего землеустройством и переселением в Иркутской губернии» отмечалось, что к 1 января 1911 г. колонизационный фонд Иркутской губернии составляли 710 переселенческих, 84 хуторских участка и 8 старожильческих селений. К 1 января 1911 г. было занято водворенными на переселенческих участках 30 604 доли, зачислено 18 777, оставалось свободных 85 384, из них 65 000 долей могло быть предоставлено для немедленного заселения. Подводится следующий итог: «Движение ходоков надо признать слабым…» В 1910 г. в Иркутскую губернию было разрешено свободное ходачество всем желающим, срок зачисления продлен до 1 октября.

В отчете о зачислении земель ходоками, водворении и устройстве переселенцев в Иркутской губернии в 1910 г. говорится следующее: «Особенно охотно зачисляются участки, близкие к железной дороге, со значительным количеством готовых пашен и лугов и с обеспеченным водоснабжением. Ходоки боятся удаляться от участков, на которых есть водворенные переселенцы, предпочитают участки уже заселенные или расположенные вблизи старожильческих селений. Неохотно зачисляются на отдаленные лесные участки, на безводные, лишенные лугов»[1].

[1] ГАИО. Ф. 171. Оп. 1. Д. 256. Л. 28.

В общем плане работ по переселенческому делу в Иркутской губернии и соображениях о расходах, необходимых для его ведения в 1909 г. отмечается, что «в заселенной полосе Нижнеудинского, Балаганского и Верхоленского уездов, после 1909 г., если и можно рассчитывать еще на занятие земель для переселения, то только незначительной площадью, отдельными мелкими участками…»[1].

Основными местами расселения татар стали Балаганский и Нижнеудинский уезды. Именно там образовались в эти годы три группы этнически однородных татарских поселений. Кроме того, в некоторых деревнях и селах татары поселились наряду с русскими.

Нами рассмотрены три группы этнически однородных поселений, образовавшихся в один и тот же период (1911– 1916). Две группы расположены на территории Балаганского уезда группа – в Тагнинской (с 1915 – Око-Тагнинской) и в Заларинской волостях. Третья – на территории Нижнеудинского уезда Алзамайской волости.

Еще в 1904 г. Балаганский уезд был обследован землеустроительно-переселенческим отрядом, определившим места для возможного поселения новых обитателей. В ходе столыпинской реформы Балаганская земля приняла переселенцев больше, чем насчитывала жителей. Сюда ехали люди из всех губерний, разных национальностей. Выходцы из Белоруссии, могилевские крестьяне обосновали д. Мариинск. Украинские переселенцы дали жизнь участкам Хохловский, Большой и Малый Усовский, Халтам. Среди переселенцев оказались чуваши, мордва, вепсы, а также татары из Среднего Поволжья, Уфимской и Пермской губерний.

В начале XX в. лучшие земли уезда были заняты. Правительство было заинтересовано в освоении окраин, именно там образовывались переселенческие участки, заимки, хутора. В годы столыпинской реформы на территории Око-Тагнинского подрайона Тагнинской волости были образованы несколько чисто татарских поселений. Это переселенческие участки Харагунский, Хорско-Бутырский, Федоровский, Черемшанский, Черноречен-

[1] ГАИО. Ф. 171. Оп. 1. Д. 23. Л. 16.

ский. Деревни были основаны почти одновременно, татарами из Уфимской губернии. Большая группа татар поселилась тогда же в переселенческом участке Русь наряду с русскими. Жители этих деревень долгое время поддерживали между собой связи – брачные, хозяйственные, дружеские.

Первоначально участки предназначались для переселенцев из Могилевской губернии. Однако произошло перезачисление наделов, и на данную территорию стали переселяться татары[1].

На родине все переселенцы занимались земледелием, и именно нехватка земли и леса стала главной побудительной причиной их переезда в Сибирь. Участки, где водворились татары-переселенцы, по степени своей пригодности для земледелия, согласно официальной оценке переселенческих чиновников, относились к третьей – худшей категории. Здесь преобладали суглинки, не было достаточного количества чистой от леса земли. Впоследствии жители большинства этих деревень отошли от земледелия и стали промысловыми рабочими.

До нашего времени сохранилось единственное из указанных поселений – д. Черемшанка, которая является крупной татарской деревней. Деревень на месте участков Русь и Федоровский уже не существует, остальные находятся на грани вымирания.

Остановимся на участках, созданных в Око-Тагнинском подрайоне Тагнинской волости. С 1915 г. они вошли во вновь созданную Хор-Тагнинскую волость. Переселенческий участок Харагунский создан в 1908 г., относился к Око-Тагнинскому подрайону Тагнинской волости. Ссудная полоса в 200 рублей. Участок поселкового пользования. Общее число душевых долей – 191, норма земельного надела на 1 душу мужского пола – 15 десятин. Площадь удобной земли – 2 872 десятины.

На 1 января 1913 г. на участке было водворенных 6 семей, в том числе 11 мужчин, которые заняли соответственно 11 долей

---

[1] *Галеткина Н. Г.* Черемшанка: динамика развития татарской пересе-лен- ческой деревни // Россия и Восток: Взгляд из Сибири : материалы и тез. докл. к XI Междунар. науч.-практ. конф. (Иркутск, 13–16 мая 1998 г.). Ир- кутск, 1998. Т. 1. С. 208.

земли. На 1 октября количество семей увеличилось до 20, а число мужчин и занятых долей составило 52. В октябре 1913 г. подъехала еще одна большая партия переселенцев, и к концу месяца семей насчитывалось 33, занятых долей – 78. В течение последующего времени вплоть до 1915 г. число семей, а также мужчин и занятых земельных долей менялось лишь незначительно, то в сторону увеличения, то в сторону уменьшения. В декабре 1913 г. эти цифры составили: 34 – 79 – 79; с 1 мая по 30 июня 1914 г. – 36 –86 – 86; с 31 июля по 30 августа 1914 г. – 37 – 88 – 88; с 31 января по 28 февраля 1915 г. – 32 – 81 – 81; с 31 июля по 30 сентября 1915 г. – 34 – 85 – 85[1].

Таким образом, население участка Харагунский сложилось фактически в течение 1913 г. Площадь удобной земли, занятой к ноябрю 1913 г., составляла 1885 десятин. Стоит обратить внимание на большое количество свободных долей – 72 на 1 октября 1913 г. Часть из них была зачислена в конце 1913 – начале 1914 г., когда число свободных долей сократилось до 47. Однако по каким-то причинам, к участку Харагунский зачислившие эти доли потеряли интерес, так как число водворенных в этот период не увеличилось в пропорциональном размере[2].

Ведомости о водворении и зачислении, к сожалению, не указывают общее количество прибывших, а содержат сведения только о лицах мужского пола. Поэтому количество жителей переселенческого пункта Харагунский к концу 1915 г. можно установить путем вычислений. Если соотношение мужчин и женщин принять за 1:1, оно составит 170 человек. Таким образом, количество жителей можно определить в 160–170.

Переселенческий участок Хорско-Бутырский создан также в 1908 г., относился к Око-Тагнинскому подрайону Тагнинской волости. Ссудная полоса в 200 рублей. Участок поселкового пользования. Общее число душевых долей – 392, норма земельного надела

---

[1] ГАИО. Ф. 171. Оп. 1. Д. 70. Л. 75, 175, 281; Д. 81. Л. 78–79, 143–144, 255–256, 420–421; Д. 86. Л. 91–92, 228–229; Д. 87. Л. 57–58, 167–168, 280–281.

[2] Там же.

на 1 душу мужского пола – 15 десятин. Площадь удобной земли – 5 874 десятины.

На 1 января 1911 г. на участке было водворенных 15 душ мужского пола. Свободных долей числилось 306, следовательно, 71 доля была на этот момент зачислена. На 1 января 1913 г. водворенных было 11 семей, мужчин и занятых ими долей – 35. На октябрь 1913 г. занято удобной земли 2 250 десятин.

В течение 1913 и 1914 гг. население участка прибывало. На 30 сентября 1913 г. водворено 35 семей, мужчин и зачисленных долей – 92; на 31 декабря того же года – 56 семей, мужчин и зачисленных долей – 150; на 30 июня 1914 г. – 71 семья, мужчин и зачисленных долей – 186. Впоследствии эти цифры менялись незначительно, и на октябрь 1915 г. 69 семей, 175 мужчин и зачисленных долей[1].

По архивным данным можно проследить колебания в размерах зачисленных долей. Нужно отметить, что в 1915 г. свободных долей осталось лишь 62, зачисленными были 155 долей. Однако сведений о водворении на эти доли переселенцев нами не найдено. Ведомости о водворении и зачислении отмечают, что в 1915 г. три человека мужского пола (две семьи) выбыли обратно на родину.

Если произвести вычисления по вышеуказанному принципу, то количество жителей участка Хорско-Бутырский в 1915 г. составляло около 350 человек.

Переселенческий участок Русь основан в 1908 г., относился к Око-Тагнинскому подрайону Тагнинской волости. Ссудная полоса в 200 рублей. Участок поселкового пользования. Общее число душевых долей – 196, норма земельного надела на 1 душу мужского пола – 15 десятин. Площадь удобной земли – 2 947 десятин.

С 1 января по 31 декабря 1913 г. водворена была одна семья, в составе которой – один человек мужского пола. Возможно, это была семья ходока. На 1 мая 1914 г. водворено 12 семей, мужчин и занятых долей числилось 26. К концу этого года поселок попол-

[1] ГАИО. Ф. 171. Оп. 1. Д. 70. Л. 75, 281; Д. 81. Л. 78–79, 143–144, 255–256, 420–421; Д. 86. Л. 91–92, 228–229; Д. 87. Л. 57–58, 167–168, 280–281; Д. 256. Л. 6.

нился еще тремя семьями, а число мужчин составило 35 человек. В течение всего 1915 г. в Русь прибыли еще две семьи, и на 30 сентября 1915 г. население поселка составляли 17 семей, в числе которых было 39 мужчин, занимавших 39 земельных долей. Число свободных долей на конец этого периода составило 62. Следовательно, 95 долей этого участка считались зачисленными. Однако о водворении на эти доли сведений нет[1].

Число жителей этого переселенческого участка по сравнению с другими весьма невелико. Исходя из расчетов, оно составляло около 75 человек. Однако в данном переселенческом участке население состояло не только из татар. По некоторым данным, из 17 дворов татарских было 9, а число душ мужского пола – 20. Следовательно, численность татар была примерно 40 человек.

Переселенческий участок Федоровский основан в 1909 г. Относился к Око-Тагнинскому подрайону Тагнинской волости. Ссудная полоса в 200 рублей. Участок поселкового пользования. Общее число душевых долей – 257. Норма земельного надела на 1 душу мужского пола – 15 десятин, площадь удобной земли – 3 842 десятины.

На 1 января 1911 г. участок был еще пуст, здесь не числилось ни одного водворенного. На 1 января 1913 г. состоит водворенных 32 семьи, в их числе 79 мужчин. Следовательно, заселение произошло в летний период 1911 г. или в 1912 г. Поскольку на 1 января 1911 г. зачисленных долей еще не значится, то вероятнее, что в 1911 г. на участке побывали ходоки и было зачислено определенное количество долей, а водворение осуществилось в 1912 г. За весь 1913 г. население участка увеличилось всего на две семьи, в числе которых двое мужчин. В последующие годы и так небольшое количество жителей не прибывало, а, напротив, убавлялось. В 1914 г. здесь числится 24 семьи и 60 человек мужского пола, а на конец сентября 1915 г. – 23 семьи и соответственно 53 человека мужского пола.

---

Вторая часть приведенных таблиц говорит о хронологии строительства жилых домов на участках, что означало оседание людей на месте. Строительство домов шло постепенно, из года в год. Дома небольшие, похожие на типичные для Сибири зимовья, быстро отапливались. Экспедиционные изыскания Заларинского

РКМ и АЭМ «Тальцы» гор. Иркутска в 2014 г. помогли установить 5 сохранившихся столетних домов в дер. Черемшанке. Обследование показало, что размеры построенных домов и указанные в Переписи соответствуют действительности. Особенностью оказалась нетолстостенность этих домов. Видимо, переселенцы не совсем были знакомы с климатом края и способами строительства домов из векового дерева не владели. Не случайно в воспоминаниях старожилов присутствуют утверждения, что многие переселенцы в первое время умирали от морозов.

Южная часть района явилась частью, куда направляли основной поток татар-переселенцев, прибывших в начале XX в. по Столыпинской аграрной реформе на освоение земель Сибири, представляет собой горно-таёжную область предгорий Саян, или, как принято здесь называть эти предгорные места – Присаянье. На 1913 г. чиновникам особых поручений по переселенческим делам А.А. Райнертом была представлена к отчету система о заселении местности в зависимости от географии. Участки делились на 3 группы по сложности освоения участков:

При Тагнинском волостном селе – в серединной части района. Здесь болота, заболоченные пади, небольшая холмистость.в нее входит 11 участков, относительно уже разработанные или облегченные благодаря высоким сухим местам и луговым полосам.

Юго-западная часть подрайона. Здесь начинается зона таежных лесов. Здесь людей селится меньше. Дальняя волость – Хор – Тагнинская. К ней относятся участки Хор-Бутыринский, Харагун, Ивановский, Пихтинский и др. (всего 10 участков). Участки заселены всего наполовину. Многие новоселы уходят жить к старожилам.

Группа на юге Хор-Тагнинской волости – Черемшанка, Русь, Каменка, Исаковка и др. – 8 участков. Все они представляют собой особо трудные к разработке участки тайги. Здесь начинается нетронутая вековая тайга, которая переходит в Саянские горы. Под фразой в отчете «Разработка и расчистка под пашни трудна, предприняты корчевальные работы по расчистке» кроется неимоверный добровольный каторжный труд крестьян, чтобы добыть

хлебородное угодье. (В 1950-е гг. сюда будут поселены спецпереселенцы Западной Украины). Здесь, на землях 2 и 3 участков и поселили уроженцев Уфимской губернии.

Люди закалятся, приспособятся, обретут таёжные промыслы, помогавшим выжить в суровых непривычных условиях. Основными промыслами станут охота, заготовка и сплав леса, заготовка дров, ягод, орешничество, смолокурение, дегтярный промысел. Выручало то, что кругом много леса, и люди же уже были причастны к лесным промыслам – охоте, рыбалке. Здесь, в восточносибирской Саянской тайге, им довелось в условиях дикого нетронутого края и буйного таежного ландшафта пройти и укрепить тропы лесных бурятов, звериные тропы к водопою, разведать местность черемшанской тайги и, поделив ее на таежки, построить таежные охотничьи зимовья. В Заларинской тайге существовали таежки Мартышкина, Кузьминиха, Малиновая гора, Жежем, Выборов Хребет, Углы, Анфимова, Нефедова баня и другие, которые стали за небольшим веком служить новым обитателям – столыпинским переселенцам. Таежные зимовья явились негласным дополнением к развитию социальной инфраструктуры переселенческого подрайона, так как они помогали устраиваться на новом месте, подчинять эти угодья себе. Таёжный характер местности явится судьбоносным для татар, переселённым в эти места. Вековой лес будет отодвинут неимоверным ручным трудом и уступит место расчищенным землям под обустройство.

Позднее в начале советского периода черемшанские татары попробуют образовать колхоз, но землепашество очень не подходило к предгорной зоне, и тогда ими была создана артель по изготовлению древесного угля. Уголь шел на работу кузниц во всех населенных пунктах района. Черемшанцы также, как и в Заларях, поставили для духовных нужд небольшую мечеть, которую сами же и содержали. Школа здесь действовала как часть реформы: Переселенческим Управлением отводились деньги на содержание учителя. Первыми учителями назвали Тулякова Салиха, Тимергазина. Многие татары привезли с собой богословские книги на арабском языке, которые они умели читать.

Земли Балаганского уезда были в большинстве своем к началу земельных реформ не тронуты ногой первопроходцев. Два века – XVIII и XIX – понадобилось русским государственным людям для обживания этих места. Для того, чтобы представить разницу заселяемости края, приведем цифры: 1722 г. в Илимском воеводстве, куда входили наряду с другими и земли будущего Заларинского района, проживало всего 14 400 чел (из них в Братском остроге – 1272 чел, Нижне-Илимском – 935 чел, Киренском – 535). На заларинской земле площадью в 7,6 тысяч кв. километров за это же время было образовано всего 7 сел и 14 деревень. Конечно, при таких всеобщих по Восточной Сибири показателях этот край продолжал оставаться краем холода, льда и вечной нехоженой тайги для людей за Уралом-камнем.

На этом фоне с невольным уважением оглядываемся на событие, о котором рассуждаем с высоты его 100-летнего юбилея, с высоты опыта положительного и отрицательного, обретенного как следствие по истечении этих ста лет. Речь идет об аграрной и переселенческой реформах государства начала XX века, автором которых явился просвещенный политик, блестящий экономист и юрист, крупный административный талант, отказавшийся почти от личной жизни и вложивший свою удивительную работоспособность в преобразование России – председатель Совета министров Российского правительства с 1906 года Петр Аркадьевич Столыпин. Его программа заключалась в освобождении крестьян от «общинной крепи», о наделении их землей: предоставление участков земли должно быть в Сибири, что будет способствовать заселению и хозяйственному освоению края. Основную тяжесть всех организационных и хозяйственных работ и финансовых затрат на себя должно взять – и взяло! – государство.

Люди преодолели громадный путь по железной дороге, перевозя свой скарб, со страхом покидая свои вековые «гнезда» на исторической родине. По воспоминаниям старожилов-переселенцев, в дороге рождались дети и умирали старые и больные. Это был государственный риск в отношении своего народа. Вот так прокомментировал это состояние в своей речи П.А. Столыпин

на Государственной Думе 5 декабря 1908 года после принятия Думой законопроекта о землеустройстве крестьян: «Господа, нужна вера. Была минута, и минута эта недалека, когда в будущее России была поколеблена, когда были нарушены многие понятия. Не нарушена была в эту минуту лишь вера царя в силу русского пахаря и русского крестьянина. Это было время не для колебаний, а для решений. В эту тяжелую минуту правительство приняло на себя большую ответственность, проведя в порядке 87 закон 9 ноября 1906 года. Оно сделало ставку не на убогих и пьяных, а на крепких и сильных. Таковых в короткое время оказалось полумиллиона домохозяев, закрепивших за собой более 3200000 десятин земли… Помните, господа, законодательствуя, что таких сильных людей в России большинство»... Могущество России приросло не только Сибирью и ее недрами, а и многочисленным естественным приростом переселившихся в Сибирь.

О возврате татар на родину вопроса не стояло. Есть только единственное упоминание об одной семье Бурхановых, вернувшихся на родину. Уфа была так далеко, что и помышлять о возврате не стоило. Однако, миграция из тайги все же стала происходить с новыми временами. Большое количество черемшанских татар стали выезжать как до революции, так и позже в связи с заработками денег на Троицкий винокуренный, потом спиртовый завод, плативший живые деньги за заготовку дров, изготовление шпал и за картофель и пшеницу, шедшие на изготовление спирта, а также в деревни Кряжево, Сорты, Заблагар, находящиеся вблизи с заводом. Там всюду были плодородные земли. Часть черемшанцев оказалась в дер. Сенная падь с того момента, как в 1929 г. туда прибыла большая партия татар-практических беженцев от голода и расправы новой власти с крестьянами Поволжья. К татарам Сенной пади (22 км от р.ц.) относятся семьи: Аксановых, Газизулиных, Замалеевых, Идиатулиных, Нуреевых, Рахмеевых, Хафизулиных, Хакимовых, Шагеевых, Юсуповых и др.

Пол переписи 1925 г. здесь уже 31 двор 169 человек. С переселением татар в 1929 г. населения станет значительно больше

еще и потому, что за 10 лет сюда прибывали татарские семьи из таежной зоны.

Перед войной в дер. Карлук Заларинского района прибыли татары, завербованные на строительство колхозной жизни. Но тут они не прижились. Кто-то вернулся назад, кто-то растворился в деревнях с населением татар района. Небольшая часть татар была поселена на железнодорожном разъезде Заларинского района – Хот-Хор, но подробно этот вопрос не изучен.

Так к концу XX в. образовался некий единый татарский пласт населения в районе с ярко выраженным происхождением большинства их из таежной части.

Рост продолжался на сибирской земле и дальше.

В качестве среднего статистического примера роста за 100 лет приведём типичную татарскую семью переселенца Давлетшина Сахиб-Гарея (1878 г.р.), прибывшего в Хор-Тагнинскую волость Балаганского уезда переселенческий пункт Русь из Уфимской губернии, Бирского уезда, Асаяновской волости, аула Такерлик (данные приведены в свете 100-летия переселения семьи). В 1913 г. он имел жену Гайфу, 14-летнего брата Саид-Гали, и в 1914 г., получив здесь земельный надел, позднее он привёз родителей, двух престарелых людей, которые вскоре скончались. За XX век в этой семье из 5 переселенцев появились:

детей: 12 человек;
внуков: 32 человека;
правнуков: 37 человек;
праправнуков: 15 человек;
прапраправнуков: 2 человека.

Прирост за 100 лет составил у одной семьи 102 – 5=97 человек. Такая картина была было типична для татарских семей. До 1960-х гг. браки старались соблюдать земляческими, татарскими. Но с расширением образовательных возможностей, желанием заработать на сибирских стройках городов Ангарск, Шелехов, Свирск, северных стройках ГЭС и др. и вырваться из бедности таежной глубинки, стало происходить смешение татар с другими

представителями Сибири, растворение и утрата столыпинских татарских фамилий с транзитной родины в Заларинском районе

На конец 20 века в 1990 г. Заларинском районе татары кучно проживали в количественном составе:

пос. Залари – 287 чел.,

дер. Владимир – 44 чел.,

дер.Романово – 33 чел.,

дер. Сенная Падь – 111 чел.,

дер. Сорты – 36 чел.,

дер.Троицк – 31 чел.,

дер. Холмогой – 36 чел.,

Хор-Бутырино – 8 чел,

дер. Черемшанка – 471 чел., (пункты Русь, Черная речка, Харагун существуют как урочища);

еще 783 чел. находятся разрозненно по разным деревням. В основном это потомки столыпинцев. Огромное количество татар проживают в городах Иркутской области Ангарске, Свирске, Иркутске, Усть-Илимске, Черемхово, Усолье и за пределами области. Татар, пустивших в Сибирь свои родословные корни в 5, а то и в 6 поколений, можно назвать восточносибирскими, или иркутскими, татарами, сплотившимися здесь из разных уголков Поволжья в одну семью. Именно такое социальное и духовное явление «осибирячивание» произошло здесь и с заларинскими татарами, прибывшими сюда в основном в годы столыпинских реформ.

# ГАЛӘМ-Е ИСЛАМ

*Габдерәшит Ибраһимов*

## Габдерәшит Ибраһимовның «Галәм-е Ислам» сәяхәтнамәсендә Иркутск шәһәре

Габдерәшит Ибраһимов (1857–1944) – Россиянең төрки халыклары һәм Ислам тарихларында сизелерлек эз калдырган шәхес. Белем бирү мәсьәләләрендә заманча яңалыклар яклы булган бу дин галиме, газета һәм журналлар оештыручы, язучы, татарлардан беренче сәясәтче һәм бик күп җирләр гизгән сәяхәтче буларак та билгеле. Г. Ибраһимовның үзе күргән җирләр һәм бу сәяхәтләре вакытында аралашкан кешеләр турында язганнары шул заманда ук укучыларда кызыксыну уяткан.

Биредә без аның «Галәм-е Ислам» дип аталган сәяхәтнамәсеннән «Иркутск» исеме белән бирелгән бер бүлекне татар теленә тәрҗемәдә бирәчәкбез. Ике өлештән торган бу сәяхәтнамәнең беренче китабы һиҗри ел исәбе белән 1328 елда (милади 1910 ел), икенчесе 1331 елда (милади 1913 ел) Истанбулда басылган. Гарәп хәрефләре һәм галимгә хас «куе» госманлы теле белән язылган әлеге хезмәтне Төркиядә ике тапкыр хәзерге төрек теленә күчереп бастырып чыгардылар. 1987 елдагы басма – Мехмет Паксу, 2012 елгысы Әртугрул Өзалп тарафыннан әзерләнгән. Без сәяхәтнамәнең тәрҗемәсен әзерләгәндә «Галәм-е Ислам»ның асыл басмасыннан файдаландык, Төркиядә чыккан басмаларга да мөрәҗәгать итәргә туры килде.

Габдерәшит Ибраһимов 1907 елның ахырында беренче сәяхәтенә кузгала, ул Урта Азия һәм казакъ далаларын, шул тирәдәге шәһәрләрне гизеп, Себергә, аннан Казанга килә. 1908 елның 16 сентябрендә янәдән зур сәяхәткә чыга. Уфа, Чиләбе, Кызылъяр (Петропавловск), Омск, Томск, Иркутск шәһәрләре аша Монголиягә, аннан Маньчжуриягә, Харбинга, соңрак Владивостокка барып җитә. Берничә көн Владивостокта торганнан соң, пароходка утырып Япониягә китә. Сәяхәтенең шактый өлешен ул Япониядә уздыра. 1909 елның июнендә Кореяга, аннан Кытайга, Сингапурга һәм Һиндстанга юл ала. 1910 елда Хиҗазга барып хаҗ кыла, аннан соң Бәйрут аша Истанбулга килә һәм шунда төпләнә.

«Галәм-е Ислам»ның асыл нөсхәсе китапларының күләмнәре буенча бертөрле түгел: беренчесе күпкә зуррак. Габдерәшит Ибраһимов сәяхәтнамәсенең беренче томында Япониядән соң әле Корея һәм Кытайдагы сәяхәте турында да язып, аны Сингапурга килүе белән тәмамлый. Борынгы китапларның форматы зур. Хәзерге төрек теленә күчереп бастырганда, тәрҗемә авторлары китапны үзләренчә бүлгәннәр һәм якынча бертигез күләмле ике китап барлыкка килгән. Мәсәлән, Әртугрул Өзалп хәзерләгән басманың беренче китабы – 656, икенчесе 631 битле. Бу бүленештә беренче китап Япония сәяхәте белән тәмамлана. Корея, Кытай, Сингапур, Һиндстан, Гарәбстан сәяхәте һәм Госманлы дәүләтенә килеше икенче китапка кертелгән.

Менә шул яңа бүленештә сәяхәтнамәнең беренче зур бүлеге татар теленә тәрҗемә ителде, китап хәлендә басылып, тиздән хөрмәтле укучыларыбызның кулына барып ирешер, дигән өметтә калабыз.

Габдерәшит Ибраһимов үзе барып күргән җирләрен чуар бизәкләрсез, күрешеп сөйләшкән кешеләрен чын ихласлык белән тасвирлаган; күреп, ишетеп белгәннәрен, еш кына, татар милләтенең һәм мөселман халыкларының вазгыяте белән чагыштырып, күзәтүләрдән туган үз фикерләрен дә теркәп барган. Язылганнан һәм беренче тапкыр басылып чыкканнан соң инде бер гасырдан артык вакыт үтсә дә, сәяхәтнамә әле бүген дә халкыбыз тарихы өчен кыйммәтен югалтмаган.

Ачинск шәһәрчегеннән Габдерәшит Ибраһимов Иркутск шәһәренә юл тота. Ачинск турында язганда, 40–50 мөселман йорты булган бу кечкенә шәһәрчекнең дә бер мәдрәсәсе һәм бер мәктәбе булуын әйтеп, моңа шөкер итәргә кирәклеген искәртә. «Себердә әллә ничә йөз йортлы рус авыллары аша үттем, күбесендә чиркәү дә, мәктәп тә юк иде», – ди. Түбәндә тәкъдим ителгән өзектә Иркутск һәм аның әйләнә-тирәсендәге авыллар турында сүз бара.

*Асия Рәхимова*

## Галәм-е Ислам[1]

Мин Ачинскидан Красный яр аша Иркутск шәһәренә юл тоттым. 1176 чакрым ара узасы. Мондый озын юлларда көне-төне бару кешене бик ялыктыра. Себер тимер юлы бик төзек, вагоннары да яңа система буенча төзелгән, шулай булуга да карамастан, төрмәдә утырган кеше кебек, кечкенә бүлмә эчендә вакыт үткәрү ансат түгел, бигрәк тә «куян»нар да күп булса, әле тагын ул «куян»нар арасында сәрхүшләр дә булса, Алла сакласын, адәм баласына һәртөрле куркыныч янавы мөмкин: йокы да күрмәячәк, станцияләрдә ашарга да барып килә алмаячак. Себер тимер юлында поездлар эч пошыргыч дәрәҗәдә акрын йөриләр, бер сәгатьтә егерме чакрым юл үтәләр: бик кыен.

20 ноябрь: Иртән иртүк Иркутск шәһәренә килеп җиттем. Күптәнге дустым Шәйхулла әфәнде һәм башка кайбер дуслар, укытучылар станциядә каршы алдылар. Күрешеп, бераз сөйләшеп торганнан соң, Ангара елгасы аркылы салынган күпердән чыгып, Шәйхулла әфәнденең өенә юнәлдек. Һава шулкадәр салкын: мин соңгы вакытларда бу кадәр салкынны күргәнем булмады. Ләкин Ангара елгасы әле дә боз белән капланмаган иде. 35 градус суык булып та, елга өстенә боз катмаган булса, әлбәттә, аптырарсың. Безнең Көнбатыш Себердә 12–14 градус суык булуга, елга өстеннән юл салына, атлар белән үтеп йөрерлек була.

[1] Габдерәшит Ибраһимовның «Галәм-е Ислам» (Ислам дөньясы) китабыннан өзек.

Шәйхулла әфәнде: «Бу әле чын салкыннар түгел», – ди, мин исә, шулкадәр нык суык булуга гаҗәпләнүемдә дәвам итәм. Иркутск халкы өчен 30 градус салкынлык та берни түгел икән.

Ул көнне кичкә кадәр Шәйхулла әфәнденең өендә кунак булдым. Кич җиткәч, Шәйхулла әфәнде миңа Диков кунакханәсендә номер әзерләткән икән, шунда киттем. Бик күп җирләрдән хатлар килгән иде. Аларны карап чыкканнан соң, тиешлеләренә җавап та яздым.

## Иркутск

Бу шәһәр элегрәк Себернең зур сәүдә үзәге булган. Себер тимер юлы төзелгәнгә кадәр, кышкы зәмһәрир суыкларында да Русиянең эчке төбәкләреннән, Көнбатыш Себердән, Кытайдан һәм Монголиядән бирегә күпләп сәүдәгәрләр килә һәм зур сәүдәләр алып бара торган булганнар.

Бүгенге көндә Иркутск тагын да төзегрәк шәһәр булса да, сәүдә ягыннан элеккеге әһәмияте калмаган. Чөнки элек биредә Мәскәү һәм Русия маллары китереп сатылган, Кытай товарлары да булган. Хәзер исә, тимер юл булганга, Мәскәү маллары Пекинга кадәр китә, Кытай маллары исә Петербургка кадәр килә. Шул сәбәпле, Иркутск базары сәүдә үзәге булу ягыннан тынып калган һәм, гомумән, бөтен Себер базары һаман да артка чигенә бара.

### Ике каһарман

Иркутск шәһәрендә мине кунак иткән дустым Шәйхулла әфәнде белән аның абыйсы Заһидулла әфәнде турында бераз мәгълүмат бирергә телим[1].

Үзләрен үзләре кеше иткән бу ике каһарманның укып белем ала алмаулары, гади ата балалары булганнарына күрә, гаеп ителмәс, дип уйлыйм. Тик боларның икесе дә – бик тырыш, җитди һәм саф күңелле кешеләр, чын-чынлап каһарманнар.

---

[1] Бу шәхесләр турында түбәндәге чыганаклардан өстәмә мәгълүмат алырга мөмкин: *Тимершин И.* Акъегет авылы тарихы сәхифәләре. Казан, 2001. – 164 б.; *Айзат Шәймәрдән.* Татар миллионеры Шәфигуллин // Безнең гәҗит. 2011. №8 (2 март) (тәрҗ. иск.).

Туган җирләре – Казан губернасы Цивиль өязенең Акъегет авылы. Заһидулла әфәнде яшь чагында туган җирен калдырып, Ерак Көнчыгышка киткән. Моннан 40–50 еллар элек Яфа лимоннарын Иркутскида берсен 12 тиенгә кадәр саткан кеше бу! Аннары ул Иркутскида урнашып калган. Соңрак Шәйхулла әфәнде дә абыйсына ияргән. Эшкә беренче башлап Заһидулла әфәнде тотынган булса да, бүгенге көндә бөтен Себер сәүдәсен үз кулына алып, Себер якларында яшәп калган кеше  Шәйхулла әфәнде.

Бу ике тырыш затның берсе Себердә, икенчесе исә үз туган җирендә милләт балаларына һәм ислам диненә хезмәт итүне үз өсләренә алганнар. Укымышсызлыклары сәбәпле үзләре күргән авырлыкларны яшь буын күрмәсен, дигәннәр. Алар кичергән кыенлыклар яшь буында да кабатлана калса – моны вөҗданнары кабул итмәячәген аңлаганнар. Һәр икесе дә үзләре яшәгән җирдә мәктәпләр ачу, мәчетләр төзү өчен байлыкларыннан бик зур өлеш чыгарганнар, йөзләрчә-меңнәрчә мөселман баласын – күпме үксез, күпме ятим бар, һәммәсен бер урынга җыеп, чыгымнарын үз кесәләреннән түләп, бу балаларны укытканнар, тәрбияләгәннәр һәм әле дә бу эшне дәвам итәләр. Бүген, кая гына барсаң да, Шәйхулла әфәнде мәктәп-мәдрәсәсе бар, Заһидулла әфәнде мәчете бар. Бүгенге көндә Иркутск шәһәрендә эшләп торган изге мәчетне төзү һәм ачу, мәсәлән, якынча 30 000 сумга төшкән. Иркутскидагы ир балалар мәктәбендә 40–50 тирәсе мөселман баласы укыса, кыз балалар мәктәбендә укучыларның саны 70 кә җитә. Сабый яшьтәге кыз балалар да бар, күбесе ятим, үксез. Боларның бөтен чыгымнарын Шәйхулла әфәнде үз кесәсеннән түли, белем-тәрбия алулары өчен бик күп акча тота.

Бүгенге көндә Шәйхулла әфәнде Себердә шундый дан казанган ки, бөтен Себер татарлары бу елларда туган ир балаларына, бәхетле исем булсын дип, Шәйхулла исеме кушалар. Бу шәхеснең танылганлыгы бары тик татарлар белән генә дә чикләнми, руслар, яһүдләр, бурятлар, якутлар да бу кешегә изге кешегә караган кебек карыйлар. Иркутск шәһәрендә ничә банк филиалы булса, ул шуларның һәммәсенең дә әгъзасы, күпме хәер җәмгыяте булса – бөтенесендә әгъза, Ислам хәер җәмгыятенең исә рәисе булып тора.

Заһидулла әфәнде исә, үз туган җирендә нәкъ шулай ук данлыклы, ул да нәкъ шундый ук хезмәт күрсәтә. Бу ике каһарман яшь буынга шундый нәсыйхәт бирә: «Безнең кебек җаһил калмагыз!». Мин биредә алар турында бик аз гына яздым. Әгәр аларның тәрҗемәи хәлләрен язарга уйласаң, бер китап булыр иде. Мин бу кешеләрнең мөселман халкына күрсәткән хезмәтләренең бер истәлеге булсын өчен, бу ике кардәшнең рәсемнәрен биредә газиз укучыларымның игътибарына тәкъдим итәм.



Иркутск мөселманнары арасында бай кешеләр аз булса да, тырыш кешеләр бик күп. Шәһәрдә кеше саны меңгә дә тулмаган бер мөселман мәхәлләсе бар. Бу мәхәлләдә бик югары дәрәҗәдә оештырылган мәктәп һәм моннан тыш, 10000 сумга якын акчасы булган хәер җәмгыяте дә бар.

### Рухани белән әңгәмә

Мин биредә шәһәрнең алдынгы кешеләре һәм әдипләреннән берничә кеше белән таныштым. Танылган православие рухание Иннокентий Подгорбунский[1] җәнаплары да – шуларның берсе.

[1] Подгорбунский Иннокентий Александрович (1862–1913) – священник, педагог, галим, туган якны өйрәнүче белгеч, фотограф. Казанда Духовный семинария бетергәннән соң, Иркутскидагы Духовный семинариягә укытучы итеп җибәрелә (тәрж. иск.).

Бу зат белән күп тапкыр күрешеп сөйләштем һәм Монголия турында аннан шактый мәгълүмат алдым.

Иннокентий җәнаплары священник булу белән бергә олы әдип тә: инглизчә, французча, алманчадан (немецча) тыш, бик яхшы монголча да белә, бераз татарча да аңлый. Диннән күбрәк әдәбиятка хезмәт итүче бу шәхес рухка караганда күбрәк матдәне хөрмәт итә. Моннан өч-дүрт ел элек ул «Русча-монголча сүзлек» төзегән һәм бастырып чыгарган[1].

Бу затның фикеренә күрә, дөньяда милләтләрнең тынычлыгын качырачак бер нәрсә булса, бу – христианлык камчысы, христиан дин галимнәренең үзләре хөрмәт итмәгән нәрсәне башкаларга тәкъдим итүләре.

Подгорбунский Монголия турында шуларны сөйләде:

*Монголлар христианлыкны кабул итү белән юкка чыга барачаклар, чөнки бүгенге христианлык, дин исемен кулланып, монголлар арасында әхлак бозыклыгы орлыгын чәчә. Миссионерлар, халыкны мәгълүмат белән күндерә алмаганга, теләсә нинди начарлык китереп чыгуга сәбәп булалар. Монголларны да, маньчжурларны да эчәргә өйрәтеп бәлага төшерделәр. Бүген бөтен Монголиядә әхлак бозыклыгы зур тизлек белән арта бара. Моның нәтиҗәсендә бурятлар, якутлар, Минусия татарларының нәселләре корый бара. Бу җирләрдә генә түгел, хәтта төньякка таба да шулай, иштәкләр, самоедлар да безнең руслар белән элемтәгә кергәннән соң, юкка чыга башлауга дучар ителгәннәр.*

*Нинди генә дин турында сүз барса да, кешеләрнең дингә булган ихтыяҗлары күркәм әхлак өчендер. Югыйсә, әхлак бозыклыгы белән дин бервакытта да берләшә алмаячак.*

Подгорбунский җәнаплары – Монголия турында гаять күп мәгълүмат туплаган белгеч. Бу илне адым-адым гизгән, һәр җәһәттән бик җентекләп күздән кичергән, ул гына да түгел, әдәбиятыннан да мәгълүматлы. Шуңа күрә бу шәхеснең белеме

[1] Будда дине һәм шаманизм белгече И.А. Подгорбунскийның «Русско-монголо-бурятский словарь» исемле сүзлеге турында сүз бара. Гомеренең соңгы елларында күбесенчә монгол һәм бурят телләрен өйрәнү белән шөгыльләнгән галим бу сүзлекне төзеп, 1908 елда бастыра (тәрҗ. иск.).

бик киң, үзе күпме генә дин кешесе булса да, үтә фанат булмаганга, ул сөйләгән сүзләрнең дөреслеккә туры килүендә шик юк.

Подгорбунский җәнапларының фикеренчә, лама мәзһәбендә әхлак тәрбиясе күпкә тәртипле, табигатькә күбрәк ярашлы, тик ламаларның үлеләрен җирләмичә, утта да яндырмыйча, турыдан-туры далага атулары һәм җәсәднең, ерткыч җанварлар күреп ала алмаган очракта, юл өстендә айларча аунап ятуы әхлакка бик начар йогынты ясый. Гомуми саулыкка зарар китерү ихтималы да бар.

Шулай булса да, лама мәзһәбендә ялган, золым, коллар хокукын, хайваннар хакын бозу һәм җан ияләрен юк итү катгый рәвештә хәрәм санала. Иннокентий Подгорбунский боларны мәзһәбнең яхшы яклары дип саный, тик ирләр җенес әгъзасын «бар итүче» сыйфатында кабул күрүне дин исеменнән әмер итүнең урынсыз булуын бик әрнеп белдерде.

## Расатханә, ягъни обсерватория

Мин аннан соң Иркутск расатханәсен барып карадым. Биредә искә алып үтәрлек берни булмаса да, расатханәнең нәкъ менә Иркутск шәһәрендә булуы үзе билгеләп үтәргә лаеклы. Бигрәк тә без – мөселманнар өчен бу югары белем үз малыбыз дәрәҗәсендә була торып, бүген Иркутскида бар, ә менә Палестинада юк. Кызганыч димичә, ни дисең?! Мондый югары белемнәрне күргән саен, мирасын югалткан үксез кебек елаудан башка бер чарабыз да юк.

Расатханә мөдире Шостакович[1] белән күрешеп сөйләштем, бераз фикер алыштык. Хөкүмәтнең басым ясавы аркасында расатханәләрнең зыян күрүе турында әйтте.

## Бурятларның нәселләренең корый башлавы, халыкның юкка чыга баруы һәм моның сәбәпләре

Бурят халкының алдынгы кешесе – доктор Турабачев белән күрешеп сөйләштем. Бу кеше милләте буенча бурят булса да, ба-

[1] Шостакович Владимир Болеславович (1870–1942) – геофизик, Иркутск магнитлы метеорология обсерваториясенең директоры, Иркутск дәүләт университеты профессоры (тәрҗ. иск.).

лачагында чукындырылган. Аннары ул Петербург университетын тәмамлаган, доктор. Бурят халкының язмышы турында бик нык уйлана торган бу кеше, сөйләшү арасында болай диде:

– Болай барса, безнең бурятлар тәмам юкка чыгачак, көн үткән саен нәсел-нәсәбебез югала, моны туктату өчен бер чара табарга телим, булмый.

– Доктор булуыгызның файдасын кайчан күрә башларсыз икән соң?

– Минем доктор булуымның бу авыруга бернинди файдасы да тимәячәк. Ә менә рухларны дәвалау ысулына мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булырбыз, ахры.

– Безнең татарларда борынгылар моны күп тапкырлар сынаганнар: бер ыруда нәсел өзелә башладымы, башка ыру белән кан катыштырганнар, өйләнешкәннәр. Сез дә моны сынап карагыз.

– Әйе, бу фикер минем күңелгә ятышлы. Бу чынлап та яхшы ысул булыр, дип уйлыйм. Башка чара уйлап торасы да юк. Әмма кем белән өйләнешергә соң? Менә бу читен мәсьәлә.

– Руслар белән өйләнешүне сынап карагыз.

– Нәселемнең бөтенләй юкка чыгачагын аермачык белгән очракта да, руслар белән өйләнешүне кабул итә алмаячакмын.

– Инде христианлыкны кабул иткәнсез, өйләнешүне кабул итү җиңелрәк түгел мени?

– Мин христианлыкны кабул итмәгәнмен, мине кабул иттергәннәр. Мондый хәлдән соң, әлбәттә, җиңел түгел.

– Японнар белән мөнәсәбәт корырга тырышып карагыз. Тарихи динегез буенча да якынлыгыгыз бар. Бурятлар да бу фикерне хупларлар, дип уйлыйм.

– Ах, бу насыйп булса, моңа, шөбһәсез, бөтен бурят халкы кушылачак. Тик бу – хәтта хөкүмәт каршы чыкмаса да, авыр мәсьәлә.

– Алайса, японнар да кабул итсә, дип әйтергә кирәк.

### Иркутск авыллары

Мин Иркутск шәһәрендә яшәгәндә, гадәтем буенча, якынтирә авылларны да йөреп чыктым. Мәктәпләренә бардым, кая

гына барсам да, һәр җирдә уяныш галәмәте күрдем. Иркутск әйләнәсендәге авыллар һәммәсе дә диярлек сөрген срогы тулганнан соң, чарасызлыктан биредә төпләнеп калучылардан гыйбарәт икән. Димәк болар гаеплеләр һәм сөрелгән кешеләрдән оешкан авыллар булып чыга. Шул ук вакытта, дин юлындагы тырышлыкларының күрсәткече буларак, боларның да дини мәктәпләре, мәчетләре бар.

Сөрген мөддәтләрен (срокларын) тутырган гаеплеләр генә түгел, хәтта «каторга» дип аталган җәзага тартылган кешеләр дә үзләренә аерым мәктәп һәм мәчет ачканнар.

**Александр каторгасы**

Бу гаять зур, эчендә 25 меңгә якын каторжанны сыйдырган төрмәсе дә булган каторга дигән җирне шәһәр дип тә атарга мөмкин булыр иде. Биредә яшәүчеләрнең – төрмә сакчылары һәм анда эшләүче башка хезмәткәрләрдән тыш – һәммәсе җинаятьче һәм кеше хокукларыннан мәхрүм ителгән бәхетсезләр, ләкин барыбер дә безнең кебек үк кешеләр. Бу җинаятьчеләр, кеше үтерүчеләр, инсани хокуклардан мәхрүм ителгәннәр, дип хөкем йөртелгән кешеләр арасында безнең дин кардәшләребез, мөселманнар да бар. Шундый хәлдә дә, болар дини тырышлыклары белән үз араларыннан берәүне имам итеп сайлап куеп, гаиләсе, бала-чагасы белән бергә килгәннәрнең балаларына ислам динен өйрәтәләр. Имам әфәнде дә бу гаеплеләрнең берсе, шулай булса да, дин таләп иткәнчә, имамлык урынын яклап, саклап тора. Менә шул Александр каторгасы имамы Мифтахетдин мулла гаять яхшы кеше булып чыкты. Мәгълүматы, белеме бик тирән булмаса да, дине бөтен, нык, какшамас, бик эшчән һәм тырыш шәхес. Җинаятьчеләрне бергә җыеп, динебезгә хезмәт итә, җаваплы вазифа башкара.

Александр каторгасына һәр ел саен биш меңнән алып сигез меңгә кадәр яңа җинаятьче килә, өч-дүрт мең җинаятьче срогын тутырып аннан чыга һәм әйләнә-тирәгә авылларга илтеп урнаштырыла. Килгән җинаятьче саны елдан-ел арта бара икән. Төрмәдә әхлак бозыклыгы бик күп, бер-берсен үтерү, эчеп үлү

бигрәк тә күп, ди. Мин Усолье дигән авылда хезмәттә булганнардан 700–800 кешене эш вакытында күрдем, 35 градус суыкта эшлиләр иде. Күкрәкләре ачык, башларыннан күтәрелә торган пар өсләрендә томанга әйләнгән. Бу җир күмер шахтасы булганга, йөзләре дә су күрмәгәнгә, котчыккыч, боларны кеше кыяфәтендәге ерткыч җанвар, дип уйларлык иде.

Бу каторжаннар арасында гаять диндар, тәкъва кешеләр дә очрый. Боларның җинаятьләре дә, дөресен генә әйткәндә, диннәре хакына күрсәткән ныклыклары белән бәйле. Шулай ук, гаять мәгълүматлы сәяси каторжан руслар да бар. Ләкин бу җирләрнең тәэсирендә боларның аңлылыклары уйсызлыкка, бәхетләре бәхетсезлеккә әйләнеп, инсан булуларыннан бары тик исемнәре генә калган. Сәяси тоткыннар арасында 16–18 ел каторгада калган кешеләр булуын сөйлиләр.

Мин биредә бу каторжаннарның рәсемнәрен дә гыйбрәт алып карар өчен куям[1].



[1] Г. Ибраһимов китабына кергән сурәтләр бик тонык, шактый бозылган, шуңа күрә укучыларда күзаллау булдыру максатыннан, Александровский централ төрмәсенең шул чорын чагылдырган башка фотосурәтләр белән алыштырдык. Беренче һәм соңгы фотолар китаптан алынды.




Болар арасында шул авыр хезмәтләрдә хатын-кыз да бар һәм боларга хайваннарга эшләтергә кирәкле эшне эшләтәләр. Аларның да рәсемнәрен куям.



Каторга җире – авыр хезмәт белән җәзалау урыны, руслар аңа «каторжная работа» диләр, ул хезмәттәге кешеләргә «каторжанин» диләр. Үзәгендә Александр исемендәге төрмә тора. Биредә кулы эш белгән эшчеләр өчен бик зур остаханәләр бар. Җинаятьченең нинди хезмәт тәҗрибәсе булса, шул эштә эшләттерелә: өс киеме тегүчеләр, аяк киеме тегүчеләр, балта осталары, тимерчеләр, бизәнү әйберләре ясаучы осталар һ.б. гел шул үз эшләрендә эшлиләр. Әгәр инде андый эшләргә осталыклары булмаса, авыр хезмәт башкаралар.

Бу төрмәләрдә җитештерелгән маллар бик зур табыш китерә. Шул рәвешле, хезмәтенә күрә һәммә кешегә хезмәт хакы билгеләнгән һәм ул төрмә казнасында җыелып бара. Аның өчтән бере – хөкүмәткә дигән акча, тагын бер өчтән бере төрмә чыгымнарына тотыла, калган өчтән бер өлеш җинаятьче исеменә җыелып бара, каторга срогы тулып, төрмәдән чыкканда, үзенә бирелә. Болар арасында кайбер осталар төрмәдән азат булганда, шактый ишле акча белән чыгалар. 3–5 мең сум акча белән чыгучылар да булгалый, ди. Соңыннан үз теләге белән эш башлап җибәреп, байлык туплаган кешеләр дә бар икән. Тик бу кешеләр туган җирләренә кайтып китә алмыйлар, бу тыелган.

Бу кешеләр үзләре турында «университет студенты без» диләр. Болар арасында гаять сәләтле кешеләр дә аз түгел. Бер каторжан белән күрештем, арабызда шундый сөйләшү булды:

– Бу каторгада кешеләрне авыр хезмәтләрдә эшләтәләр, шулаймы?

– Минем фикеремчә, биредә каторга юк. Каторга беләсезме кемнәр өчен? Сәясиләр өчен. Чөнки алар үз туган якларында мөхтәрәм затлар булганнар, фикерләре белән хезмәт иткәннәр. Тик безнең кебек туган якларында да ач-ялангач яшәгән кешеләргә монда әле яхшырак та. Һич югы, монда безгә эш бар. Безнең өчен каторга дип, монда бары тик бер нәрсәне әйтергә мөмкин: ул да булса – туган җиребез һәм гаиләбездән аерым булу. Гаиләсен дә янына китергәннәр өчен каторга бөтенләй юк.

– Сез бу хәлегездән канәгать, димәк.

– Минем уемны тырмалый торган бер нәрсә бар: без гөнаһыбыз өчен җәзага тартылдык. Җәза диделәр, туган җиребездән сөргенгә сөрделәр. Моны кабул итәргә була, моңа минем дә башым җитә. Тик көн күрүе минем җилкәмдә булган гаиләм бар иде, инде минем аркамда алар ач калды, аларның гөнаһлары ни? Аларга карата бу золым һәм хаксызлык түгелме? Алар тик торганда ятим калдылар. Менә бу гаделлеккә туры килми, дип уйлыйм.

Каторжанның бу сүзләрен ошаттым:

– Бу турыда нинди фикерләрегез бар? Ничек булса, гаделлеккә туры килгән булыр иде? – дип сорадым.

– Минемчә, туган җиреннән сөрелү – җинаятьче өчен җәза түгел, ул аерылу аркасында башта бераз сагынып күңелсезләнсә, кайгырса да, бирегә килеп урнашкач, оныта башлый. Ә менә гаиләсе өчен бу – бик зур җәза. Хөкүмәтләрнең максаты да шул: кеше аз яши торган җирләрне тутыру. Сөрген җәзасы булган дәүләтләрдә гомумән җинаять күп була, бу исә – мәгълүм һәм үзгәрмәслек нык урнашкан нәрсә. Минем фикеремчә, җинаятьчегә авыр җәза бирергә кирәк, ләкин бу гаиләсенә яшәр өчен акча җибәрттерү шарты белән булырга тиеш. Минем өч яшьлек, биш яшьлек балаларым калды, аларның караучысы юк, шулай булгач, тәрбия күрмәячәкләр, белем алмаячаклар. Мин хулиган идем, ләкин үз хәлемнән үзем канәгать идем, дип әйтә алмыйм. Шуңа күрә, әлбәттә, ичмаса балаларым минем көнгә калмасын, дип, ничек булса да, аларны мәктәпкә биреп укытыр идем. Инде мин сөргенгә сөрелдем, тик минем урыныма тагын ике хулиган җитешәчәк. Гомумән, биредә җинаятьчеләрнең елдан-ел артуының сәбәбе дә мин әйткәннәр белән бәйле.

– Менә бу сүзләр минем игътибарымны бик нык җәлеп итте. Тик әңгәмәне дәвам итәргә мөмкинлек булмады, шул арада сакчы килеп, безнең сөйләшүне тыйды.

– Мин шул рәвешле каторжан авылларын карап йөргәннән соң, кире Иркутскига кайтып киттем.

**Иркутск музее**

Беркөнне музейны карарга бардым. Иркутск музее тулысынча Көнчыгыш яшәеше белән бәйле әсәрләрдән оешкан иде. Бигрәк тә этнография бүлеге бик бай. Буддизм һәм шаманизмга караган күпсанлы сәер әсәр бар. «Бурхан» ди атала торган җисемләштерелгән тәңренең нindие генә юк, чын бәясен билгеләп бетереп булмаслык кыйммәтле ташлар белән бизәлгәннәре дә бар. Музейга барлыгы 158 бурхан куелган.

Моннан тыш, монгол язуы белән язылган төрле-төрле догалар куелган. Мәсәлән, бала еламасын өчен, авырудан саклану өчен, күз тимәсен өчен аерым-аерым догалар бар. Сәнгать осталары язып калдырган мактаулы бәяләмәләрдән дә аңлашылганча, болар сәнгати югарылыкта язылганнар. Барысы да монгол язмалары.

Минем игътибарымны җәлеп иткән нәрсәләрдән берничәсе турында биредә дә язып үтәчәкмен. Бер агач тамырының тармакларына 11 кеше рәсеме урнаштырылган. Һәммәсе дә бер үк агачның тамырлары. Хамба Ламаның аңлатуы буенча, бу рәсемнәр Будда һәм аның укучыларының рәсемнәре икән. Тагын берсе – бер бурят даруханәсе, тәлинкәле кечкенә үлчәүләре дә куелган. 212 ел элек ясалган хәреф басу калыбы, ул вакытларда ук Монголиядә басмаханә булганлыкка дәлил булып тора. Каен тузыннан ясалган көймә, ишкәкләре нәкъ безнең Истанбул каекларының ишкәкләрен хәтерләтә.  Бу бик гаҗәеп сәнгать. Көймә биш кешене алып су өстендә йөзә ала, ә үзенең авырлыгы, ишкәкләрен санамаганда, якынча 28,5 кг. Бу көймә Минусия татарларыннан алынган, алар андый көймәләрне Енисей, Ирбә елгаларында кулланалар икән.

Бу музейда Көнчыгыштагы тормыш белән бәйле башка әһәмиятле әсәрләр дә бар, ләкин алар, музейның ачылуына инде 25 ел үткән булса да, әлегә тәртипкә салынмаганнар.

**Госманлы Милләт Мәҗлесе һәм Иркутск мөселманнары**

Иркутск шәһәрендә 5 декабрь җомга көнне кичке телеграф белән Истанбулдан Милли Мәҗлеснең ачылуы турында хәбәр килде. Шул кичен үк бөтен Иркутск мөселманнары бергә

җыелдылар, чыгышлар ясап, шатлыкларын белдерделәр, дога кылдылар. Тик ул җитди һәм самими изге теләкләрен һәм шатлыкларын Милләт Мәҗлесенә телеграф җибәреп, тәбрикләрен ирештерә алмадылар, моңа хөкүмәт басымы астында булган һәм ул кушканча эш итүче телеграф хезмәткәрләре каршы төште. Ни генә булса да, Истанбулдагы мөселман кардәшләренең гомерлек хөррият бәйрәмнәренә, тирәннәрдә әрнегән сызлаулы йөрәк хисләре белән бағланып булса да катнаштылар.

Шунысына шөкер итәргә кирәк, бөтен Госманлы мөселман кардәшләребезнең иртән йөрәкләрендә туган хөррият сөенече кичен Иркутск мөселманнарының йөрәкләрендә дә балкыды. Гүя, чыбыксыз телеграфлар йөрәкләрне бергә бәйләде, ул көнне Иркутск мөселманнарында күргән сөенечне бәйнә-бәйнә язарга уйласам, бу кәгазь битләре генә җитмәс иде. Себер сәяхәтем белән Госманлы Милли Мәҗлесе арасындагы бәйләнешне уйлап кына, бу кадәре белән чикләнәм.

Иркутск шәһәрендә 15 көн торганнан соң, Югары Удин (Верхнеудинск) шәһәренә юл тоттым. Биредә сәфәрем Байкал күле яныннан үтсә дә, төн караңгылыгына туры килгәнгә, берни дә күрә алмадым. Бары тик вагон эчендә утырып, ул куркыныч туннельләрдән үтүебезне тойдым. Байкалны әйләндереп алган матур табигатьне күрү безгә насыйп булмады.

# МЕЦЕНАТ ШӘЙХУЛЛА ШӘФИГУЛЛИННЫҢ ИРКУТСК ТАТАРЛАРЫ ТОРМЫШЫНДА ТОТКАН УРЫНЫ

*Олег Хисамов*
*Илһам Гомәров*
*Илсөяр Закирова*

Шәйхулла Шәфигуллинның тормыш юлы һәм эшчәнлеге белән кызыксыну 2018 елның июнь аенда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан халыкның милли мәдәниятен һәм рухи байлыгын өйрәнү һәм барлау максаты белән Иркутск өлкәсенә оештырылган комплекслы экспедиция вакытында башланды. Төгәлрәк әйткәндә, әлеге мәкаләне язарга экспедиция вакытында табылган бер фоторәсем этәргеч бирде. Экспедиция Иркутск өлкәсенең Усолье шәһәрендә эшләгән вакытта бу фотоны шушы шәһәрдә яшәүче Мөхәммәдиева Мәүлидә апа алып килде. Мәүлидә апада Иркутск татарларының тормышын чагылдырган фотолар тагын да бар, әмма бу фото үзенең сыйфаты белән дә, сурәттә тасвирланган кешеләр, вакыйгасы белән дә игътибарны тартты.

Фоторәсемдә 1926 елда Иркутск мәчете бинасында имтихан биргән укучылар һәм имтихан алган укытучылар сурәтләнгән. Ысулы җәдит мәктәбендә һәр яз имтихан бирү, бер еллык алган белемне тикшерү кабул ителгән була. Фотода укучылар да, укытучылар да ярымтүгәрәк ясап тезелгән өстәлләр артында утырган. Уртада имтиханның датасы һәм имтихан алучыларның исем-фамилиясе язылган плакат эленгән. Бу язма түбәндәгедән

гыйбарәт: «1926 сәнә 16 май. Имтихан комиссиясе әгъзалары: I – комиссиянең рәисе Вафа Вәлишев, II – милләт хадиме Исмәгыйль Мөфтизадә, III – дини мөгаллим Нурылгаян Закири, IV – Шәйхелислам Әхмәтҗанов, V – Әгъмәл Җәлалетдинов, VI – икенче сафта мәхәллә идарәсе әгъзалары».

Фотога кергән тагын бер плакатта Коръәннең «Әль-Гыймран» сүрәсендәге Мәрьям Ана искә алынган 37 аятьтән өзек язылган.

Фото Иркутск мәчетенең эчке күренешен саклый, һәр кешенең йөзе ачык күренә, кием-салым турында да мәгълүмат аларга мөмкин. Укучы кызларның башында энҗе белән чиккән затлы калфаклар, калфак өстеннән ефәк шәл салынган. Ир балаларның башларында хәтфә кәләпүш. Өлкәннәр, нигездә, европача киенгән. Һәр кешенең, һәр баланың йөзе җитди, шул ук вккытта йөз төзелешләре камил, үз-үзләренен тотышларында затлылык бар.

Шушы фотога бәйле рәвештә Иркутск мәчете тарихы, мәдрәсәләр белән кызыксына башладык. Иркутск шәһәрендә яшәүче информантларыбыз шәһәр мәчетен тумышлары белән Казан губернасының Акъегет авылыннан (Хәзерге Зеленодольск районы) булган Шәйхулла һәм Заһидулла Шәфигуллиннар салдыруын, аларның Иркутскида сәүдә белән шөгыльләнүе «Бертуган Шәфигуллиннар» дигән сәүдә йорты тотулары, баштарак җиләк-җимеш, төгәлрәге алма, соңрак мехлар, кием-салым белән сату итүләре турында сөйләделәр.

Татар халкының бөтен уку-укыту системасы аерым фидакярләр җилкәсендә булган Октябрь революциясенә кадәрге чорда бар гомерен халыкны агартуга багышлаган шәхесләр тормышы аеруча игътибарга лаек. Шундый шәхесләрнең берсе – фабрикант, беренче гильдия купец Шәйхулла Шәфигуллин. Әлеге олпат затның исеме үз чорында татар дөньясында яхшы мәгълүм була. Аның бертуганы Заһидулла Шәфигуллин турында язмалар шактый булса да, бүгенге көндә Шәйхулла Шәфигуллинны бик азлар гына белә. Бу мәкаләдә әлеге шәхес турында табылган мәгълүматларны бергә туплап, аның тормышы һәм эшчәнлеге белән укучыны таныштыруны максат итеп куйдык. Чыганак буларак аның хатлары, үтенеч-язулары, Иркутск елъязмалары,

истәлекләр, замандашларының хезмәтләре һәм экспедиция вакытында тупланган материаллар алынды.

Иркутск өлкәсендә татарлар югалып калмаган, алар, бер яктан, чисталыгы, эшчәнлеге белән башкаларга үрнәк булса, икенче яктан, динле булуы, белемгә омтылып яшәве белән дә күпләрне сокландырган, ихтирам казанган. Һәр авыл, төзелүенең беренче елында булмаса да, икенче яки өченче елында мәчет салырга һәм мәдрәсә ачарга тырышкан.

Г.И. Бобкова туплаган мәгълүматлар буенча, Иркутск губернасында Октябрь революциясенә кадәр 23 мәчет булган[1]. Иркутск өлкәсендә тәүге мәчетләр XIX гасырның беренче яртысында ачылган. В.П.Паршин үзенең «Описание пути от Иркутска до Москвы, составленное 1849 г.» дигән сәяхәтнамәсендә шушы вакытта Биликтуйда 120 йортның өчтән берендә татарлар яшәве, авылда агачтан салынган мәчет булуы турында яза[2].

Иркутскиның үзендә мәчет ачылу тарихы исә турыдан-туры бертуган Шәфигуллиннар исеме белән бәйле, ул XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башында Иркутскида яшәгән беренче гильдия купец, безнең мәкаләбезнең герое Шәйхулла Шәфигуллин тырышлыгы белән ачыла.

Шәйхулла Шәфигуллин турындагы беренче, иң кызыклы һәм әлегә кадәр фәндә билгеле булмаган чыганак – Акъегет авылы мәдрәсәсендә укыткан Гарифулла Хәйрулла улының 1948 елда язылган кулъязма истәлекләре[3]. Гарифулла Хәйрулла улы – 1896 елда, Заһидулла Шәфигуллин чакыру буенча Акъегет мәктәбенә[4] җәдитчә, ягъни яңа ысул белән укытырга килгән мөгаллим. Акъегет авылы мәдрәсәсе Тау ягында гына түгел, бөтен Казан губер-

---

[1] *Бобкова Г. И.* Татарские общины Иркутской губернии (конец XIX – начало XX в.): монография / Г. И. Бобкова. Иркутск : Изд-во Иркут. гос. ун-та, 2009. С. 134.

[2] *Паршин В.П.* Описание пути от Иркутска до Москвы, составленное в 1849 г. М., 1851. С. 14

[3] Авторларның шәхси архивы. Бүгенге көндә хезмәт гарәп шрифтыннан кириллицага күчерелеп, бастырып чыгару өчен әзерләнә.

[4] Гарифулла Хәйрулла улы *мәктәп* дип яза.

насына танылган ысулы җәдит мәдрәсәләрдән була. Кулъязма авторы аның үз чорында күз уңында булган уку йортларыннан икәнлеген искәртеп: «Бер елны имтиханга Казандан Галимҗан әл-Баруди хәзрәтләре һәм дә Борһанеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләре һәм «Йолдыз» мөхәррире Һади Максуди кебек олуг галимләр килеб, үзләре теләгәнчә укытыб караб, тәхсин вә әфаринләр кылдылар. Бер кышны Габдерәшит Ибраһимов белән Гобәйдулла Буби килеб, шәкертләрне үзләре сайлаб алыб, имтихан кылыб, зур рәхмәтләр укыб китделәр», – дип яза.

Акъегеттән киткәннән соң да Гарифулла Хәйрулла улы Шәфигуллиннар белән арасын өзми, ул Шәйхулла Шәфигуллинга якынрак, Иркутск губернасына күченә «1909 ел Забайкалга Верхний Удин каласына имам вә мөгаллим була».

Автор бертуган Шәфигуллиннар белән аралашып яши, истәлекләрендә үзе күргәннәрен яза, алар турында ишеткәннәрен дә файдалана. Истәлекләрдә күбрәк игътибар гаиләдәге олы бала булган Заһидулла Шәфигуллинга бирелә. Автор аның туган-үлгән елын һәм туган урынын төгәл күрсәтеп: «Заһидулла хаҗи Тау ягында Акъегет авылында 1840 елда туган. Вафат 1919 елда 28 майда, 15 рамазан шәрифдә»[1], – дип яза. Истәлек бертуган Шәфигуллиннарның гаиләсе, матди хәле турында язмадан башлана: «Заһидулла хаҗи белән Шәйхулла хаҗи – бертуганнар. Аталарындан ятим булыб бик фәкыйрь хәлдә калганлар. Аталары Шәфигулла бабай вафат булган көндән ашарларына икмәкләре булмагач, аталарындан мирас булып калган читекләрне күршеләренә закладка салыб, ярты икмәк алыб чыгыб тукланганлар. Аналары Сафура әби бик уңган, бик пакь, тормышны ярата торган булган. Шәфигулла бабадан бик кечкенә генә өе калган, шул өйне Сафура әби эчдән дә, тышдан да балчык белән сылаб, ап-пак итдереб акбур белән бик матур идеб агарта торган булган».

Автор юклыктан иза чиккән гаиләнең хәлен, уллары Заһидулланың сәүдә дөньясына кереп китүен бәян итә. Кулъязмага караганда, ул сәүдә эшенә 17–18 яшьләрендә керешә, «ана-

[1] Кулъязманың теле оригиналдагыча бирелә.

сы Сафура әбидән сораб бик зур фатиха алыб», беренче тапкыр Акъегеттән чыгып китә, башта Казанга, аннан Пермьгә, соңрак Барнаулга барып җитә. Барнаулда шырпыга кытлык булганын белеп, йорттан йортка кереп шырпы сата. Ягъни бик кечкенәдән башлап, үз көче белән аякка баса. Барнаулда ничек сатуга керешкәнен Заһидулла хаҗи үзе болай дип сөйли торган булган: «Шырпы предлагать идеп кергән йортдан, аягымда оек-чабата булганга күрә, куыб чыгаралар иде. Шуның өчен иң әүвәлге файдама ике сумга аягымга күн итек алыб кидем. Шундан соң йортларга кереб шырпы белән сату итәргә бик уңгай булды». Шырпыдан соң нәрсә сатканы, капиталны ничек туплаганы турында әлеге истәлектә төгәл мәгълүмат юк. Беренче капиталны туплаганнан соң, Омск, Томск якларына барып, пушнина белән сату итәргә керешә. Аннан соң Иркутскига барып йөри башлый. Бертуган энесе Шәйхулла да сәүдә эшенә кушыла. Шәйхулла Шәфигуллинның туган елы төгәл билгеле түгел, якынча 1857 ел[1] күрсәтелә. Иркутскига килгәндә, Шәйхуллага да 17 яшьләр була (1874 ел). Гарифулла Хәйрулла улы истәлекләрендәге һәр эпизод бертуган Шәфигуллиннар турында яхшырак белергә, аларны аңларга ярдәм итә.

Бертуганнар Иркутскига алма, лимон китерәләр, Себердән пушнина алып кайталар. Гарифулла Хәйрулла улы кулъязмасында Шәфигуллиннарның сәүдәсе турында болай дип язылган: «Төб мәркәз сәүдәләре Иркутскидә булган. Иркутскидә фруктовый подвал ачканлар. Бу тарафдан бик зур возокларга төяб бик күб фрукта илтә торган булганлар. Возокларына сигезәр-унар ат җикдерә торган булганлар. Возоклары үзләренеке булган. Атларны ыстансә саен алышдырыб җикдерә торган булганлар. Соңа таба үзе белән бергә борадәре Шәйхулла хаҗины алыб йөри башлаган. Ерак Сибириянең һәр шәһәрләренә барыб, Байкал күле артында Верхний Удин, Чита, Хабаровски кебек һәм Амур, Лена буйларына барыб сәүдә итә торган булганлар. Кытайлар белән

[1] Городские головы, гласные и депутаты Иркутской думы 1872–2011: биогр. справочник / авт.-сост. А.В. Петров, М.М. Плотникова; отв. ред. Л.М. Дамешек. Иркутск: Оттиск, 2011. С. 310.

бик зур эш эшләгәнләр. Бу Иркутскидә йорт алганлар. Шәйхулла хаҗи җәмәгате белән Иркутскидә тора башлаган. Заһидулла хаҗи үзе көз китеб, яз көнләрендә Акъегеткә кайта торган булган. Дәүләткә ирешә башлагач да, мәсҗедләр сала башлаганлар, фәкыйрь-фукарага, ятим-ятимәгә ярдәмләр итә башлаганлар».

1907 елда Иркутскиның Большой урамында (хәзерге Карл Маркс урамы, 37) өч катлы таш йорт салдыралар һәм ул 1908 елда «Торговый дом братьев Шафигуллиных» дигән исем белән ачыла. «В магазине все приказчики были мужчины-татары, одетые в европейский тип одежды, но головы их были покрыты тюбетейками. Другие же работники набирались исключительно из русских: кассирами были только женщины, а бухгалтерами, в основном, мужчины. Здесь же работала скорняжная мастерская»[1].

Шәфигуллиннарның сәүдәгәр буларак дәрәҗәләре бик зур була, аларны Мәскәү, Казан, Себер сәүдәгәрләре яхшы белә. Гарифулла Хәйрулла улы истәлегендә Шәфигуллиннарга булган ихтирамның, аларның намуслылыгын раслаган бер вакыйга тасвирланган. 1895 елда Шәфигуллиннарның товарын сатарга алган сәүдәгәрләр аларга булган 60 мең сум бурычларын түләмиләр. Шәфигуллиннарга банкротлыкка чыгу яный. Бертуганнар бурычларын түләү өчен, Иркутскидагы да, Акъегеттәге дә йорт-җирләрен сату турында карарга киләләр. Шулвакыт Шәфигуллиннарга Россиядә «Меховой король» булып танылган купец Сорокоумов ярдәмгә килә: «Заһидулла бай Воскресенский, хәзер Чернышевский урам буйлаб бик уйланыб кына каядыр бара икән. Шул урамда бик зур меховой магазин белән сату итүче Суракумов карт очраган да, магазинларына алыб кергән дә «Эшләрегез ничек сезнең? Эшегез бозыла икән диеб хәбәрләр таралган», диб сорашкан. Билгеле, Заһидулла бай да дөрестне сөйләгән. / Иркутскидан килгән телеграммны чыгарыб күрсәткән. Суракумов карт әйткән: «Бер нәрсәгезне дә сатмагыз, Иркутка да телеграмм бир, анда да сатмасын. Менә сезгә эшегез-

[1] Иркутские повествования. 1661–1917 годы. В 2 т. / Авт.-сост. А. К. Чернигов. Иркутск: Оттиск, 2003. Т. 1.

не төзәтергә 40 мең сум акча бирәм. Вакытыгыз белән түләрсез», дигән». Сурәтләнгән вакыйга чынбарлыкта булган хәл дип уйлыйбыз. Әмма купец Сорокоумовның Казанда кайчан яшәве, кибете булуы турында хәзергә хәбәребез юк. Кибет XIX гасыр ахырларына таба гына ачылырга мөмкин. Шул ук вакытта икесе дә затлы мех белән эш итүче купецлар буларак, аларның аралашып яшәве, мех сәүдәсендә партнерлар булуы бәхәссез. Икесе дә бер үк ярминкәләргә мех алып килгән.

Шәйхулла Шәфигуллин – солдатка алынып, 1877–1878 елгы Рус-төрек сугышында катнашкан кеше. Ш. Шәфигуллинның сугышта катнашуы турында төгәл мәгълүматыбыз юк, ул алган хәрби бүләкләрдән чыгып кына фикер йөртәбез: «Был награжден знаком отличия Святого Георгия 4-й ст., медалью участника Русско-турецкой войны, светло-бронзовой медалью в память 300-летия царствования дома Романовых»[1]. Сүз уңаеннан шуны да искәртү урынлы булыр: беренче бүләк – «Знак отличия Святого Георгия 4-й ст.» бары 1877–1878 елгы Рус-төрек сугышында турыдан-туры катнашып, яу вакытында күрсәтелгән зур батырлык өчен солдатларга һәм унтер-офицерларга бирелгән. 1844 елдан әлеге награданың иноверецлар өчен махсус коелган медальоны барлыкка килгән, православный динендә булмаганнар өчен медальонның ике ягына да Россия гербы сурәте төшкән үзенчәлекле билге бирелә башлаган. Икенче бүләк – Рус-төрек сугышында катнашучы медале, ул өч төрле булып, ачык төстәге бронза медаль сугышта турыдан-туры катнашкан кешегә генә бирелгән. Романовлар нәселенең 300 еллыгына чыккан медаль бер генә материалдан коелган, шуңа күрә аның бронза булуын күрсәтү урынсыз икәнлеген искә алып, материал турындагы искәрмә нәкъ икенче медальне ачыклап килә, дип фараз итәбез. Романовлар нәселенең 300 еллыгына чыккан медаль Хәрби орденның отличие билгесен алганнарга да бирелгән.

[1] Городские головы, гласные и депутаты Иркутской думы 1872–2011: биогр. справочник / авт.-сост. А.В. Петров, М.М. Плотникова; отв. ред. Л.М. Дамешек. Иркутск: Оттиск, 2011. С. 310.

Шәйхулла Шәфигуллин 1890 елда Иркутск губернаторына тапшырылган үтенеч язуында үзе турында «Уволенный в запас армии Канонир Шайхулла Шафигуллин»[1] дигән мәгълүмат бирә. Димәк, Шәйхулла Шәфигуллин сугышта артеллерия сугышчысы, тупчы булган.

эчәбез/ җиләкне җыйабыз да/ җиләкнең чүбе кала бит/ шул чүпне киптерәбез дә туже чәйгә/ богородский трава җыйабыз/ чәйгә салабыз/ өйдә чирле кеше булса/ шул үләнне йандырсаң/ төтөннәсәң өйдә/ имеш/ чистара/ микробларны үтерә// әниләр малны күп тоталар ийэ/ сыйырлар/ сарыклар/ дуңгызны инәй кушмый иде тотарга/ бервакытта дуңгыз балаларын апкайттылар әнәү белән әтәү базардан/ асрарга дийэп/ инәү аларны/ элекке чебен даруwы белән су эчергән дә/ дуңгыз балаларын үтергән// йарамый балакаыйм дуңгызларны тотырга/ йортны мыскыл итәләр алар дийә иде/ инәй безнең укымышлы иде// әнәүдә бар иде жакеткасы элеке шундый/ ойдә йөрий торган// ә япкыч гел дә бар иде// өй ийәсе бар диләр/ берәр алама хәл булса/ имеш/ берәр знак бирә диләр// йорт ийәсе бар диләр/ բездә өйгә беренче кергәндә әпи белән бергә/ инәйем әйтте/ өй хозяины әпи кертергә/ тоз кертергә/ су кертергә тиеш// безнең әниләр җыйылалар иде/ чигәләр иде матур чикле/ каплар өчен әйберләр/ чигәргә үрәтәләр иде безне// минчага үникедән соң йөрергә йарамый дип әйтә иде картыйым /уникедән соң җеннәр йуыналар/ куркыта иде безне/ минчада койынып чыкканда әйтергә кирәк: эчемне иман пакла/ тышымны дарйа пакла дип// йуынгач шулай дийеп чәйкәнып чыгарга кирәк минчадан/ башны каплап/ башны кеше ирләре күрмәсен/ айакның чәлтерләрен күрмәсеннәр/ шулай чыгарга тиеш хатыннар минчадан// әнәүемнең әтәсе үлгән/ калган әнәсе белән генә йәшәргә/ ачлык вакыты булган/ әтәү икенче аwылдан клубка/ анда әнәүне күргән// ебәргән башкодалар/ ул башкода килгән инәйгә/ килгәннәр/ димнәгәннәр/ йаратмыйча/ белмичә чыккан// биш҆бала табып/ әйбәт торганнар// әтәү бик әйбәт кеше иде//

*Аларский район, д. Шаховская,*
*Кузинская (Галеева) Альбира Ахметовна (1960 г.р.)*

әт҆҆ием чечиковскийдан / ән҆ием ул҆йановская област҆ дубининский район село ламаты// алар анан күч(т)кәнәр// минем ике әбием иде /ас҆ма узтдиновна/ ас҆ма мухутдиновна/ минем бабайның/ әниемнекен биз әбием дия идек/ ә икенчесе сукыр апа иде// ул бизне үстереп торды/ ул аны бургытмады/ әбиләр бик

укымышлылар иде алар// мин татарча сүләшәм/ ә балаларым/ улым/килˀен сүләшә алмый/ алар бөтененсен аңгыра (аңлый)/ сүләшергә белмиләр/ мин балалар белән эшләдем/ аларны әнˀләре әтиләре бургытканнар// бик җәлли идем үзләрен//

мин әтиемә әтә идем/ эти/ җибәр мине әбигә/ мин нәнәйләргә барам кунарга// мин сукыр апа белән ярата идем/ ул миңа әкиятләр сүли иде// мәч(т)кә йөри иде// миңә нәнәй өйрәтеп калдырды/ миңа алты йәш булгандыр/ сюралар/ элкеге вакытта мин курка идем/үзˀем укыйм/ садак бирˀям// бик зур гонˀях/орламаска (әрләмәскә) тырышам/әбиләргә гел булыша идем// пешерәләр иде кыстыбай/перемәч/колак/бәлеш/качан аш уздыралар/ токмач/ бәрәңге// татар йырларын йырлый алмый үзем, йаратам тыңларга/ әбиләр минек/ әнˀем/ әнˀиемнеке сеңелесе зур/ шулай матур йырлыйлар иде// биздә йырларга кеше юктыр/ мин өйрәнеп калмадым/ өйрәнеп калырга иде/ сүләшергә сүләшәм/ ну мин ыялам/ телевизорда карыйм татарча сүләшәләр/ә биздә алай түгел//

мин әтәм саплаяк (ковш)/ алар әтә чүмеч/ биз үзебез мал тота идек/ биздә инде ат/ кәзәляр/ күбәр тоталар иде// әнˀием дә кәзәләр тота иде/ бәләкәй кәзә чагаларын соскадан эчерә иде сет белән/ шулай үстерәләр иде// биз тордык үз ызбабызда/ хәзер мин торам нәнәйнең ызбасында// нукларым күп// минеке ерем урыс иде/ мин җәллямим/ яхшы балалар үстердем// кеше балаларын карадым//

алланы беркайчан онытмый идем мин/ алладан гел сорый идем/ балаларга да хә әтеп торам сˀез алланы быргытмагыз/ сорагыз// йә рәббем ходайым/ әрдәмеңнән ташлама/ аллахы тәгәлә барыбызга да җан тынычлыгы бир/ астягафирулла//

биздя бар әлбинә/ ул сүләшә/ йомшак иттереп сүләшә//

*Заларинский район, п.Залари,*
*Лунина (Денмухаметова) Найлэ Мухаряновна (1956 г.р.)*

# ИРКУТСК ӨЛКӘСЕ ТАТАР ФОЛЬКЛОРЫ (ИНСТИТУТНЫҢ 2018 ЕЛДА ИРКУТСК ӨЛКӘСЕНДӘ УЗГАН ЭКСПЕДЕЦИЯСЕ МАТЕРИАЛЛАРЫ НИГЕЗЕНДӘ)

*Илсөяр Закирова*

Фольклор – халыкның уртак мәдәни мирасы, башка халыклардан аерып узара торган рухи байлыгы. Дөньяның төрле почмакларына сибелеп яшәүче татарларның, берләштереп торучы уртак җырлары, риваять-легендалары, әкиятләре, мәкаль-әйтемнәре бар. Иркутск татарлары фольклоры да, нигездә, Казан татарлары фольклорыннан аз аерыла. Биредә дә шул ук җырлар җырлана, бәйрәмнәр уза, йолалар билгеләп үтелә. Шул ук вакытта халыкның яшәү рәвешенең, дөньяны күзаллавының, уй-фикерләренең кайтавазы булган фольклорның үзенә генә хас сыйфатлары да бар. Бер караганда, шул ук җыр, шул ук йола кебек. Әмма аның я көендә, я сүзләрендә берәр аерымлык күзәтелә. Халык иҗаты әсәрләренә хуҗалык итү рәвеше, төбәкнең географик үзенчәлекләре һәм табигать шартлары, күрше халыклар белән бәгланышлар да йогынты ясый. Фольклор халыкның яшәү рәвешен, уй-фикерләрен, дөньяны кабул итүен көзге кебек чагылдыра.

Иркутск шәһәрендә һәм якын-тирә татар авылларында яшәүче милләттәшләребезнең хәтерендә, телдән телгә, буыннан – буынга күчеп, аларның гаилә тарихлары, тормыш-көнкүреше, ышанулары, дөньяны кабул итүе белән бәйле карашлары, ышанулары саклана.

Биредә дә халык иҗатының аерым жанрларына караган текстлар очрый. Әмма әкиятләр, дастаннар кебек зур күләмле жанр-

ларга караган әсәрләр соңгы, 2018 елгаы экспедиция вакытында табылмады. 1971 елгы экспедициядә биредә яшәүче татарлардан күпсанлы тылсымлы әкиятләр язып алынган булган. Бу бер татар халкына гына хас күренеш түгел, хәзерге вакытта фольклорның күп кенә жанрларына караган әсәрләр югалып бара. Элегрәк һәр авылда әкият сөйләүчеләр булган, әкият тыңларга бала-чагалар гына түгел, өлкәннәр дә җыелган. Кешеләр, тылсымлы әкият тыңлаганда, үзләрен дә шул тылсымлы, могҗизалы дөньяда дип хис иткән, дөнья мәшәкатьләрен, тормыш авырлыгын онытып торган. Әкият сөйләү традициясе XX гасырның 70 елларына кадәр дәвам иткән. Соңгы экспедициядә ул чор әкиятчеләре турында истәлекләрне генә очраттык. Информантларыбыз әби-бабаларының әкиятләр сөйләвен, «Йосыф кыссасы»н көйләвен яхшы хәтерли.

Бу өлкәдә яшәүче милләттәшләребез бирегә килеп төпләнгән ата-бабаларының тарихын, аларның тормышына караган аерым вакыйгаларны яхшы белә, үткәннәргә ихтирам белән карый. Аларның бу якларга ничек килеп чыгуы, урнашып калуы, биредә яшәгән аерым шәхесләрнең тормышы риваятьләрдә, истәлекләрдә һәм сөйләкләрдә бәян ителә. Мәсәлән, Чирмешән авылына нигез салыну, Шаховский авылында мәчет төзелү, меценат Шәфигуллиннар турында сөйләк-истәлекләр саклана. Алардагы вакыйгалар гаилә, нәсел, халык һәм ил тарихына үрелеп китә.

### Новоселово авылы

*Новосел зур авыл иде, 140 йорт иде. Аннан 120 ир китте сугышка, 3 ир генә кайтты сугыштан. Калдылар бар да, биш белән, алты бала белән, җиде бала белән. Өч бала белән калдылар. Минем өч братым сугышта үлде. Ике братым кайтты. Бер братым раненный кайтты. Бер братым Берлин алып кайтты. Мәгъсүм абыем юлда кайтканда Башкириядән бер фронтовичка белән танышкан. 45 елны Берлиннан кайтып, безгә кайтып, шул Нуриягә өйләнеп әнием никах укытты. Башкириягә кайтып киттеләр.*

## Нәсел тарихы

*Әти-әни Казаннан килгәннәр. Минем әни – Галимә Заһидул-лина. Вәлиев Һади – әтием. Алар 18 елны килгәннәр. Әни-әтинең ике малай булган инде анда. Минем әтине 1912 елны сугышка алганнар.*

*Әни Кукмара районы Сәрдегән авылы. Минем әнием бик знатный семьядан, ул графиня-княжна булганмы. Анда булган Гарифулла дигән бай.*

## Әтисе турында

*Монда 23 елда Колчак торган Заларида. Әтиләр колхоз төзеп ятканнар монда, Красное поле дип атала. Красное Поле дигән авыл бар. Шунда коммуна атаганнар. Шунда Колчак кереп бөтенесен атып үтергәннәр. Әти бәрәңге арасына, ботва арасына качып калган. Әни шул 23 елны Зәки абыйны тапкан. Ул сугышта үлде. Өч брат минем сугышта үлде.*

## Гаилә тарихы

*Әти белән әнинең 9 малай, 3 кыз. Алар 70 ел бергә торганнар. Шулкадәр гыйшык, матур ярату күрмәдем. Шулкадәр матур тордылар алар. Мин андый гыйшык, андый ярату гомердә күрмәдем. Әнисез әти чәй эчми иде. Иртә белән «Карчык, тор,чәем кайнады инде, әнисе, әйдә тор, чәем кайнады» дип әнине уята ие.*

*Сугыш вакытында без башакка барадыр идек. Анда бодай башагы җыябыз инде, арыш башагы да. «Шул башакны анагызга апкайтыгыз, куырып апкайтыгыз» дип тора иде. Шулкадәр тату торганнар.*

## Гаилә тарихы

*Әти белән әни 18 елда киткәннәр монда. Апкилгән монда Гали абзыйны, 1912 елгы малаен. Хәлил дигән малае Казанда үлеп калган. Рәсәйдә әнинең бертуган браты, Билал дигән абзые калган. И, энекәемне күрсәм иде, бер күрсәм иде, дип гел сөйләде шуны. Менә хәзер карыйм Зөфәр Билаловны, минем Бари дигән абыйның берсе Ренат исемле. Суйган да каплаган, Зөфәр Билалов инде. Карыйм, әллә туган микән безгә. Без өч сестра – Габидә, Әминә,*

*Нәгыймә бик матур җырлайдыр идек. Әни – Галимә Заһидуллина. Әтисе Заһидулла булды микән. 905 канал тотам мин. Гел карыйм телевизордан.*

*Залари районы Залари поселогы.*
*Вәлиева Нәгыймә Һади кызы (1932 елгы)*

## Гаилә тарихы

*Әти 1937 елда по вербовке килгән, семьясы белән. Кукмара районы Уркуш авылыннан. Алар 2–3 ай килгәннәр. Юлда ике бала үлгән. Теплушкаларда килгәннәр. Заларига килгәннәр. Башта Карлукка килгәннәр. Заларидан 3 километрда мост, шунда булган Карлук. Татар авылы булган. Керәшеннәр дә торганнар. Картыебыз русча белмәгән. Җиләк күп булган. Урыслар, опять татарка пошла, дип сөйләп калганнар. Мондагы халык җиләк җыя белмәгән.*

*Татарлар бик дус яшәгән гомер-гомергә, замок бер кешедә дә юк, бер кеше бикләмәгән бер нәрсәне.*

*Авыл халкы матур яшәгән. Кичләрен ирләр белән балалар лапта уйныйлар. Хатын-кызлар скамьядә карап утыралар.*

*Мал күп һәр хуҗалыкта. Ирләр бабки уйныйлар иде.*

*Хафизова Халисә Мөхәммәтгалим кызы(1958 елгы)*

*Халык бик дус иде. Бәлеш, табикмәк, әлбә, корт, эремчек пешерәләр иде бәйрәм табынына.*

*Гаеткә коймак пешерәләр. Гаеттән чыккач, бер берсенә кунакка йөргәннәр.*

*Нокыт районы Новоселово авылы.*
*Мугинова Әминә Евгеньевна, (1939 елгы)*

## Бабай турында

*Китаплары күп булган бабайның. Аларны капчыкларга тутырып, урманга күмделәр. Бабай яндырырга бирмимен, гонаһны үземә алам, диде. Бабай мулла иде. Мәдрәсә бетергән, грамоталы кеше иде. Бала чакта тыңлыйсы килми иде ул сөйләгәннәрне.*

*Хәзер уйлап ятам, их тыңлыйсы калган, дип. Ирләр хатыннар киеме кияр, чәчәкле киемнәр, дия иде. Хатыннар ирләр киеме кияр, дия иде. Кияләрме, менә, кияләр шул. Шәрә йөрерләр, гыйбрәтләрен күрсәтерләр, дип. Ахырзаман алдыннан кешеләр ни кыланырга белмәс, дия иде. Бер-берсен үтерерләр. Су басар, суга басып үләрләр, канга батып үләрләр.*

*Һавада тимер кошлар очып йөрер, алар очып йөрер дә, агач кебек янып, егылып төшәрләр, дип сөйли иде.*

*Нокыт районы Новоселово авылы.*
*Мугинова Әминә Евгеньевна, (1939 елгы)*

## Гаилә тарихы

*Әтиләр 1937 елда килгән, Тәкәнештән киткән алар. Переселенцы. Мүхтәсим бабай Идиатуллин Идиатович.*

*Шәйхетдинов абый аларның татарча сөйләшкәннәрен ишеткән дә Иркутскида, ияртеп алып килгән Чирмешәнгә. Шулай итеп монда яшәп калганнар.*

*Бабай туган җирләрен, торган җирләрен сагына.*

*Бабай да, әти-әни җырлыйлар иде.*

*Илһам Шакиров җырларын яраталар иде. Пластинкалар алып кайттылар Казаннан.*

*«Умырзая», «Дим-дим», «Зәңгәр күлмәк» җырларын җырлыйлар, «Сак-Сок» ны көйлиләр иде.*

*Залари районы Холмогой авылы.*
*Сабитова (Идиатуллина) Руминә Мәхмүт кызы (1952 елгы)*

## Гаилә тарихы

*Монда бабайларның бабасы килгән.*

*Безнекеләр Иван Грозный чукындырудан качып килгәннәр. Бабайлар дүрт бала белән килгән. Әнием ягы бабайны 10 десятина җир освоить итеп, бай дип раскулачивать итеп утыртканар.*

*Элгәре Белектуйда татарлар күп иде. Сугыш беткәч, авылдан татарлар китте.*

*Безнең фамилия Әхмәтҗәнов булган. Оренбург ягыннан килгән.*

*Әнием ягыннан шестидесятники.*

*Халыкны җыялар да, утырталар да вагонга, җибәрәләр.*

*Алар башта Шаховскига киләләр.*

*Алар 1935 елларда бередә өйләнешәләр.*

*Татарлар бер урам иде, хәзер бер генә йорт калды. Без генә.*

*Обелискта татар фамилияәре күп:*

*Якупов, Шахмуратов, Хасанов, Зайнуллин, Мамедов...*

*Биликтуй авылына беренче булып татарлар килгән, каторжаннар араларында да татарлар булган*

*Авыл аша Московский тракт уза. Күпере бар иде.*

*Хәзер авылда 1000 кеше чамасы, дачниклар белән. Кыш көне кеше аз кала. 300 тирәсе йорт бар.*

*Мәчет бар иде элек. Мәдрәсә дә булган, әтием укыган анда.*

*Усольск районы Биликтуй авылы.*
*Нурмөхәммәтов Хәмит Рәхимьян улы (1955 елгы).*

## Сугыш турында

*Күпме кеше киткәнен әйтәлмәем. Белмәем. Поссовет кырыенда мемориал бар. Ул мемориалда мин белгән, погибших на фронте барсы да юк. Мин аларны точно беләм. Бездә, Федоровск дим бит инде, без тордык. Бездән бер чакырым Каменка иде. Алар белоруслар. Иван Яковлевич Шлык. Шлык фамилиясе безнең Заларида һаман да бар әле. Ул 20 года рождения. Сугыш вакытында алдылар аны, өч айдан килде похоронкасы. Шул юк поссовет кырындагы мемориалда.*

*Олы Ялан диләр иде. Олы Яланда Гопоненко дигән кеше бар иде. Шул юк исемлектә. Исеме Сергей микән. Онытгым инде.*

*Нина Петровнага әйтәсе бар аны. Документально юк инде. Словесно гына. Но бу 100 процентов правдиво, словесно булса да. Ике кеше пропущенно. Ул вакытта Заларида военкомат бар иде. Военкомат сообщить итмәгәнме?*

*Залари районы Чирмешән авылы.*
*Насыйпов Шәехзаман Шәйхелиман улы (1921 елгы)*

Фольклорьда халыкның бердәмлеге, бер-берсенә ярдәм итеп, бергәләшеп эшләп һәм күңел ачып яшәгәнлеге чагыла. Иркутск татарларында йола фольклоры, бигрәк тә бала багу поэзиясе, туй йолалары, алар белән бәйле текстлар хәзер дә популяр. Гаилә һәм календарь йолалары тулы бер цикл хасил итеп, аларның күбесе бүген дә үтәлә. Календарь йолалар, мәсәлән, «Каз туе» яки «Каз өмәсе» аерым бер авыл яки район, хәтта төбәк күләмендә бәйрәм ителсә, гаилә-көнкүреш йолалары гаиләнең, туганнарның үзара аралашуын, туганлык мөнәсәбәтләренең якынаюын тәэмин итеп, билгеле бер нәсел эчендә уздырыла. Биредә татар халкының кунак кабул итү традициясе дә яхшы саклана. Иркутскида яшәүче татарлар бер-берсен яхшы белә, якыннан аралашып, кунакка йөрешеп яши.

Информантлар үз туйларын искә төшереп, халыкның туй йолаларын да барлыйлар.

## Туйлар

*Кызларны урлаганнары да бар. Мин үзем кияүгә чыктым бик хәерче елны инде. 50 елны кияүгә чыктым бабаема. Ул армиядән кайткан ие. Мин хлебозаводта эшлидерием. Миңа 18 яшь ие. Без аның белән таныштык та. Беркөнне Фәгыйлә исемле иптәш кызым мине кунакка чакырды, день рождениесына. Шунда инде безгә бражка салып бирделәр. Без инде гомердә дә эчкән югые, ул бражканы күргән дә югые. Аның өстендә йөземнәр йөзеп йөридерие. Минәйтәм, карале, компот биргәннәр, тәмле, дип, мин аны кашык белән ашап утырам. Миннән көләләр. Ул бит бражка дип. Юк, минәйтәм, бражка түгел, мин андый әйбер эчмим, дим. Бу бит компот дим. Миннән көләләр.*

*Шунда егет тә утырган. Ул Татарстанның Чүпрәле районы Мочали авылыннан монда килгән, Себергә. Ул да көлеп утыра. Шуннан ул мине озата килде инде. Бер алты ай йөрдек тә кавыштык инде. Башта, Черохауда мулла бар иде, муллада никах укыттык. Никах укыткач, инде мунчага җибәрәләр. Чишенергә оят инде. Аннары аларны бер буш йортка ябалар.*

*Туйга бәлеш пешерәләр. Берсе итле бәлеш булсын. Берсе – сладкий, тәмле бәлеш, җимешләр салып. Әбәзәтелне каз пешерәләр. Брынын кисеп кызга бирәләр. Тәмле җирен егеткә бирәләр. Ник шулайдыр инде, хәзер дә белмим.*

*Бабай белән 52 ел тордык. Бик тату тордык. Үлгәненә 15 ел инде.*

*Залари районы Залари поселогы.*

*Вәлиева Нәгыймә Һади кызы (1932 елгы)*

## Туй

*Туйлар атлар җигеп, урам үтәсең, кыңгыраулар белән. Аннары соң капка төбендә киленне төшерәләр. Мендәрләр куялар. Катырак тапта, катырак тапта, ныграк торырсың, диләр иде. Бал-май каптыралар. Аннары күмәч пешерәләр, күпме тешли аласың, тешлә, диләр иде.*

*Нокыт районы Новоселово авылы.*
*Мугинова Әминә Евгеньевна (1939 елгы)*

## Өйләнүе турында

Предложили как то. Инде сугыштан соң. Сугыштан соң, минем әткәйнең энесе, самый младшие – Мөхәммәтшәех дигәне Заларида торадырые. Мин кайтып кердем шуларга. Ә ул Примерныйныкы. Монда бар колхоз «Примерный» иде. Сенная Падь диләр ие. Вот шунда. Электән Чирмешәннеке булган алар. Аннары шул тарала башлап инде. Потому что монда, урманда икмәк бик үсми. Шуннан соң халык китте инде. Безнең бит район с/х. Район продовольственный, хозяйственный. При области авторитет держал.

Шул абзыйларда очрашып, шунда поженились инде. 51 ел тордык.

Дүрт кыз, бер малай безнең.

*Залари районы Чирмешән авылы.*
*Насыйпов Шәехзаман Шәйхелиман улы (1921 елгы)*

## Мәет саклау

*Мәетне өч көн саклыйлар. Әбиләр өч көн сакларга бара. Анда догалар укый. Өченче көнгә күмәләр.*

*Залари районы Чирмешән авылы.*
*Сәлимгәрәев Гаффар Хамматнур улы (1954 елгы)*

Гасырлар дәвамында аналарга бала тудыру вакытында ярдәм күрсәтүче, бала кабул итүче кендек әбиләре булган. Алар, кагыйдә буларак, өлкән яшьтә булып, бу һөнәрләр буыннан-буынга, анадан кызга күчкән. Хәзерге көнгә кадәр халыкта бала тапканда хатыннарга ярдәм күрсәткән кендек әбиләре турында истәлекләр саклана. Аларны һәрвакыт яхшы сүз белән искә алалар. Тәҗрибәле кендек әбиләре баланы бик җиңел таптырган, катлаулы очракларда, бала дөрес килмәгәндә дә, кендек әбиләре ананың да гомерен саклап, баланы да имгәтмичә тудырырга ярдәм итә белгәннәр. Татар халкында баланы кендек әбиләр ярдәмендә таптыру күренеше XX гасырның урталарына кадәр дәвам итә. 1960 елларда кендек әбиләренең эшчәнлеген тыю нәтиҗәсе буларак, бу күренеш юкка чыга.

## Кендек әби

*Әби кергән чакта, башта барып итәген тарта: «Бисмиллаһи рахман ирраһим, исән-сау килсен дөньяга», дип, аннары аны яткыра, эчен сыйпалаем, үгетләсең инде: «Хәзер, кызым, хәзер, балам, хәзер. Тиз генә, тиз була» дип сыйпайсың инде. Безнең әни дә әби булып йөрде. Менә Мәдинә дигән хатын Иркутскида торды. Ул кайта иде, ел саен әнигә күлмәклек алып кайта иде. Аның баласы аркылы килгән. Врач килгән, шунда утыра ди. Әни килеп, аркылы килгән баланы турылатып, бәбәйләтте».*

*Бәбәйнең кендеген кисеп аласың да, аны җуып, коендырып, бишегенә илтеп саласың. Авызына бал-май каптырасың, иренендә сыйпыйсың. «Ходай сиңа озын гомер бирсен. Бал шикелле татлы телле бул, май шикелле йомшак бул әниеңә-әтиеңә.*

*Икенче җортта коймак пешә инде. Бала тугач бәбәй туе ясайбыз инде. Анда, бәбәй туенда, күп кеше булмый. Кендек әби дә, бәбәй тапкан хатын, хуҗабикә инде коймак пешерүче.*

*Баланы коендырганда, «Балакаем, озын гомерең булсын, якты йөзең булсын, татлы телең булсын, атага-анага игелекле бала бул», дип әйтә-әйтә коендырасың инде. Әби кертә мунчаны, өч тапкыр килә. Әнине өченче көнне генә мунча кертәбез. Аны әби алып бара мунчага.*

*Шунда исем кушабыз. Мендәргә яткырам да азан әйтеп исем кушам. Әле менә бер балага Сөләйман исеме куеп кайттым.*

*Безнең авылда кендек әби бар иде, кендек әбигә барып су китерә идек. Кучтәнәч илтә идек, аш пешерсәк аш күтәреп илтә идек.*

*Баланың чәчен кырык көннән алабыз. Хуҗабикә коймак пешерә. Ул чәч саклана. Ул гомере буе саклый. Әби чәчне кырка. Аны кыягазьгә төреп яшереп куясың. Ул гомер тели.*

*Залари районы Залари поселогы.*
*Вәлиева Нәгыймә Һади кызы (1932 елгы)*

Кендек әбиләре туган балага беренче булып бәхет-тәүфыйк теләгәннәр. Тәмле телле булсын, ризыклы-бәхетле булсын өчен, балага бал белән май каптырганнар. Һәрбер йола шигъри текстлар ярдәмендә ныгытылган. Бу йола һәм текстларны башкаруның максаты – ананың исән-сау булып, баладан җиңел котылуын теләү, сабыйның таза, бәхетле булып тууын тәэмин итәргә омтылу, ана белән баланы кара көчләрдән, сихердән саклау.

Баланы беренче тапкыр юындырганнан башлап, 40 көн дәвамында мунча ягылган һәм һәр көнне кендек әбисе килеп баланы юындырып киткән. Шул ук вакытта ул баланы юындырып кына калмаган, баш формасында, кул-аякларында, аркасында җитешсезлекләр булганда, да массаж һәм мунча ярдәмендә дәваланган, урынына утырткан.

Татар халкында һәркем үз кендек әбисен белгән. Хәрби хезмәткә китүче егетләр кендек әбиләре белән саубуллашырга кергән. Кайткач, кереп хәл белешү дә мәҗбүри саналган. Кендек әбигә бәйрәмнәрдә күчтәнәчләр китергәннәр. Ул һәрбер өйдә кадерле кунак булган.

## Кендек әби

*Кендек әби бар иде. Тимербай бабайның анасы.*

*Бервакыт күчтәнәчкә бал алып киттем. Әниләр җибәрде дә. Кердем, намаз укый иде. Тордым көтеп, тордым. Кулымнан балым төшеп китеп ватылды. Иии, елап йөгереп кайттым. Әни яңадан бал тутырып бирде. Без корт тота идек.*

*Залари районы Холмогой авылы.*
*Сабитова (Идиатуллина) Руминә Мәхмүт кызы (1952 елгы)*

## Кендек әби

*Күрше яшәдек кендек әби белән. Мунчада юа иде балаларны.*

*Алар районы Шаховский авылы.*
*Галиева Фәйхүнә Зыятдин кызы (1935 елгы)*

Элек һәр авылда имчеләр, төрле ырым башкаручылар, өшкерүчеләр булган. Хәзерге вакытта бу күренешләр юкка чыгып бара. Бары әби-бабайлар традициясен дәвам итеп, күз тиюләрне имләү генә саклана.

## Күз тию

*Балага күз тисә, җиде тапкыр өшкерәм. Җиде көн подряд. Бала тартыла, тартыша күз тисә, үзенә үзе урын таба алмый, елый. Шулай булса күз тигән була. Күз бик әшәке ул. Бездә бер бабай бар ие. «Ой, кызым, балаларың күрсәтмә, күзем тия», ди. Күзе бик әшәке. Әшәке күзне сразы сизәм мин.*

*Олы кеше күз тисә тоже борчыла, әле башы әйләнә, башы авырта, ди. Үзенә үзе урын таба алмый, эче поша. Кызымны да өшкерәм мин. Киләләр миңа хатыннар, өшкереп җибәрәм мин.*

*Әйтәсәң инде:*

*И, Ходаем, бу бәндәңне әшәке күзләрдән, әшәке кешеләрдән, бинак сүзләрдән, Ходаем, сакла, Ярабби, Аллакаем, башына зиһен, күкрәгенә сабырлык, тәннәренә тазалык бир, ярабби, Ходаем, дип укыйм.*

*7 тапкыр Аятел Көрси, Колхуалла 3 тапкыр, аннары өшкерәм суга, җиде тәрәзәне сыйпаймын, җиде ишекне сыйпаймын суга. Башыннан аяк табанына тикле сөртергә кирәк.*

*Залари районы Залари поселогы.*
*Вәлиева Нәгыймә Һади кызы (1932 елгы)*

## Корбан

*Кызым чирләгәч нәзер корбан чалдым. Бер кеше чирләсә, нәзер әйтәләр. Шул корбанны чалырга бер ир тапмадым. Чалгач, малаем белән бөтен авылларга, карчыкларга тараттык.*

## Йөрәк авыртса

*Йөрәк авыртса, әтинең атасы су өшкереп бирә иде.*

*Залари районы Холмогой авылы.*
*Сабитова (Идиатуллина) Руминә Мәхмүт кызы (1952 елгы)*

## Күз тигәндә өшкерү

*Бала өстенә бернәрсә әйтергә ярамый. Өшкерәләр, тәрәзә тире белән битләрен юешләп, итәк белән сөртәләр.*

*Залари районы Холмогой авылы.*
*Сабитова (Идиатуллина) Руминә Мәхмүт кызы (1952 елгы)*

## Имче әби

*Елан чакканны катык белән, үзенең пычагы белән кыра-кыра имләде. Тайганны, чыкканны утырта иде ул.*

*Алар районы Шаховский авылы.*
*Галиева Фәйхүнә Зыятдин кызы (1935 елгы)*

Татар халкының күңелле бәйрәмнәренең берсе – Каз өмәсе. Иркутск ягында бу йола сакланган. Каз өмәсе күп көч, вакыт, пөхтәлек-чисталык сорый торган йолалардан. Халыкта күп эшләр өмәгә җыелып башкарылган. Әле хәзер дә кош-корт суйганда һәм йорт күтәргәндә өмәгә җыелалар.

Каз өмәсе һәр елны көз ахырында яисә кыш башында үткәрелә. Ул хатын-кызлар һәм кызлар өмәсе. Каз өмәсен уздыруның үз тәртибе бар. Казлары күп кешеләр, иртәгә өмә буласы көнне үк, каз башына бер кыз, шул ук санда канат сыдыручы кызларны чакырып чыга. Беренче чиратта өмәгә туган-тумача, күрше кызларын дәшәләр. Кызлар, казларны йолкып, эчләрен алып, аларны су буена алып төшеп юалар. Алар кайтышка өйдә өмә коймагы пешерелгән була. Кич белән өмә булган йортка кызлар бәйрәм киемнәрен киенеп, ясанып яңадан киләләр. Казның баш-аягыннан бәлеш пешерелә. Кызлар уеннар уйныйлар, җырлыйлар, күңел ачалар. Алар янына кич утырырга егетләр дә дә килә.

**Каз өмәсе**

*Новоселда торганда әни җөзләп каз тотты. Өмәгә кызлар җыйдык. Йолыктык та, аннары су буена, чишмәгә төшеп юдык. Аннары соң инде пешердек. Пешердек башларын, аякларын, казын пешердек инде канишны. Аулак өй җыя иек. Аулак өйдә пешерәдериек аны. Җегетләр килә тәрәзә янына. Йөриләр иде тәрәзә янында. Кертмәйдер идек аларны. Аулак өйдә аш пешерәдериек. Кызлар җыеладырыек. Иптәшләрем бар ие: Рәйсә, Галия, Мариха, Фәридә, Сәрви, Мәдинә. Күп ие. Иптәшләрем күп ие. Берсе дә калмады инде.*

*Залари районы Залари поселогы.*
*Вәлиева Нәгыймә Һади кызы (1932 елгы)*

**Өмә**

*Сугыштан соң да каз өмәсе булды. Гармонистлар сугыштан кайтмады. Күңелсез генә инде ул сугыштан соңгы өмәләр. Коймагын пешерәсең, йоласын йолаларга тырышасың, барыбер яме калмады.*

*Алар районы Шаховский авылы.*
*Галиева Фәйхүнә Зыятдин кызы (1935 елгы)*

### Кунакка йөрү

*Элек өйдән-өйгә кунакка йөрешәләр иде. Бүген берсендә гулять итәләр җыелышып. Икенче бәйрәмдә икенчесендә җыелышалар.*

*Бик тату тора иде халык, нык тату. Өй салырга кирәк берәрсенә, өмә җыялар иде. Хуҗа алдан бүрәнә әзерли өй салырга. Алдан хәбәр бирәләр. Бер атнадан миндә өмә дип. Акча-мазар түләү юк. Бер-берсенә помогать итәләр. Өмә диярләр. Нигезгә накладка, һәр почмакка акча салалар. Бисмилла әйтеп.*

*Каз өмәсе була хатын-кызларның.*

*Залари районы Чирмешән авылы.*
*Сәлимгәрәев Гаффар Хәммәтнур улы (1954 елгы)*

Ел фасылларына бәйле Сабантуй бәйрәме, ислам диненә бәйле Корбан һәм Ураза гаетләре дә уздырыла. Еллар үткән саен бу бәйрәмнәр яңара, аларның формалары үзгәрә һәм эчтәлекләре тулылана бара.

### Сабан туе

*Элек һәр елны Сабан туе буладырые. Авыл буенча картлар колга тотып бүләк җыялар иде. Бүләккә тастымал, яулык, күкәй бирәләр. Күкәйне красить итеп алдан әзерләп куялар. Кеше белә. Бөтен кеше чыга. Күкәйне пешерәләр. Йөгергән кешегә, бала-чагага, капчыклар белән бәрешкән кешегә бирәләр аны.*

*Залари районы Чирмешән авылы.*
*Сәлимгәрәев Гаффар Хәммәтнур улы (1954 елгы)*

Информантларның хатирәләрендә кичке уеннар да искә алына. Иркутск белән Татарстан арасы 4000 километрдан артык булуга карамастан, биредәге татар авылларында информантлар белән сөйләшеп утырганда, еш кына үзеңне шулкадәр еракта түгел, ә күрше авылда итеп тоясың. Алар сөйләгәннәр һәрберебезгә шулкадәр таныш, якын күренешләр. Гасырлар дәвамында төрле халыклар арасында яшәп тә үзләренең гореф-гадәтләрен, традицияләрен, мәдәниятен саклап кала алган халкыбыз. Әлбәттә,

элегрәк милли рухны сакларга мәчет-мәдрәсәләр булышлык итсә, соңыннан Совет дәверендә татар мәктәпләре (Иркутск өлкәсендә аларның саны иллегә якын була) зур роль уйнаган.

### Кич

*Кич чыгу бар иде. Көндез эшләрне тизрәк бетереп, әзерләнә идек. Гармуннар уйныйлар. Су буенда җыелабыз. Җырлыйбыз, уеннар уйныйбыз. Хәзер яшьләр кич чыкмый инде.*

*Залари районы Холмогой авылы.*
*Сабитова (Идиатуллина) Руминә Мәхмүт кызы (1952 елгы)*

Татар халкында мал асраучылык белән бәйле йолалар шактый очрый.

### Малны көтүгә куу

*Малны көтүгә чыгарганда, аяк астына кул сөрткән сөлгене ташлый идек. Капкадан чыкканда, басып чыгыгыз, басып керегез, адашмагыз, кире кайтыгыз, дип. Көтүчегә хәер бирәбез. Ризык, күкәй бирәбез. Шушы күкәй кебек маллар йөрсен дип.*

*Алар районы Шаховский авылы.*
*Галиева Фәйхүнә Зыятдин кызы (1935 елгы)*

*Көтүче, беренче көнне көтү чыккач, җыеп бара көтүне, аңа беренче көнне күкәй чыгаралар. Кем күпме чыгара. Шулай чиләк күкәй җыя.*

*Сыерны сатып аласың, капка төбенә сөлге җәеп, шуның аша атлап керә. Чиккән сөлге эзләп ала идек яңа сыер алганда, аны атлатып кертергә.*

*Алар районы Шаховский авылы.*
*Александрова (Зәйнуллина) Фәгыйлә Сибогат кызы (1965 елгы)*

*Чирмешәндә, Тапыйда һәр кеше, һәр гаилә үз нуждасына дегет куган. Мәсәлән, ишек майларга, Сыерларны дәваларга, тоякларын дәваларга, украсын бетерергә. Сыер малын бик карап торалар иде.*

*Усолье-Сибирское шәһәре.*
*Котлыәхмәтова Әнисә Шәехзаман кызы (1956 елгы)*

Татар халкы яшәгән барлык төбәкләрдә киң таралган «Яңгыр боткасы» яки «Яңгыр туе» йоласы биредә дә мәгълүм. Яңгыр боткасы корылык килгәндә, озак яңгыр яумаганда уздырыла. Ул бик борынгы заманнарда, мәҗүсилек чорында барлыкка килгән йола. Су иясенә корбан бирүнең бер төре булган. Мәҗүсилек чорында Су иясенә корбан суеп, корылык җибәрмәвен яки яңгыр сораганнар. Су иясе кара төстәге терлекләрне ярата дип ышаналар. Шуңа күрә тегермәнчеләр дә бары кара төстәге терлек кенә асраган. Корбанга да кара төстәге терлек суелган. Әлеге йоланың эзләре балалар фольклорында, эндәшләрдә сакланган:

*Яңгыр, яу, яу!*
*Кара сарык суярмын,*
*Ботын сиңа куярмын.*

Кагыйдә буларак, авыл кешеләре, озак яңгыр булмаганда, йорт саен яңгыр боткасы өчен ризык, мәсәлән, төрле ярмалар, май, йомырка җыеп, су буена барганнар. Анда авыл халкы яңгыр боткасы өчен дип алган сарык суелган. Догалар укып, яңгыр сораганнар. Иркутск өлкәсендә дә корылык килгән елларда әлеге йолалар уздырылган.

### Яңгыр сорау

*Яңгыр яумый торса, әбиләргә зәер илтәләр. Аркылы сазга барыпмы, укынып кайталар. Анда чишмә бар. Анда, чишмә буенда укыганнар, теләк теләгәннәр.*

*Алар районы Шаховский авылы.*
*Александрова (Зәйнуллина) Фәгыйлә Сибогат кызы (1965 елгы)*

Хәзерге вакытта иң популяр жанрларның берсе – мифологик хикәятләр. Мифологик хикәятләр дигәндә, төрле мифик затлар белән очрашуны бәян иткән хикәятләрне күз алдында тотабыз. Информант әлеге затларны үз күзе белән күрүен сөйли яки аларны берәр танышының яки танышының танышы күрүен әйтә. Бу вакыйгалар һәрвакыт реаль шаһитларның исеме, вакыйганың төгәл урыны күрсәтелү белән дә чынбарлыкка дәгъва итә. Һәр

очракта да хикәят булган хәл итеп сөйләнә һәм тыңлаучылар тарафыннан да шулай кабул ителә. Ышаныргамы, юкмы – монысын һәр кеше үзе хәл итә. Кем өчендер ул чынбарлыктагы бер күренеш булса, икенче берәү аны күңел ачканда сөйләнә торган хикәя буларак кабул итә.

Мифологик хикәятләрнең иң популярларында Су анасы яки Су иясе, Йорт иясе һәм Абзар хуҗасы, Урман хуҗасы, Убыр белән очрашулар, аларның вазифалары һәм кылган гамәлләре туында сүз бара.

Иркутск өлкәсендә татар авыллары урман эчендә урнашкан, шуңа күрә биредә Урман иясе турында мифологик хикәятләр күп. Су анасы исә – татар мифологиясендә иң популяр Су иясе. Татар халкының мифологик хикәятләре буенча ул елга, күлләрдә яши. Татар халкында «Иясез су юк» дигән ышану да бар. Кагыйдә буларак, мифларда Су анасы матур яки киресенчә куркыныч хатын-кыз итеп тасвирлана. Су анасын татар халкы Габдулла Тукайның «Су анасы» әкият-поэмасындагы кебегрәк итеп күз алдына китерә. Гадәттә аның су буенда чәч тарап утырганын күрәләр. Бу сюжетның популярлашуында, әлбәттә, Г. Тукай поэмасы да зур роль уйнаган.

**Урман анасы**

*Без бара идек көпшә җыярга, сарана җыярга. Әйтә идек: «И, урман анасы, зинһар өчен безгә уйдыклар табып бир!» – дип. Җиләккә бара идек. Урман анасына урманга кергәндә әйтәбез: «Урман анасы, сиңа сәлам әйтәбез, сиңа Ходай Тәгаләдән исәнлек-саулык сорыйбыз. Безгә уйдыклар табып бир», – дибез. Уйдык-уйдык җиләклек була бит. Җәй булса, урманнан кайтмый идек инде. Көпшә, какы, шома көпшә, сарана, кузгалак. Аннары рәхмәт әйтәбез: «И, рәхмәт сиңа, урман хуҗабикәсе», дип рәхмәт әйтәбез.*

*Урманга бисмилла әйтеп кермәсәң, урман анасы адаштыра. Бервакыт күкрәп яңгыр ява. Башак җыеп кайтып киләбез. Каеннар җыгылалар. Наратлар шарт та шорт килә. Без 3–4 бала бер чокырга кердек тә, бәләкәйләр инде, 6–7 яшь, нәрсә бар, ябындык*

*та утырабыз. И Ходаем, туктат инде яңгырыңны, без кайтып җитәек, дибез. Шәрип исемле бер малай бар иде, минем кебек. Шул әйтә, Нәгыймә, кара әле ди, монда нәрсәдер йомшак бар ди. Карасак, борсык. Шуңа әйтәбез: «Борсык, безгә юлны өйрәт әле», – дибез. Шул чыкты да, чабып китте. Шул борсык артыннан чабабыз-чабабыз, күкрәү кире якка китеп барды. Без шул борсык артыннан урманнан чыктык. Менә, мин әйтәм, урман хуҗасы безне чыгарды. Урманнан шулай итеп кайттык. Урман хуҗасы бар. Ул юл күрсәтә.*

*Сугыш вакытында Габидә апа белән хатыннар колхозга печән чабалар иде. Без шуларга ашарга пешереп, әпәй пешереп, ат белән ашарга илтә идек. Монда урман, кая барырга белмибез, и Хозыр Ильяс, безгә юл күрсәт, дибез. Хәзер кисеп бетерделәр инде, монда шулкадәр куе казенный урман иде. Таба идек юлын да. Күрсәтә иде.*

*Залари районы Залари поселогы.*
*Вәлиева Нәгыймә Һади кызы (1932 елгы)*

**Урман хуҗасы**

*Ул булырга тиеш. Мин гомеремдә урманда кундым. Сорамаенча кунмадым мин. Хуҗамы ул? «Миңәргә рөхсәт ит шушында кунып китәргә?» – дип сорамаенча кунмадым. Шулай рөхсәт белән кунмасаң, әллә нәмәкәйләр күреп бетерәсең, юньләп йоклый алмыйсың. Ә в натуре бернәмәкәй күрәлмисең. Какой-то хозяин бар.*

*Урманга рөхсәт сорап барып керәсең. Обязательно исәнләшәсең. Киткәндә, сау булыгыз, дип, рәхмәт, дип китәсең. Шундый поведение кирәк. Алар – невидимые явления. Хозяин бар.*

*Чирмешән авылы.*
*Насыйпов Шәехзаман Шәйхелиман улы (1921 елгы)*

*Урманда адаштыра. Минем туганымның кызы, адашып, күрше авылга барып чыккан.*

*Киемне әйләндереп киегез, диләр, урманда адашканда.*

*Алар районы Шаховский авылы.*
*Галиева Фәйхүнә Зыятдин кызы (1935 елгы)*

## Абзар хуҗасы

*Абзар хуҗасы булса, ул яратса, мал тазарып китә инде. «Төс бирмәй» диләр. Хуҗа яратмаса инде, ябыга инде.*

*Залари районы Залари поселогы.*
*Вәлиева Нәгыймә Һади кызы (1932 елгы)*

## Йорт хуҗасы

*Йорт хуҗасы яратса, ул йортта бәрәкәт бар. Тынычлык, намыс бар. Ашка барам менә. Килеп керәм, сизәм, йортта бәрәкәт бар. Кайбер йортта җан тынычлыгы юк. Сизелә ул.*

*Залари районы Залари поселогы.*
*Вәлиева Нәгыймә Һади кызы (1932 елгы)*

## Йорт хуҗасы, өй хуҗасы.

*Кичтән ашаган савытыңны юып каплап калдыр. Хуҗа, сиңа, дип, ярты кисәк икмәк калдыр. Ул икмәкне кая куйганын хәтерләмим.*

*Алар районы Шаховский авылы.*
*Галиева Фәйхүнә Зыятдин кызы (1935 елгы)*

## Су хуҗасы

*Су хуҗасы бар. Безнең Новоселда, авылда торганда яз көне дөрләп килә иде. Бездә тау шулай, Залари тау башы дидериек. Иске базар юл башы диеп, тау башы. Монда, аяк очыннан, аяк очы дидериек, бакча башыннан инде, чокыр, чишмә агадырые. Шул чишмәгә дөбердәп тегеннән мондый кисәк-кисәк кар белән бозлы ташу килә ие. Шуны төшә иек карарга. И Раббым, күкрәп бу Су анасы килә, Су анасы килә, дип, матур гына кил, син бик дөбердәмә, дип аңа әйтеп басып тора идек шунда. Син бит безгә ризык бирәсең, син боз түгел, син су булып агасың, җирне туендырасың, дип сөйләнеп басып торасың шунда. Су анасы бит бу, Су анасы, дип сөйләнеп.*

*Новоселда торган чакта, бәләкәйдә судан чыкмый ята торган иек. Галия, Рәйсә, әйдә су керәбез, дип, Су анасы саклай безне, әйдә керәбез, дип. «Су анасы, безне батырма», дип әйтә идек. Күл иде, аста кузнец ие. Шунда су керәдериек. Бер кырыйда сугыш вакытында сүс батыралар иде. Аннары аны алып киптерәләр. Аның тукмагы бар ие, шуны тукмаклап, бау ишәләр ие.*

*Залари районы Залари поселогы.*
*Вәлиева Нәгыймә Һади кызы, (1932 елгы)*

*Чәчне таратып йөрсәк, Су анасы чәчегездән тотып алып китәр әле, дип әйтәләр иде.*

*Залари районы Чирмешән авылы.*
*Сәлимгәрәева Флера Мирдоҗан кызы (1955 елгы)*

*Коега карама, Су инәсе тартып алыр, без әйтәбез.*

*Залари районы Чирмешән авылы.*
*Сәлимгәрәев Гаффар Хамматнур улы (1954 елгы)*

## Су инәсе

*Су инәсе алган, диләр, кемдер батып үлсә. Невидимый хуҗалар бар ул. Мин үзем бәләкәйдән урманда өйрәнеп, урман яраттым.*

*Залари районы Чирмешән авылы.*
*Насыйпов Шәехзаман Шәйхелиман (1921 елгы)*

## Су анасы

*Бисмилла әйтеп чумыгыз, диләр. Инәм куркыта иде. Чәчен тарап утырыр су кырыенда Су анасы, дип сөйли иде.*

*Алар районы Шаховский авылы.*
*Галиева Фәйхүнә Зыятдин кызы (1935 елгы)*

Иркутск өлкәсендә ислам дине белән бәйле, ислам мифологиясенә нигезләгән, ислам изгеләренә багышланган, суфичылык чорыннан килгән сюжетларны яңарткан шактый гына текстлар да, мөнәҗәтләр дә язып алдык. Аларның бер өлеше татар халкында популяр булып, күп төбәкләргә таралган, икенчеләре акрынлап онытыла бара.

Татар халкының рухи кыйммәтләре ислам кануннарына бәйле рәвештә формалашкан. Татарлар гасырлар дәвамында шушы кануннар нигезендә җанын-рухын мәкер-яманлыктан саклап, тәнен, киемен йортын һәм бигрәк тә уй-фикерләрен пакь тотып, изге ният кылып яшәргә омтылган.

Татар халкында яхшы уй-фикер, изге теләкләрнең калыплашкан бик матур үрнәкләре бар: багышлаулар, алкышлар, төрле эшгамәлләргә һәм вакыйгаларга бәйле рәвештә Аллага мөрәҗәгать иткән шигъри текстлар. Алар барысы да татар телендә. Информантлар бу текстларны дога дип тә атыйлар. Габдулла Тукайның «Туган тел» шигырендәге юллар нәкъ шушы текстларның асылын ача:

И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!

Иркутск өлкәсендә дә бу төр үрнәкләр шактый күп язып алынды. Аларда татар халкының ислам һәм мәҗүсилек белән бәйле күп кенә ышанулары, изге саналган шәхесләрнең исемнәре саклана. Текстларда мәгънәләре аңлашылмаган сүзләр дә очрый. Әмма аларны төшереп калдыру дөрес түгел. Бәлки укучылар арасында бу сүзләрнең мәгънәсен, каян килеп чыгуын белүчеләр булыр.

*Яттым, я Аллаһ,*
*Торырмын, Иншаллаһ,*
*Шушы урынымнан тора алмасам,*
*Бирсен иман бер Аллаһ!*
*Вәли вәлиләре,*
*Вәли солтаннары,*
*Рәхмәтле фирештәләре,*
*Афу кыл!*

*Ай күрдем аман белән,*
*Авызым тулсын иман белән,*
*Шушы айларда үлә калсам,*
*Аллаһым үткәрсен иман белән.*

*Исеме, исеме,*
*Исеме – Хуҗиәхмәт,*
*Бердән меңгә тикле,*
*Хуҗа Әхмәт, еланыңа сәлам әйт.*

*Залари районы Залари поселогы.*
*Лунина Найлә Мөхәррәм кызы. (1956 елгы)*

*Яттым, я Алла,*
*Торырмын, Иншаалла,*
*Бу айда вафат булсам,*
*Иман бирер бер Алла.*
*Иман белән үткәем,*
*Сират күпере кичкәем.*

## Салават әйтү

*Сугыш вакытында бәләкәй балалар кулга-кул тотына идек тә салават әйтеп түгәрәкләп йөри иек. Өй эчендә йөри идек.*

## Теләк теләү

*Көн саен иртән торгачтын тәрәзә каршына килеп, «И Ходаем, рәхмәтеңнән ташлама, озын гомер бир, балаларның башларына зиһен, күкрәкләренә сабырлык, тәннәренә тазалык бир», дип, «И Раббым, бүген тордым, рәхмәт үзеңә, биргән ризыгыңа, биргән гомереңә, җан тынычлыгы бир, Раббым», дип Ходай Тәгаләдән сораем.*

*Коръән укырга барганда мин утырмыйм теләсә кая, мин утырам кыйблага каршы. Кояш самый 12 сәгатьтә кая тора, шунда кыйбла каршысы. Менә монда өстәл икән, килгәч, түр башына утыр, Син укучы әби, дип, түр башына утырталар. Мин анда утырмыйм, кыйбла каршысына утырып дога укыйм. Алла каршысына. Ул әбәзәтелне булырга тиеш.*

## Дини бәйрәмнәр

*Ураза бәйрәме, Корбан гаете, җомга көн. Авылда торганда картлар тәкбир әйтеп гаеткә бараларые. Мәчит барые авылда. Аны Рәхимә апа карый торганые. Бабайлар җыелаларые. Хатын-кызны алмыйларые. Ничәдер адым китәләрие дә, 40 адым китәләр дә, тәкбир әйтәләр:*

*Аллаһы әкбәр, Аллаһы әкбәр,*
*Лә Илаһы Иллалаһу,*
*Аллаһы әкбәр, Аллаһы әкбәр,*
*Шуннан тагын кырык адым китәләр.*

*Тәкбир әйтеп бараларые да мәчеттә укыйларые. Без – балачага барадырыек мәчеткә.*

*Хатын-кызлар инде, әни дә, көлчә пешерә иде пич алдында. Табага салып, пич яна, шунда көлчә пешерәдерие, зур көлчәне майлай. Әни шулкадәр кабартып көлчә пешерә, аны майлап-майлап куя. Шундый карап утырабыз, селәгәебез ага ашарга. «Хәзер, кызым, гаеттән атагыз кайтыр, ашарсыз», – диеп әйтәдерие. Ирләр гаеттән кайтмайча ашамыйдырыек. Шундый гадәт барые.*

### *Ул Мөхәммәт Мостафа*

*Ураза гаетендә «Ул Мөхәммәт Мостафаны» җырлый идек.*

*Аллаһенең дусты син,*
*Әй, Мөхәммәт Мостафа!*
*Безгә шәфәгатьле син,*
*Сән, Мөхәммәт Мостафа!*
*Салаллаһе галәйкә,*
*Йә, Мөхәммәт Мостафа!*

*Җиде кат күкне кичтең сән,*
*Гарештән дә аштың сән,*
*Илаһым берлән серләштең,*
*Әй, Мөхәммәт Мостафа!*
*Салаллаһе галәйкә,*
*Йә, Мөхәммәт Мостафа!*

*Шәригатьне сүзләдең,*
*Тәрикатьне эзләдең.*
*Хакыйкатьне күзләдең*
*Сән Мөхәммәт Мостафа!*
*Салаллаһе галәйкэ,*
*Йә, Мөхәммәт Мостафа!*

*Бу дөньяны сөймәдең,*
*Туйганчы аш җыймадың.*
*Хак коллыгын куймадың*
*Сән, Мөхәммәт Мостафа!*
*Салаллаһе галәйкэ,*
*Йә, Мөхәммәт Мостафа!*

*Тәкъдир булган Алладан,*
*Ятим калган атадан.*
*Һәм шәфкатьле анадан*
*Ул Мостафа Мөхәммәт!*
*Салаллаһе галәйкэ,*
*Йә, Мөхәммәт Мостафа!*

*Атам-анам, димәгән,*
*Бала-чагам, димәгән,*
*Аһ-аһ өммәтем, дигән*
*Ул Мөхәммәт Мостафа!*
*Салаллаһе галәйкэ*
*Йә, Мөхәммәт Мостафа!*

*Ачлыкка сабыр иткән,*
*Нәфескә җәбер иткән,*
*Өммәт өчен аһ иткән*
*Ул Мөхәммәт Мостафа!*
*Салаллаһе галәйкэ,*
*Йә, Мөхәммәт Мостафа!*

*Күп рәхмәт булсын сәңа,*
*Чук сәлам булсын сәңа,*
*Шәфкатъ әйлә сән безгә,*

*Әй, Мөхәммәт Мостафа!*
*Салаллаһе галәйкә*
*Йә, Мөхәммәт Мостафа!*

*Залари районы Залари поселогы.*
*Вәлиева Нәгыймә Һади кызы (1932 елгы)*

*Я Рабби,*
*Рәхмәт кылсаң, рәхмәтең бар,*
*Каһәр кылсаң, кодрәтең бар,*
*Рәхмәтеңнән өметем бар,*
*Каһәреңнән куркуым бар.*
*Колларыңа кол итмә,*
*Дошманыңа хур итмә,*
*Шайтаныңа яр итмә.*
*Изге колларыңнан аерма.*
*Иманымны үзең сакла.*

*Шөкер кыламын барлыкка,*
*Төшермә безне тарлыкка,*
*Барчабызны ярлыка,*
*Яраткучы Җәббар[1],*
*Сән саклаучы Саттар[2],*
*Сән сакла, Ходам.*

*Тырнак-чәчне җиргә ташларга ярамый, яндырырга кирәк. Яндырганда болай дип әйтәләр:*

*Төтене һавада*
*Көле янымда,*
*Исемем Фәйхүнә, дим,*
*шул әйтергә тиеш дип әйтәм инде.*

*Алар районы Шаховский авылы.*
*Галиева Фәйхүнә Зыятдин кызы (1935 елгы)*

[1] Җәббар – кодрәтле, Аллаһның күркәм исемнәренең берсе.
[2] Саттар – гафу итүче, Аллаһның күркәм исемнәренең берсе.

*– Бердән ни дип беләсең?*
*– Бер Аллам, дип беләмен.*
*– Икедән ни дип беләсең?*
*– Ике иңемдәге фәрештә, дип беләмен.*
*– Өчтән ни дип беләсең?*
*– Өч витрны, дип беләмен.*
*– Дүрттән ни дип беләрсең?*
*– Дүрт бурычлы Коръән, дип беләмен.*
*– Биштән ни дип беләсең?*
*– Биш мизгеллек намаз, дип беләмен.*
*– Алтыдан ни дип беләсең?*
*– Ата-ана хакы, дип беләрмен.*
*– Җидедән ни дип беләрсең?*
*– Җиде тәмуг, дип беләрмен.*
*– Сигездән ни дип беләрсең?*
*– Сигез оҗмах, дип беләрмен.*
*– Тугыздан ни дип беләрсең?*
*– Туксак тугыз мәгъриб белән мәшрикъ, дип беләрмен.*
*– Уннан ни дип беләрсең?*
*– Уңлы-суллы сәлам, дип беләрмен.*

*Залари районы Залари поселогы.*
*Вәлиева Нәгыймә Һади кызы (1932 елгы)*

## Бабасы турында

*Это очень-очень давно. Әле Россиядә булган. Минем әткәйнең атасы Мөхәммәтнасыйп. Шул Мөхәммәтнасыйпның атасы Мөхәммәтсалих булган. Ул не только очып кына йөргән, су өстеннән йөгереп тә йөргән ул. Бәләкәй генә карт булган, Салих карт диләр иде. Салих карт булган. 150 лет тому назад. Әткәй сөйли иде. Ул вакытта 7–8 яшьтә булгандыр ул.*

*Үрмәт авылында яшәгәннәр. Карт атамның авылына, әткәйнең атасына кунакка килгән ул Мөхәммәтсалих бабай. Та-*

*тарлар биш вакыт намаз укый бит, ул вакытта татар намазын калдырмаган, иртә, өйлә, икенде, акшам ясыйг.*

*Килгән булган бу Мөхәммәтсалих малаена кунакка, минем әтинең атасына. Әткәй сөйли иде, кич була башлагач, әткәй әйтте ди, шул картатаңны озат, дигән. Әткәй әйтә, басу капкасына җиттек ди. Ул вакытта авылларда басу капкасы булган бит. Мал басуга, посевка китмәсен өчен ул капка.*

*Басу капкасын чыккач, капканы яптык, ди. Шуннан картатам әйтте ди, кич булды инде. Намазга соңга калмаем. Икенде намазына өлгерергә кирәк, әле кайтып тәһарәт аласы бар, дип әйтте ди. Авыллары 12 чакырым, ди. Нинди авыл булгандыр инде ул, исемен белмим. Улым, мин очып китсәм, син курыкмассыңмы, дип әйтте, ди. Нишләп куркыйм, курыкмамын, картәткәй, дип әйттем, ди.*

*Вот, әзерәк йөгереп барды да, очты да китте, диде. Мин кайтып киттем аннары, диде. Ул үзе очевидец. Ул зур түгел иде. Ә малае, минем картәткәй бик здоровый иде.*

*Ул батмаган, су өстеннән йөгереп йөргән.*

*Залари районы Чирмешән авылы.*
*Насыйпов Шәехзаман Шәйхелиман улы (1921 елгы)*

*Минем прапрадедушка, картәтәй Салих, кирәк булган аңарга чыгарга Агыйдел суы аркылы. Кешеләргә соранган кәмәгә, урын аңарга табылмаган.*

*Су буенда җиргә утырган. Аякларын чикатып утыра икән. Әйтә икән: «Сез Салих картны алмадыгыз, ә Салих карт сездән алдарак барып җитә теге якка», дип.*

*Аннары торган да, судан җәяү чәп-чәп-чәп киткән теге якка.*

*Кешеләр кәмәдә килгән вакытта Салих карт теге якта аякларын Агыйдел суында чикатып утыра икән.*

*Ул бик бәләкәй генә булган.*

*Усолье Сибирское шәһәре.*
*Котлыәхмәтова Әнисә Шәехзаман кызы (1956 елгы)*

Экспедиция вакытында халыкның табигатькә сакчыл караштa булуына сокландык. Аларны хәзерге вакытта экологиянең бозылуы, тайганың плансыз киселүе, сулыкларның, бигрәк тә Байкал суының пычрануы бик нык борчый. Информантлар табигать турындагы күзәтүләре белән уртаклашалар. Бу язмалар һәрберсе фольклорга карамый. Шулай да аларны китапка кертү Иркутск өлкәсендә яшәүче халыкның рухын тоярга булыша.

**Табигать**

*Бездә бүреләр күп иде. Аю юк ие. Чирмешәнкәдә аю бар. Чирмешәнкәдә анда Тәңкәле чишмәсе бар. Анда омуль бар икән.*

*Урманны кисеп бетерәләр инде. Урман бик күп иде монда. Монда бит бик куе-куе урман иде. Без урманнан кайтып кермәдек. Һәр агачын белә идек. Урман саклап калды безне, урман үстерде.*

**Кошлар**

*Татарстанда яз көне килә торган кошлар монда килми. Монда кошлардан карлыгачлар гына килә. Үрдәкләр килә. Казлар юк. Карга китми  дә ул. Карга, саескан, чыпчык китмәйләр. Кызым кышын пшено алып кайтып, ихатага чәчеп, ашатам аларны. Аларның ашарына юк бит кышын. Алар монда бала чыгаралар. Хәзер кәккүк урманда бик матур кычкыра. Авылда торганда безнең таллык бар ие. Шул таллыкта сандугач бик матур сайрыйдырые. Сандугач килеп, бер ай гына тора. Ә карлыгачлар киләләр монда. Карлыгачлар абзарда оя ясайдырые. Оясы әселенеп тора. Бер ай эчендә бала чыгара. Балаларын очарга өйрәтә алар. Әй кызык өйрәтә ул. Монда авылда балалар карап торадырыек. Бераз канат ачкач, канатыннан ала да очырып җибәрә. Карга да шулай. Төшә башласа, барып тотып ала.*

*Залари районы Залари поселогы.*
*Вәлиева Нәгыймә Һади кызы (1932 елгы)*

*Аучы-егерь булып эшләгән, үз гомерендә 40 аю аткан Шәехзаман абзыйның белеме нәкъ өч класс була. Максатчан*

*рәвештә үзлегеннән укып ул урманчы, геодезист һөнәрләрен үзләштерә, техник лесовод, урманчы, геодезист булып эшли. 98 яшен ваклаган Шәехзаман абзый[1] урман һәм җәнлекләр турында яратып сөйли. Ул тирә-як урманнарны биш бармагы кебек белә, аларны мең кат ураган. Берәр кеше, бигрәк тә балалар урманда адашып калганда да, беренче аңа мөрәҗәгать иткәннәр. Ул кемнең урманга кайсы яктан кереп китүен сорап, адашучыларның кая булырга мөмкин икәнлекләрен әйтә алган. Шул рәвешле шактый кешене коткарганнар.*

*Шәехзаман абый истәлекләргә күчкәндә, татарчага шактый гына рус сүзләре кыстырып сөйли. Бу – Чирмешән авылына хас күренеш. Аның тел үзенчәлеген саклադык.*

*60 чакырымда Саяны башлана. Анда сибирская сосна үсә. Кедр чикләвек бирә. Көз – август, сентябрь – халык тайгага керә. Чикләвек халыкка әйбәт доход бирә.*

*Биредә ераклык вакыт белән билгеләнә, ераклыкны аны үлчәп караган кеше булмаган. Бу елга 3 сәгатьлек юлда, теге авыл биш сәгатлек, дип сөйләшә идек.*

**Аю турында**

*Аучыга сообразительность кирәк. Мин аны аттым көз көне. Аюга чүт-чүт не попал. Мин бик быстрый и ценный охотник. Карабиным бар иде, пятизарядный карабин. По разрешению. Бүтән пушнинаны малокалибрный винтовкадан аттым. С 1 октября ачалар иде сезон по добычи пушнины. Безнең урманда сохатый водится.*

*Аю – кеше кебек акыллы җәнлек ул. Көз көне бик симерә. Аның сыртында четвертной май. Кыш буена берлогка залегать итә. Берлогта балалай. Язга табарак инде балалай. Үзе очень хитрый, очень умный. Перед залеганием шундай маневрлар ясай,*

[1] Китап әзерләнгән арада Шәехзаман абыйның вафаты турында хәбәр алдык.

*трудно разобраться даже. Куркытсалар, малейшей шум булса, ул анда не залегает. Менә хәзер Федоровскида да бар аю, әйтәләр менә, мин ишетәймен. Анда да бар аю берлогалары. Менә монда бакча артларында аю йөри җәй көне. Хәзер кеше әзәйде, мал әзәйде.*

*Агачка менеп аюдан разве котыла аласың, любой агачка аю менә. Аның тырнаклары бик сильный. Хотя менмәскә дә может. Потому что, аю кешедән курка. Понимает, что кеше очень опасный аңарга. Ул аны понимает.*

*Аюдан, аңарга очрасаң, качарга кирәкми. Йөгерсәң, китә башласаң безовсякого предупреждения инде... Вплотную очраган булды менә шушында. Менә шушында, Самсанкин дигән урында, Чирмешәннән 10 чакрым булыр. Җиләккә барып шулай туры килгән булды. Качарга нельзя. Стойкость. И 3–4 метр калгач туктай бит ул. Бу опасный вакыт. Качарга кирәкми. Бер-ике ыргый да, сине накроет. Стойко кирәк, стойко, стойко. Басып торырга кирәк. Кул белән күрсәтергә кирәк: син нигә килдең минем кырга, бар әнә тегендә, дип. Ул вроде понимает. Конечно, ул не понимает. Барыбер кул белән күрсәткәч, шул якка караен. Акыллы җәнлек ул. Шул якка китә аннары.*

*Метёлькин менә генә бит. 8 километр моннан. Ике малай бар шунда, әле дә торалар әле шунда. Шулар нишләптер урманга чыкканнар да шушы Чирмешән ягына, мылтыклары да булган. Ике балалы аю очраган. Самый опасный аю – балалы аю. Япякын. Шунда берсе атарга ниткән. Нәмә белән заряженный булгандыр инде ул. Аюны дробь белән, кортечь белән үтерәлмисең. Тәне бик каты тәнле. Алгы куллары бик озын. Шунда нишләптер мылтыклары атылмаган. Осечка биргән. Аткан булсалар, аларның икесен дә бетергән булыр иде ул. Аюга кирәк пуля, только пуля. Мин 30–40 ар патрон пуля белән йөртә идем. 18 әр тапкыр атарга туры килгән вакытлар булды. Потому что, точно убойно тидереп булмый. Ул тик кенә тормый бит. Хороший стрелок булсам да мин.*

## Агач кисү

*Агачны в основном леспромхоз заниматься итәләр. Алар с 39 годов. Первое, урманны кисәләр иде, шпалы готовили тимер юлына. Доход кирәк бит, апакаем, торырга. Тордык бит инде, сера, сагыз җыеп, җиләк сатып, сазда үсә торган мүк җиләге диләр, клюква, чиремшә сатыла. Бәйрәмнәр по татарскому стилю ул вакытларда. Дини бәйрәмнәр. Ураза бәйрәме, Корбан бәйрәме. Основной татарларда. Алар күп түгел татарларда.*

*Өй салыр өчен агачны көз мәлендә кисәләр. Агач туңа башлагач. Мин аның вакытын оныткanмын инде. Ае-көне бар иде. Олы кешеләр әйтә иде. Бу йортны үзем, үз кулларым белән салдым.*

*Сайлана деловая древесина. Строительный диаметр опреденный диаметр – 32–34–36 см. Бик җуаннары бар ие – 60–70–80 см. Аларны бетерделәр инде. Шул вакытларда государство аларны безхозяйственно бетерде. Разбазарило. Видимо сугыштан соң доход кирәк булган.*

*Чирмешәндә узкоколейка бар иде, агачны кышын җәен ташыйлар иде. Башта паровозлар бар иде. Аннары тепловозлар китте инде.*

*Безнең район авыл хуҗалыгы районы иде.*

## Күлләр турында

Отделка строений традиционно исполняет не только декоративные функции, но и служит оберегом. Некоторые хозяева до сих пор следуют традиции размещать у входа в усадьбу конскую подкову. По сообщению Рогачевой (Кутлахметовой) Гэльсэм Нурдовлятовны (1939 г. р., с. Черемшанка), это привлекает удачу и счастье, и «дом будет – полная чаша». Однако в последние десятилетия традиции стали забываться вместе с верованиями. На смену богато декорированным орнаментальными узорами домам, передающим этническое своеобразие жителей, приходят обезличенные, обшитые сайдингом постройки с пластиковыми окнами. В то же время в селах Иркутской области еще встречаются усадьбы, постройки в которых украшены многолепестковыми розетками, трилистниками, что можно рассматривать, как наследие тюркской культуры.

В деревянной резьбе татар Иркутской области нередко встречается солярная тематика, отражающая, по мнению Л.М. Шкляевой, архаичные мотивы, связанные с поклонением богу Тенгри[1]. Солярные розетки, расчлененные желобками на сегменты, часто выполнены в технике рельефной резьбы на очельях наличников.

Второй традиционный и, как правило, обязательный элемент украшения очелий наличников – орнамент в виде ромба[2]. В Иркутской области белые ромбы располагаются либо в центре, либо по краям очелий наличников синего, реже зеленого цвета, что позволяет, вслед за Е.П. Бусыгиным, соотносить данный элемент с земледельческим знакам поля и зерна[3].

---

[1] *Шкляева Л.М.* Особенности народного декоративно-прикладного искусства татар Самарской области // Милли-мәдәни мирасыбыз: Самара өлкәсе татарлары. С. 180.

[2] *Валеев Ф.Х.* Народное декоративное искусство Татарстана. Казань: Татарское книжное издательство, 1984. 188 с.

[3] *Бусыгин Е.П., Зорин Н.В., Токсубаева Л.С.* Декоративное оформление сельского жилища в Казанском Поволжье. Казань, 1986. С.58.

Лишь в селах Черемшанка и Шаховская нам удалось увидеть восходящий к салтово-маяцкой культуре цветочный орнамент, выполненный в технике пропильной резьбы (сквозной и ажурной). Обязательными элементами данного орнамента выступают традиционные для тюрок трилистники. Еще одним элементом декора оконных наличников выступают капли в форме сердца.

Следующий, используемый в отделке наличников окон мотив – орнитоморфный, воспроизводящий как стилизованные образы птиц по краям наличников (село Залари), так и стилизованные птичьи клювы, развернутые по разные стороны от находящейся в центре очелья наличника солярной розетки.

К концу XX века символика стала забываться. Современные дома зачастую украшают в соответствии с эстетическим вкусом хозяев. Так в селе Новоселово мы встретили усадьбу, расписанную масляными красками хозяйкой – Шарифуллиной Флюрой Тагировной (1955 г. р.). Росписи здесь располагаются как на наружных стенах дома и построек, так и внутри веранды (йолды), стекла которой также покрыты рисунками, создающими имитацию витражей. Флюра Тагировна расписывает свой дом на протяжении последних 28 лет.

Примерно до середины XX века татары Иркутской области оформляли интерьеры домов, активно используя традиционные элементы – в беленых изнутри деревенских избах для украшения оконных и дверных проемов, а также для деления внутреннего пространства помещения использовались занавески. Над дверью размещали написанные тушью шамаили (многие местные жители называют их «текст с молитвой»). В деревне Черемшанка сохранился шамаиль, созданный в советское время местным самодеятельным художником Гаяновым Мирдазяном Булатовичем (1927–1969). Однако сейчас интерьер домов и квартир практически потерял этническое своеобразие: исчезли вышитые изделия, домотканые коврики. Им на смену пришли чеченские шамаили, репродукции картин и фотографии. Лишь в некоторых домах сохранились отдельные элементы традиционного оформления домашнего интерьера. Так в поселке Кутулик в доме Ишбулатовой

Раисы Бадрихтиновны (1941) отсутствуют межкомнатные двери, вместо них хозяйка использует занавеси. Она уже не помнит их татарское название, однако отмечает, что так было в доме у ее родителей. По ее мнению подобные занавеси дают ощущение свободы, открытого, безграничного пространства.

В конце XIX – начале XX веков своеобразной являлась погребальная культура татар в г. Иркутске. Памятники на городском мусульманском кладбище, созданные из местного камня, воспроизводят ствол дерева с обрубленными ветвями, что совершенно не характерно для традиционных татарских надгробных памятников. Объяснений данному факту респонденты предоставить не смогли. В то же время наличие подобных памятников на захоронениях местного еврейского и русского населения свидетельствует о наличии в городе мастеров, специализирующихся на изготовлении подобных надгробий и их широком распространении у всех проживающих в городе народов.

Сохранению культурного наследия татар Иркутской области способствуют музеи. Они расположены в 4 населенных пунктах (см. Приложение).

Специальный Татарский этнографический центр функционирует в Доме национальной культуры д. Кулиш Чунского района. Работу по созданию краеведческого музея деревни работники Дома национальной культуры совместно с активными жителями д. Кулиш начали с 2002 года. На сегодняшний день его фонды насчитывают свыше 4000 экспонатов и более 200 записей воспоминаний старожилов, в которых отразилась история заселения татарами сибирского края. Одной из самых ценных единиц хранения является карта д. Кулиш 1909 года.

В комнате, где разместился музей, оборудован уголок избы татарской семьи начала XX века. Установлена печь, деревянная кровать, детская колыбель, швейная машинка, ткацкий станок. Имеются прялки, самовары, утюги, часы, глиняная посуда, сепараторы, маслобойки. В экспозиции представлена старинная татарская женская одежда, которой более 100 лет, и др.

Материал краеведческого характера бережно собирает директор Заларинского районного краеведческого музея Макогон (Абдуллова) Бибигайша Калимулловна (1958 г. р.). В музее хранится информация не только по истории пос. Залари, но и по истории деревень района, сохраняются образцы татарского женского рукоделия – полотенца, вышивки, головные уборы, а также различные виды прялок, ткацких станков, приспособлений для обработки шерсти и льна. Б.К. Макогон занимается и составлением родословий местных татарских родов, активно вовлекая в эту работу жителей своего района.

К сожалению, не все осознают важность сохранения памяти о достижениях предыдущих поколений в музейных стенах, не ценят доставшиеся им от предков произведения декоративно-прикладного искусства. Так директор культурно-информационного центра с. Черемшанка Елена Анатольевна Мухаметзянова сетует: «У многих просила изделия предков для пополнения музейных фондов, однако мало что удалось собрать». Но, с другой стороны, ряд респондентов в поселке Кутулик отмечают, что передавали предметы декоративно-прикладного искусства (вышивки) в местный музей, однако его сотрудники отказались предоставить членам экспедиции материалы, связанные с культурой татарского народа, ссылаясь на их отсутствие.

На наш взгляд, в современных условиях глобализации и размывания рамок традиционной культуры необходимо с особым вниманием относится к местным краеведческим музеям и их этнографическим коллекциям, ведь приобщение к ним способствует уважительному отношению к истории своего народа, своих деревень, почитанию традиции, а в конечном счете усилению самоидентификации человека, как представителя того или иного народа.

Обобщая представленные материалы, можно сделать следующие выводы:

Среди различных видов декоративно-прикладного творчества у татар Иркутской области в первую очереди развиты его женские виды – вязание и вышивка. Данные изделия носят не только бы-

товой, утилитарный характер, но и, выполняют роль маркеров национальной идентичности, так как презентуются и используются во время праздников, в том числе и национальных.

Мужчины ранее активно занимались обработкой дерева (изготовление мебели, хозяйственных орудий, бондарным промыслом, резьбой по дереву), однако, сейчас данные ремесла потеряли былое значение.

Что касается декорирования изделий, то следует отметить, что население воспроизводит отдельные элементы татарского орнамента, однако его символическое значение практически утрачено. Тем не менее, важно, что данный орнамент воплощает эстетику национального мироощущения.

Следует отметить, что на развитие декоративно-прикладного искусства татар Иркутской области большое влияние оказывают мода и соседство с другими проживающими в крае народами. Особенно заметно данное влияние в оформлении экстерьеров и интерьеров как городских квартир, так и частных домов.

К сожалению, практически угасли такие ремесла, как ткачество и войлоковаляние (пимокатный промысел).

В целом же образцы народного искусства татар Иркутской области востребованы, а мастера пользуются признанием. Все больше происходит осознание ценности самобытного художественного творчества, что вселяет уверенность в возможности его дальнейшего развития.

**Приложение**

## Список мастеров декоративно-прикладного искусства

**Художники:**

*Иркутск:* Хаиров Анвар Сафиуллович (1950 г. р.)

*Черемшанка:* Гаянов Мирдазян Булатович (1927–1969)

*Новоселово:* Шарифуллина Флюра Тагировна (1955 г. р.)

**Войлоковаляние:**

*Залари:* Исламгалеевы – работали в артели «Красное знамя» (пимокатный и гребеночный цеха – расчески, гребни из бараньего

рога), Сандыковы (Сандыков Закарья Абдуллович – мастер), Резаковы

**Вязание:**

*Иркутск:* Гаянова Идая Разетдиновна (1896–1964), Гаянова Гульрух Булатовна (1924–2010)

*Залари:* Аширова Мирзия Сафиулловна (1929–2012), Хохрина (Сандыкова) Руфина Закирьяновна (1948 г. р.), Макогон (Абдуллова) Бибигайша Калимулловна (1958 г. р.), Аширова Разия Калимулловна (1949 г. р.), Апсалямова Амина Ахметгалеевна (1957 г. р.)

*Сенная падь:* Галеева Гульсум Муллаяновна (1939 г. р.), Клюшникова (Сайфуллина) Рузия Васильевна (1959 г. р.)

*Черемшанка:* Давлетова Галина Васильевна (1958 г. р.), Гильманова Мавзида Шафеевна (1923 – 2017), Мухаметзянова Гульфаны Карамовна (1936–2007), Прынзина (Мухаметзянова) Екатерина (Кабира) Максюмовна (1994 г. р.)

*Новоселово:* Шарифуллина Флюра Тагировна (1955 г. р.)

*Холмогой:* Шарафутдинова (Бурашева) Рашида Мирзалиевна (1958 г. р.), Нуреева Кристина Васильевна

*Шелихов:* Гайфутдинова Кылара Якуповна (1936 г. р.), Гайфутдинова Раиза Фахрутдиновна (1939–2014), Павлова Лариса Фаритовна (1961 г. р.)

*Кулиш:* Бикбова Юлия, Габзалилова Кристина

**Лоскутное шитье:**

*Залари:* Аширова Разия Калимулловна (1949 г. р.)

**Вышивальщицы:**

*Иркутск:* Ахметшина Гульнур Шафиковна (1949 г. р.), Гайсина Альфия Закиевна (1948 г. р.)

*Сенная падь:* Галеева Гульсум Муллаяновна (1939 г. р.)

*Черемшанка:* Ихсанова Гульрух Тимербулатовна (1924–2008), Рогачева (Кутлахметова) Гэльсэм Нурдовлятовна (1939 г. р.), Абзалтынова Фая (1934 г. р.)

*Усолье-Сибирское:* Асмадиярова Василя Миркасимовна (1958 г. р.), Карымова Танзиля Гаптулловна (1948 г. р.)

*Кулиш:* Мирказимова Минигуль

**Ткачество:**

*Кулиш:* Сагдеева Гульназира, Ахметова Минивара

**Мастера художественной обработки дерева:**

*Черемшанка:* Ахмадьянов, Гаянов Мирдазян Булатович (1927–1969), Ихсанов Габдрахман Гаптракипович (1920–1995),

*Новоселово:* Башаров Тагир Галимзянович (1928– ?)

*Усолье-Сибирское:* Сабиров Ансаф Галеевич (1932 г. р.)

**Мастера по пошиву национального татарского костюма:**

*Ангарск:* Пятайкина (Айсина) Рахиля Нуруковна (1945 г. р.) Ахметшина Гульнур Шафиковна (1949 г. р.)

**Керамист:**

*Залари:* Чернигова Любовь Викторовна (1959 г. р.)

**Строитель:**

*Залари:* Сандыков Закарья Абдуллович

*Шаховская:* Камалов Фарахутдин Камалутдинович

**Бондарный промысел:**

*Черемшанка:* Шамсутдинов Хамит Сарварович (1933–1997), Салимгареев Хаматнур Бахтеевич (1924–1989)

**Музеи:**

Заларинский районный краеведческий музей. Директор – Макогон (Абдуллова) Бибигайша Калимулловна (1958 г. р.)

Культурный центр села Черемшанка. Руководитель – Мухаметзянова Елена Анатольевна (1972 г. р.)

Школьный музей с. Новоселово. Хранитель – Рысметова Ольга Гильфановна.

Татарский этнографический центр в Доме национальной культуры д. Кулиш Чунского района Иркутской области. Руководитель – Надия Галиоскаровна Стрелкова (1955 г. р.)

*Примечание.*

В списке не у всех мастеров указаны личные данные, что связано с отсутствием необходимых сведений у респондентов.

*Алексеев М.П.* Сибирь в известиях западноевропейских путешественников и писателей. XIII–XVII вв. Иркутск. ОГИЗ. Иркутское областное издательство, 1941. – 677 с.

В исторической литературе о Сибири важную часть составляют известия западноевропейских путешественников и писателей. Их записки с характеристикой экономических условий и путей сообщения в Сибири, описанием климатических условий, этнографическими наблюдениями, указаниями на месторождения ценных ископаемых представляют научный интерес и в настоящее время. О каждом из ниже перечисленных путешественников и писателей (в скобках указан год путешествия) дана биографическая справка, фрагменты из книг снабжены научными комментариями.

С. Коллинз (1667)
Я. Рейтенфельс (1672)
А. Доббин (1672)
И. Арн. Бранд (1673)
Эрик Пальмквист
Кильбургер (1674)
Н. Витсен (1675)
Бальтазар Койэт (1675)
Гильдебрант фон Горн (1684)
Ф. Авриль (1687)
Жербильон (1689)
Г. А. Шлейсинг (1690)
Де ла Невилль (1691)
Исбрант Идес (1692)

# ИНСТИТУТНЫҢ 1971 ЕЛГЫ ФОЛЬКЛОР ЭКСПЕДИЦИЯСЕ ВАКЫТЫНДА ТУПЛАНГАН ХАЛЫК ИҖАТЫ ҮРНӘКЛӘРЕ

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының 1971 елда Иркутск өлкәсендә узган экспедициясендә Флора Әхмәтова, Ленар Җамалетдинов, Филисә Хәкимова һәм Дания Миңнуллина катнашалар. Бу экспедиция вакытында галимнәр күпсанлы әкиятләр, җырлар, бәетләр, мөнәҗәтләр, уеннар, йола текстлары, ырымнар, ышанулар язып алалар. Шунысы да игътибарга лаек: 2018 елгы экспедициядә дә шушы ук җырлар, бәетләр, ышанулар очрады. Димәк, буыннар арасындагы бәйләнеш исән, халык рухының көзгесе булган фольклор әле яши.

Экспедиция вакытында язып алынган материаллар Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана. Биредә шул материаллар арасыннан иң кызыклыларын сайлап алдык.

Иркутск өлкәсендә «Сак-Сок» бәетенең берничә варианты язып алына. Иң уңышлы ике вариантны китапка да кертәбез. Җыентыкта шулай ук татар халкының йола җырлары, сюжетлы җырлар, ырымнар, әкиятләрдән үрнәкләр дә урын алды.

## Өркет

Иркутск шәһәре татарча Өркет дип йөртелә. Әнгәр (Ангара) елгасында тора. Халык саны ярты миллион, шулар эчендә татарлар саны 6000 (1959 ел переписе). Элек татар клубы булган. Революциягә хәтле һәм аннан соң. Шул елларда ук атаклы

драмтүгәрәге була. Режиссеры Ибраһим Тинский һ.б. Билгеле артистларыннан Кәшифә Тумашева (хәзер ТАССРның атказанган артисткасы) һәм укытучы Гайшә Мендеева (хәзер укытучы-пенсионер). Татар мәктәбе булган. Хәзер уку рус телендә.

1916 елда I гильдия купец Шәфигуллин мәчет салдырган. Аның уллары совет специалистлары булган, Казанда торалар. Мәчет берничә ел ябылып торган, хәзер эшли. 50–60 лап кеше йөри.

Татар интеллигенциясе бар. Художниклар фонды директоры – Закиров Әнвәр Шакир улы, художник. Аның энесе Әкрам университетта философия укыта, доцент, Ильясов – мединститутта укыта. Тау инженерлары Сахабов, Урманчеев һ.б. Язучы Хәерниса Сафина Иркутск татарлары тормышыннан романнар яза, «Гульшира» дигәне 1968 елда басылган, икенчесе чыгарга тиеш шул елларда. Үзе пенсиядәге укытучы.

(Татар клубы хәзерге Тимерязев урамында Алексеев йортында булган. Хәзерге дом офицеров.)

Иркутск өлкәсендә татарлар ике төбәктә урнашкан: көнчыгышта бурят милли округында өч районда – Эхирит-Булагат, Аларский һәм Бохан районнары. Көнбатышта – Чуна һәм Тайшет районнары. Көнчыгышта татарлар бурят, урыс, украин, литвалы һ.б. халыклар белән аралаш яши.

*Ф.Әхмәтова язып алган. 1971 ел*

### Бала тирбәткәндә

Әлли-бәлли көйләрем,
Хикәятләр сөйләрмен,
Сиңа теләкләр теләрмен,
Бәхетле бул диярмен.
Йокла улым, йом күзең,
Йом-йом күзең йолдызым.
Кичтән йокың кала да,
Егълап үтә көндезең.
Әлли-бәлли итәр бу,

Мәдрәсәгә китәр бу.
Тырышып сабаклар укыгач,
Галим булып җитәр бу.
Йокла бәбкәм,
Йокла бәбкәм.
Әлли-бәлли, бәлли бәү.

*Алар районы Чичкәү авылы.*
*Хәмидуллина Мәгъсүфә Әдиятулла кызы (1907 елгы)*

**Туй җыры (кыз елату)**

Агайкаем киткән сунарга,
Төлке аяклары тунарга,
Агайкаем, һиңә мин килдем
Бер һумлыккай тәңкә һорарга.
Арттан килгән кодаларның
Өшлиякәйләре яшел чук.
Алдан ла килгән баш коданы
Илаһым кадир яшен һук.
Урак та урдым сызганып,
Печән дә чаптым сызганып.
Атакаем мине яшьтәй бирде
Кара икмәккәйләрен кызганып.
Кода да булган Таһирның күлмәге
Сандыкта ятып кабыккан.
Кияү дә булган Локман-Хәким
Пивнойда ятып ябыккан.
Аргы якта да ак тана,
Бирге якта да ак тана.
Кодагый да булган Латифа
Кеше бүркен киеп мактана.

*Алар районы Новоселово авылы.*
*Нурдәвләтова Гелмениса Әхмәтҗан кызы (1903 елгы)*

## Кыз озатканда

1. Аршын да аршын ак ука,
Акбүз аткаема дилбегә.
Китәр лә чакта җеп бәйләдем
Туган илләремә билгегә.
2. Тептер дә тептер таягым
Тептердәп калды шушы илдә
Кыңгырау кебек тавышым
Җыңгырдап кала шушы илдә.
(җеп бәйләгәннән соң)
Түгәрәк тә күлне өч әйләндем
Аккаршанкай кебек ялтырап.
Кәйнә каршысына барып төшкәс
Сәгать ярым тордым калтырап.

*Алар районы Новоселово авылы.*
*Нурдәвләтова Гелмениса Әхмәтҗан кызы (1903 елгы)*

## Авыл читендә
## (Кирпичики көенә)

Авыл читендә, бабай йортында
Ишле гаиләдә мин тудым.
Абыйлар белән, апалар белән,
Тугыз яшьтән эшкә тотындым.
Күңелле иде, абыйлар белән бергә
Рәхәт гомер итүе,
Җәйге көннәрдә, таң нуры белән
Төялешеп эшкә китүе.
Күпкә бармады шатлыклы көннәр
Канлы сугыш тиздән башланды.
Кырык яшьтәге безнең әткәбез
Ут эченә илтеп ташланды.
Зур абый китте кызыллар белән
Дошманнардан илне сакларга.
Кечкенә абый мылтыгын алып,

Үз ирекен китте якларга.
Бердән беркөнне, кара урманда
Ишетелде мылтык тавышы.
Зур абый белән кечкенә абый
Атышалар кара-карышы.
– Атма туганкай, куй мылтыгыңны
Энекәшең бит соң синең.
– Юк минем энем, бүгенге көндә
Туганкаем түгел син минем.

*Алар районы Новоселово авылы.*
*Мугинова Зөһрә Әхмәтҗан кызы (1919 елгы)*

**Сак-Сок бәете**

Әнкәй каргагач, Сак-Сок булдык без,
Бу дөньялардан гыйбрәт алдык без.
Бардым урманга, җиләкләр пешкәч,
Әткәй җылыйдыр, исенә төшкәч.
Төшкәндер безгә әнкәй каргышы,
Үзебез тугач та тәкъдир язмышы.
Әнкәй ашыңны нигә күп иттең,
Әткәй кайтканчы безне юк иттең.
Бардым урманга, кистем пар каен,
Газиз әнкәем сагыныр көн саен.
Кистем пар нарат яңа абзарга
Ике күземнән канлы яшь ага.
Йокыга киткәч, бер төш күрдем мин,
Кара урманда ялгыз йөрдем мин.
Су буйларында диңгез камышы,
Кара урманда Сак-Сок тавышы.
Әчегән сөткә, әнкәй, сусатма,
Мәхшәр көннәргә бәхил бул сана.
Кара бүркемне алып кайтыгыз,
Әнкәйне күргәч, сәлам әйтегез.
Су буйларында балалы үрдәк,

Искә төшкәндә янадыр йөрәк.
Кыйбла яклардан җилләр исәдер,
Безнең нәфгыны әнкәй кисәдер.
Кара карлыгач, сары сандугач,
Әнкәй, елама, үзең каргагач.
Бардым урманга, җыйдым карлыган,
Без җәтимнәрне әнкәй каргаган.
Чыктым басуга урак урырга,
Кодай язгандыр Сак-Сок булырга.
Җаңгыр җавадыр әнкәй башына,
Җылап бардык без әнкәй каршына.
Каргады безне газиз әнкәбез,
Якты дөньяны күрми калабыз.
Әткәй калдырды өйдә торыгыз дип,
Әнкәй каргады Сак-Сок булыгыз дип.
Мәдрәсәләрдә пиала ишек,
Сак белән Сокның тавышын ишет.
Ишек алдында җигелгән пар ат,
Әнкәй каргагач, яралды канат.
Ашын карарсың, гыйбрәт алырсың,
Кошлар очканда карап калырсың.
Өйгән кибәнне җилләр тарата,
Кавышабыз дигәч, хәзер таң ата.
Әткәбез калды безнең мәчеттә,
Без тилмерәбез икебез читтә.
Әнкәй каргады, әнкәй белмәде,
Турыннан уздык, әткәй күрмәде.
Бардым урманга, кистем пар нарат,
Әнкәй каргагач, яралды канат.
Бик күп җыласаң, китапка кара,
Безне сагынсаң, Сак-Сокка кара.
Газиз әнкәем, бер сүз әйтиек
Бәхиллек бирче, өйгә кайтыек.
Бер йыл тулганчы, кайтам, дип йөрдем,
Бер ел тулгачтын өметне өздем.

Җыйган җиләгем калды яртысы,
Ике баланың калмады берсе.
Кояш чыкканда нур тула күзгә,
Кыямәт көн саен кавышу юк безгә.
Мамык шәлемне җилгә очырдым,
Ике баламны каргап очырдым.
Әткәй – сандугач, әнкәй – карлыгач,
Әнкәй, җылама үзең каргагач.
Тауның башында аю үкерә,
Ник каргадым, дип әнкәй үкенә.
Кара күлмәкне кич тә кимәдем,
Чыгып киткәндә, сау бул, димәдем.
Мамык эшләпә башны тирләтә,
Әнкәй каргышы безне нишләтә.
Өйгән кибәнне җилләр тарата,
Кавышабыз дигәч, хәзер таң ата.
Әнкәй кер җуа мил буйларында,
Сак-Сок булуыбыз юк уйларымда.
Сандугач килсә, кума сайрасын,
Балаңны очырдың, кыймә җыларсың.

*Алар районы Хареты авылы.*
*Фролова Елена (1928 елгы)*

**Хан мәчет бәете**

Һәр бинадан биек улып
Күкләргә чыкмыш башың.
Бән беләм белдермәсәң дә
Агадыр канлы яшең.
Бу хәлеңдин шикаять кылды
Сәнең һәрбер ташың.
Калбе минең парә кылды
Шул гүзәл хан мәсчете.
Бер заманда синдә намаз
Укыганнар хан иде.

Кавеме татар һәм төрекнең
Мәзкәне Казан иде.
Ул заманны тасвир итсәң,
Нә гүзәл заман иде.
Калбеминең парә кылды
Шул гүзәл хан мәсчете.
Бер заманда сәндә торды
Әһле ислам гаскәре.
Калбе минең парә кылды
Шул гүзәл хан мәсчете.
Башкаларның җире улды
Ошбу көн ислам җире.
Калбе минең парә кылды
Шул гүзәл хан мәсчете.
Һәпкәлисә уртасында (чиркәүләр арасында)
Ялгызың калдың, мәсчет.
Илтифатың без татардин
Сән бина алдың нә гөн.
Әһле ислам калбенә син
Хәсрәтен салдың нә чөн.
Калбе минең парә кыйлды
Шул гүзәл хан мәсчете.
Сән өмет өзсәң дә бездин,
Без өметне өзмәдек.
Заһирең һәр түзсә дә дус,
Калбемездән түзмәдек.
Жаһил улган ул заманны,
Кыйммәтеңне белмәдек.
Калбеминең парә кылды
Шул гүзәл хан мәсчете.

*Иркутск шәһәре.*

*Галиәхмәт (1898 елгы) һәм Гафифә(1906 елгы) Мөхәммәдиевләр*

## Кодалар сыйлау җырлары

Ишекләр дә ачтым, ай гөл күрдем,
Сандыклар да ачтым, мал күрдем.
Сез кодакайларым килеп кергәч,
Асыл кошлар белән тиң күрдем.
Йөгерепкәй төштем инеш дип,
Божралар таптым көмеш дип.
Сез кодакайларны эзләп таптым,
Нәселегез асыл имеш, дип.
Ерактан да яшел ай күренә,
Икәү икән сезнең садыгыз.
Килгәннән бирле карап торам,
Асыл икән сезнең затыгыз.
Ай ил күрә инде, ил күрә,
Ил күрергә чыккан бер түрә.
Без бәбекәбезне сезгә бирдек,
Сез үзегез яхшыга күрә.
Киртәләр дә тотсаң, иртә тот,
Каенлыккайларга җитә тот.
Инде бәбекәбез сезнең кулда,
Кадерләрен белеп иркә тот.
Айлашты инде айлашты,
Табаларда пешкән майлы аштый.
Сезләр китәрсез дә, без калырбыз,
Яфракларын койган агачтый.
Кодалар да китә, озатыйк
Басу капкасына җиткәнче.
Кояшлар да баер, айлар калкыр,
Безләр аерылышып киткәнче.
Көмешкәй дә йөзек мин койдырдым,
Йөз тәңкәгә төште бер ташы.
Безнең кодаларны сорасагыз,
Йөз кешегә тора бер башы.
Түшеңдәге таккан медалеңне
Ничек итеп чутын алаем.

Шул кадәрле асыл кодаларның
Ничек итеп күңелен табаем.

*Алар районы Хореты авылы.*
*Фролова Гыйльменур (1917 елгы)*

**Шәм-Шәрифкәй (көе пленкада)**

Шәм-Шәрифкәй дигән и калада
Акшам җитми капка ябылмый.
Әхәлләли, ваксүләли,
Сүзең булса сүләле (ди),
Йөртмә эчеңдә кереңне (ди),
Белгертмичә сереңне.
Ахшам җитми капкалар ябылмый.
Узган да гынай гомер калган хәтер
Сатып алыем дисәң табылмый.
Элеп ала, селкеп сала,
Җай килгәндә кысып ук ала
Кыз баланы ир бала,
Сатып алыем дисәң дә табылмый.

*Алар районы Шаховский авылы.*
*Латыйпов Гыйлемҗан*

## ЙОЛАЛАР ҺӘМ ЫШАНУЛАР

### Калак салу (кашык салу)

Искечә Яңа ел көнне җыелып утыручылар сулы чиләккә тамгалап кашык салалар. Катнашучыларның берсе суда килеш бер кашыкны ала да «җырлагыз», ди. Кем кашыгы икәнен белмичә, багышлап ике җыр җырлана. Шул җырлар буенча кашык хуҗасының киләчәк язмышы билгеләнә. Шуннан соң кашык иясенә кайтарып бирелә. Җыр белән юрау тәмамлангач, кашыкларны, янә чиләккә салып, чыгарып түгәләр. Кашыкта калган

суны һәркем баш түбәсенә сала. Янәсе, шулай иткәч, сөйгәне белән кавыша. Кемнең кашыгы капланса – сөйгәне үлә.

### Келәт тыңлау (тынса йөрү)

Искечә Яңа ел көнне (14 нче числода) төнлә белән теләсә кайсы кешенең келәтенә барасың да тыңлыйсың. Бай торыр булсаң – «кыштыр» итеп әпәй бушаткан кебек була келәткә. Ярлы торыр булсаң – доң-доң-доң итеп бөтен җире жыңгырдап тора.

### Төнлә әтәч кычкырса...

Төнлә әтәч кычкырса, еллар тыныч булмый, имеш. Кичтән вакытсыз кычкыра ул кайчак 1–2 мәртәбә. Хәзер кычкырганнары ишетелгәне юк ахрысы.

*Алар районы Шаховский авылы.*
*Төхфәтуллина Сания (1919 елгы)*

## Керәшен татарларының ышанулары (күрәзәлек итүләр)

### Йөзек салу

Бу – Яңа елга 6 көн калгач үткәрелә торган ышану. Йөзек салган вакыт дип данлыклы була ул чор.

Аулак өйгә яшьләр җыелгач, өч бертуганны (иң олысын, уртанчысын, иң кечесен) суга җибәрәләр. Алар кое янында, сулы чиләк һәм үзләре эчтә калырлык итеп, пычак белән түгәрәк сызалар.

Кое янында чиләккә көмеш балдак һәм акча салып болгаталар. Акча кайсы ягы белән төшә (күнме, иләкме) – юрыйлар. (Күн булса, – ел әйбәт килә, имеш.)

Шуннан сой чиләкне, чәнчә бармакка гына элеп, алып кайталар.

Суны өйгә алып кергәч, «дәүләт кайтты, дәүләт кайтты» дип кычкырышалар. Шуннан соң шыпырт кына утырырга кирәк.

Сулы чиләкне беразга мичкә куеп җылыталар (ләкин температурасы күтәрелмәсә дә ярый). Чиләк шаулыймы-юкмы – тыңлыйлар. Шауламаса ел тыныч була. Ел тыныч булмаса – шаулый.

Шуннан соң бер кеше яшьләрдән йөзек һ.б. әйберләрне җыя һәм әлеге әйберләрне чиләккә сала.

Беренчесе чәнчә бармак белән әйберләрне суда болгата. Икенчесе чиләк өстен каплап тора. Беренчесе су эчендә йөзекне кулга ала да, «җырлагыз, кемдә җыру», ди.

Шуннан соң әлеге йөзек иясенә багышлап җыр әйтәләр. (Көе белән җырланмый).

Әйтелгән җырны юрыйлар.

Беренче кеше: «Бу кем балдагы?» – дип сорый. Әлбәттә, йөзек яисә балдак иясе үзенең әйберен таный. «Минеке», – ди, ала. Аңлап җитмәсә, кабатлап та сорый ала.

Мәсәлән, түбәндәге җырлар булырга мөмкин:

Туган-үскән җирләремә
Әллә кайтам, әллә юк.
(Кайтмаган, югалган).
Урам буе киртәсе,
Думбра чиртеп үтәсе,
Өстәл өсте тулы сыйны
Ничек ташлап китәсе.
(Әтисе үлгән)

Процесс өч мәртәбә кабатлана. (Әйберләрне тагын ике мәртәбә җыялар). Беренче чиләккә әйбәт җырлар җырларга тәкъдим ителә. Өченче чиләккә – теләсә нинди җыр.

Башка кешеләргә (туганнарыңа, дусларыңа) багышлап та (ниятләп) йөзекләр салырга ярый.

### Көзге белән күрәзәлек итү

Максат – булачак киявенең яисә кәләшенең кем икәнен белү.

Аулак өйдә кызлар стенага терәп ат дугасы утырталар. Дуга эченә ике якка ике шәм яндырып куялар. Шыпырт кына утыралар.

Кызлар чиратлашып, шул көзгегә карыйлар. Анда булачак кияү күренә, имеш.

Егетләр дә карыйлар. Бер егет, мәсәлән, сөйгән кызын чылбыр тотып килгән хәлдә күргән. Килеп җиткәндә генә «тын бетте» дип каплаган. Югыйсә чылбыры белән буып үтерә икән.

*Бохан районы Бохан авылы.*
*Григорьева Аксенья*

## Басу тыны

Яңа ел алдыннан бер атна дәвамында басуга тынга баралар. Җиргә ятып тыңлыйлар, ипи буласы елны шыгыр-шыгыр, шыгыр-шыгыр арба тавышы ишетелә. На... на....на... дип кычкырган кеше тавышлары ишетелә. Ипи булмаслык елны арбалар шалтыр-шолтыр, шалтыр-шолтыр киләләр, ди.

## Чәч йозаклау

Кыз чәчен икегә үрә дә чәчен йозаклый. Ачкычын баш астына тыгып, ятып йоклый. Төшендә сөйгән егете килә дә ачкычны сорый: «Давай ачкычны», – ди.

Шулай итеп, кыз булачак киявенең кем икәнен белә.

## Чиләк йозаклау

Кыз кич уеннан без время кайта да шулай ук без время коедан ике чиләк су алып керә. Аннан соң әлеге чиләкләрне йозаклап куя.

Кемгә барасы булса, йоклагач, шул ачкычны сорап килә.

## Мунчада көл иләү

Төнлә без время мунчага барып, идәненә көл иләп кайтасың. Шулай ук без время барып көлне карыйсың.

Бай торасы булсаң, күн итек белән баса, ди, урта тормышта торасы булсаң – чабата белән, ә ярлы торасы булсаң – яланаяк баса, ди. Эзләре кала икән. Жен басамы инде, кем басадыр – анысын белмим.

*Бохан районы Бохан авылы.*
*Григорьева Аксенья*

## Мунча тәрәзәсеннән кул тыгу

Без время төнлә мунча тәрәзәсеннән эчкә кулны тыгасың. Әгәр җонлы кул белән тотса синең кулыңны, будто син бай торасың, шәрә кул белән тотса, ярлы торасың инде, будто. Әти сөйли иде боларны.

*Бохан районы Бохан авылы.*
*Григорьева Аксенья*

## Йолалар

Табынга хуҗа ризык алып кергәндә барысы да «бәрәкәт» дип кычкыралар. Кем кычкырмый, шуның хатыны кысыр кала, диләр.

Мәҗлес ахырында кунакларның иң олысы хуҗага «тау итеп» рюмка бирә. Хуҗа урыныннан тора, әлеге кунак янына килеп рюмканы ала һәм, җыр белән кайтарып, яңа рюмка бирә.

*Алар районы Хареты авылы. Мәҗлестә язып алынды*

## Яңа ел ышанулары

Яңа ел башында базга төшәләр дә, утыра бер кеше ялгыз гына. Анда кезге куя каршысына, стакан белән су ала, суга йөзекне сала. Аннан кире ак тастымал аның иңсәсендә була. Шуннан карап утыра-утыра да үзенең йөргән кешесенме (кызлар булса инде) или бер кешесе читтәме, иреме анда, читтә булса, шул килеп чыга башлый инде көзге эченнән, йөзек эченнән инде. Көзгедән күренә. Шул инде якын килә, килә дә, якын килеп җиткәндә генә, ак тастымалны яба. Көзгегә яба. Көзгегә яба да якын килеп җитсә курка.

*Алар районы Чичкәү авылы.*
*Хәмидуллина Мәгъсүфә (1907 елгы)*

## «Юлың уң булсын дисәң»...

1. Әйтәләр инде менә бездә, кайбер кешенең аягы авыр дип. Бездә шундый бер кеше бар иде. Очраса – юлың уңмай инде

гомергә. Кер дә кит кирегә. Бездә әйтәләр иде инде, ишеткәнем бар, песәй үтерсә шулай була дип.

2. Аннан юл ырымнары күп инде ул. Менә буш көянтәгә очрасаң, бидрәләре сусыз булса инде, бер дә эш уңмай тагын. Тулы әйбергә очрасаң, бар да әйбәт була. Үземнең сынаганым бар минем менә.

3. Тагы юлдан борыныңны җырып песәй чыкса бигрәк тә. Без бәләкәйрәк чакта шулай песәйләр белән куышып йөри идек, борынны җырмасын дип.

*Чуна районы Кумин авылы.*
*Гәрәев Габидулла Минневәлиулла улы (1896 елгы)*

### Кыз төшерү йоласы

Элек бит инде кыз белән егет өйләнгәнче бер-берсен күрмәгәннәр дә. Аксакмы, картмы, сукырмы. Әтәләре кемгә бирсә, шуңа чыкканнар инде. Элек карышулар булмаган бит бик.

Әгәр дә кыз белән егет электән белешсәләр инде, үзара сөйләшәләр, вәгъдәләшәләр инде.

Аннан егет кыз йортына яучы җибәрә инде. Әнәләре-әтәләре туй көнен билгеләйләр.

Элек инде шулай ие. Туй алдыннан бер атна кияү егете кияүләп йөри торган иде кызны. Шундый гадәт бар инде, иртән коймак пешереп кертәләр күршеләреме, туганнарымы инде, кем тели анда, кыз белән егет кушылгач инде бу, бик иртә белән үк кертәләр. Ул коймакны кияү коймагы дигән булалар инде, вак кына, юка гына була инде ул.

Шуннан инде, кыз «дөрес» булмаса, егет коймакның уртасын гына тешләп куя.

Коймак кертүчеләргә кияү бер сабын бирә инде. Элегрәк без яшь вакытта шулай иде. Хәзер алалар да кайталар инде сразы. Алар бетте. Электәге кебек күңеллелекләр.

Шуннан мунча ягалар, аш үткәрәләр. Аннан туй көнне ат җигеп, шаудырлар тагып, әй кияү егете килә инде, кызны алмага. Ат башында күчер егет була әле, ат тотып килергә. Килгәч,

кияүгә ак перчәткә кигерәләр кулына, моны кыз бирә инде, янәсе, бүләк итеп. Күчергә дә бирәләр инде, перчәткә дә бирәләр яулык та инде.

Әле чәй эчәләр, әзерләр торалар инде өйдәге кешеләр, кыз өендәгеләр инде болар. Шуннан кызны озаталар инде егет өенә.

Алдагы атта ястыклар салып кыз белән егет китә, шаудырларын шалтыратып. Алар артында бирнәләре була инде кызның. Аннан кода-кодагыйлар, шунда кыз ягындагы туганнар китә инде. Бөтенесе урамны әйләнәләр әле болар, бөтен кешегә күрсәтеп инде, янәсе.

Ярар хәзер кыз төшә бит инде егет йортына. Хәзер кыз төшүгә мендәр ыргыталар җиргә. Кыз төшә инде аттан, шуңа басып. Моны инде, янәсе, килен буласы кеше йомшак күңелле миһырбанлы булсын өчен диләр инде. Тагы конфит каптыралар. Имеш теле шул конфит кебек татлы булсын.

Инде бит бу вакытта ишек аллары тулган кешеләр белән, бала-чагалар җыела монда бик күп. Болар кияүне кертми торалар. Шунда куеныннан алып, берәр тиенлек акчалар, конфитләр чәчә бу балаларга. Шуннан өйгә үтәләр. Шулай була инде менә кыз төшерү. Элек шулай бик күңелле йөриләр иде менә.

*Алар районы Чичкәү авылы.*
*Шәйдуллина Сәвия (1904 елгы)*

## Ырымнар турында

1. Элегрәк ул ырымнар бик күп була иде инде, хәзер без дә бик уйламыйбыз инде.

Элек миңа әти әйтә иде:

– Түбән карап йөрмә, кеше өметен өзәр, – дибәйтеп.

Аска карап йөрүчеләрне шулай дияләр иде.

2. Балаларга күз тия, диләр бит, сокланып карасаң да, я сүсәң ныграк.

– Әй, бу кешенең күзе каты, диләр.

Файдасы булды микән соң инде без балаларга кара мунча ташын апкайтып шуның суы белән коендырып йөри идек, картлар әйткәч.

3. Тагын маңгайларын, битләрен тәрәзә тире белән сыпырасың. Күз тигәнгә ару була иде бугай инде.

4. Тагын яшь баланы коендырганда, аркасыннан су йөгертәсең дә, суын авызың белән җыясың да әйтәсең:

– Минем кулым түгел, Гайшә Батман кулы, – дип. Ул күз тимәсенгә дә инде. Авырмасынга да.

5. Аннан очан чыкканны имли идек. Эч авыртканда инде. Аклауны аласың да, очы белән әкрен генә йөртәсең инде.

– Ни булган, очан булган. Очсын, китсен, бетсен, дип өч-дүрт тапкыр.

6. Аннан башым ауган, диләр. Без баш авыртканда шулай үлчәтә идек. Мунчала аласың да башка кигереп төйнисең шуны, аннан соң инде ипи әнәләгән кебек итәләр дә башны шуның төененә карап беләләр инде, баш ауганмы. Ул төен ике якта да була. Шулар авышкан булса, әйтәләр инде, баш ауган, дигән булып.

*Чуна районы Күлиш авылы.*
*Юнысова Кафия Мостафа кызы (1908 елгы)*

## Яңа елга каршы 13 – 14 гыйнварларда

1. Үзеңнең кая кияүгә китүеңне белү өчен, төн уртасында капка түбәсе аркылы аякларыңдагы киез итегеңне салып ыргытасың. Башы кайсы якка караса, шул якка тормышка чыгасың, имеш.

2. Ниятләнү.

Төн уртасында мунча төнлегеннән кулыңны тыгасың. Йонлы кул тотса, байга кияүгә барасың, шәрә куллы кеше тотса, ярлыга кияүгә чыгасың.

3. Өйгә тавык белән әтәч кертәсең. Анда сукыр лампа гына яндырасың. Аралаш-аралаш күмер, су, ипи, көзге куясың. Алар иң башта су капса, ирең эчкече була, көзгедән караса – укы-

мышлы, этәч белән тавык икесе дә ипи ашый башласалар, тату торачаксың, күмергә ябышсалар, гомерсез буласың.

4. Базга төшеп сукыр лампа яндырасың. Стакан белән су алып төбенә балдагыңны саласың. Стакан артына көзге куясың, йөзекнең уртасына карап утырасың. Егетең күренә, имеш.

5. Тозлы итеп күмәч пешерәсең. Аны ашап йокларга ятасың. Шул егет миңа су китерә, дип ниятләп ятасың. Төшеңдә ул сиңа су китерә имеш.

*Д. Миңнуллина*

## САК-СОК БӘЕТЕ

Дөньяда ниләр булмый,
Бәндәләр ниләр күрми.
Бәндәнең күргән әлге
Тәкъдирдән тышта йөрми.
Игезәк ике бала берәүгә Алла биргән,
Бәхетсез булганнар болар,
Бетергә хәсрәт күргән.
Балалар елап сөйли,
Башындин үткән эшен
Хәсрәтендин моңаеп
Түгәләр ди күз яшен.
Анадин туган идек,
Илдә дә торган идек,
Кеше дә булырбыз диеп,
Фараз да кылган идек.
Икәүләп уйнар идек,
Суларга чумар идек,
Күп вакыт өйгә кайтмый идек,
Бакчада кунар идек.
Без өйгә кайтмаганда,
Эзләп тә тапмаганда,
Ачулана иде әнкәй
Күңеле тартмаганда.

Шаянлык начар икән,
Бозыклык басар икән.
Ата-ана каргышлары
Бик мәхрүм ясар икән.
Көн дә эзли безне әнкәй
Уйнарга чыккан җирдин.
Хурланып эзләвенә
Каргый да куя беркөн.
Яшебез алтыларда,
Акылыбыз яртыларда.
Йөрмәгез, балалар, дип
Әйтәләр шакытларда.
Ходайдин икән язмыш,
Алабыз көн дә каргыш.
Һәркөнне рәнҗегәне
Барсы да безгә бармыш.
Әнинең каргавы хак,
Булганга безләр сак.
Йөрегез, ди, вәйран булып,
Гомергә Сак белән Сок.
Әткәй йокыдан тора,
Аны да моны бирә.
Әнкәй каты эрәнҗеп,
Каргый да читкә сөрә.
Беркөнне уйнап йөрдек,
Кич кенә өйгә кердек.
Төн буенча каргады әнкәй,
Иртән үзебезне кош күрдек.
Карыйбыз без бер-беребезгә,
Яшь килә күзебезгә.
Кич белән кош булганыбызга,
Ис китә үзебезгә.
Әткәй иртән торды,
Өендә кошлар күрде.
Бу нинди кошлар диеп,

Хәйранга калып торды.
Әнкәй белде ахырдан
Балалар кош булганын.
Әткәйгә сөйләп бирде
Рәнҗеп бәддога кылганын.
Әткәй яшь түгәдер.
Кош булгач балалары.
Китәдер, болар диеп,
Урманга далаларга.
Тилмереп карыйбыз без
Әнкәйнең күз яшенә.
Кызганабыз да кунабыз
Башына, иңбашына.
Йөрибез өйдә очып
Кош булып канат сәчеп.
Сәхрәгә очар идек
Булмыйдыр ишек ачып.
Әнкәй дә үкенәдер
Тиешсез каргавына.
Яшь өчен кан түгәдер
Баласыз калганына.
Әйтәдер, бер дә юкка
Каргадым балаларны.
Әз генә куркытырга
Теләдем мин аларны.
Күрәсең туры килгән
Кабулын сәгатенә,
Балалардан калып гомергә
Янарга кайгы утында.
Мине белгәннәр болай
Баланы каргамасын.
Балага каргыш каргап,
Гомергә мәхрүм калмасын.
Кош булгач, карап тордык,
Тилмереп, хайран булдык.

Яшь кенә вакытыбызда
Каргыштан вайран булдык.
Сагынабыз яшь гомерне
Торганыбызны бишектә.
Сәхрәгә очарга дип,
Күзебез гел ишектә.
Әнкәй үкенеп сөйли,
Әткәй үкереп елый.
Безгә дә килеп җитте
Гомернең җиде елы.
Җидегә чыккан чакта
Ишектән тышка чыктык.
Кош булу хәсрәтендин
Бик күп кайгылар йоттык.
Булыгыз бәхил дигәч,
Күзебез яшькә тулды.
Урманга очып киткәч,
Күңелләр башка булды.
Урманга очып җиттек,
Төрле кош сайрый анда.
Кошлар да кызгандылар
Без моңлы елаганда.
Әткәйнең йортында
Бик рәхәт яши идек.
Әнкәй әзерләгәч,
Яхшы ашлар ашый идек.
Урманда агачлардан
Чүплибез каты бөре.
Тәкъдирләр безгә язгач,
Ризыклар шулай йөри.
Берничә көннәргә чаклы
Йөредек кайтып өйгә.
Кайтсак та бер файда юк,
Гомерләр үтә җилгә.
Елыйбыз арыганчы

Әнкәйнең каргышыннан.
Котылып булмайдыр шул
Тәкъдирнең язмышыннан.
Кайтсак та, әнкәй күреп,
Елыйдыр аһлар орып.
Китәбез тагын урманга,
Авылдан бераз торып.
Әткәй дә елый-елый,
Күзләре күрмәс булды.
Безгә дә, өйгә кайтып,
Һич файда бирмәс булды.
Ата-ана дөнья куйды,
Без калдык кошлар булып.
Йөрибез урманнарда
Йөзләрне яшьләр юып.
Уйладык бу каргышны
Бераздин бетәр диеп.
Ахырдан өмет өздек
Гомергә җитәр диеп.
Сагынабыз өйне көн дә,
Курыкабыз озын төндә.
Һаваларда ерткыч кошлар,
Киекләре өстендә.
Караңгы урман эче,
Күкри күк, яшен яшьни.
Давыл чыгып, урман гөрли,
Ялап карлар ява башлый.
Җил-давыл күтәрелгәч,
Аерылдык ике якка.
Каргышларның хәсрәтендин
Аерылдык Сак белән Сокка.
Таң атты, көн яктырды,
Арабыз ерак торды.
Беребез Сак дигәндә,
Беребез Сок кычкырды.

Кояшның батуындан
Тотынабыз кычкырырга.
Каргышларның язуыннан
Булмый шул ычкынырга
Тавышыбыз Сак та Сок,
Хәлебезне белгән юк.
Әдәмдин кошка әверелгәч,
Гомерләр үтә боек.
Кычкырабыз кара-каршы
Кавышабыз дигән чакта.
Якты беленәдер
Кояшның туган якта.
Булабыз ике аеры без
Яктырылгач ерак.
Таң белән кавышабыз дигәч,
Буладыр фрак.
Ике ара тау була да
Кавышабыз дигән вакыт.
Сак та Сок кычкырабыз,
Югалган бездин бәхет.
Каргыштан кавышулар
Дөньядан кала бугай.
Әдәмгә гыйбрәт бу хәл,
Алмасын каргыш шулай.
Хәзер дә ике туган
Икебез ике якта.
Ишеткән елап китәр
Сак та Сок дигән чакта.
Камышлар суга батмый,
Каргышлар кире кайтмый.
Каргышлар ала-ала да
Кайгысыз гүрдә ятмый.
Нәфсегә ирек биреп,
Буй-буйдап уйнамагыз.
Ата-ана догасы

Төшми дип уйламагыз.
Балалар шаярмагыз,
Анага карышмагыз.
Йөрегез әдәпле булып,
Сыйфатны алышмагыз.
Балалар нужа күргән,
Адашып читтә йөргән.
Әдәмгә гыйбрәт бу хәл,
Укысын күзе күргән.
Димәгез юкны язган
Чыгарып ялганлыкка.
Чын, имеш, дип сөйлиләр
Картлардин калганнарга.

*Чуна районы Күлиш авылы.*
*Юнысова Кафия Мостафа кызы (1908 елгы)*

## САК-СОК БӘЕТЕ
### (өзек)

Дөньяда ниләр булмый,
Бәндәләр ниләр күрми,
Бәндәнең күргән эше
Тәкъдирдән тышта йөрми.
Икәүләп уйнар идек,
Суларга сумар идек,
Күп вакытта өйгә кайтмый
Бакчада кунар идек.
Әнкәй каргады тимер ук өчен,
Әткәй каргады бигрәк юк өчен,
Әнкәй каргагач, Сак-Сок булдык без,
Бу дөньялардан гыйбрәт алдык без.

*Алар районы Шаховский авылы.*
*Төхфәтуллин Фатыйх (1906 елгы)*

**БӘЕТ**
**(«Кирпичики» көенә)**

Авыл читендә бабай йортында
Эшче гаиләдә мин тудым,
Дәдәйләр белән, түтиләр белән
Тугыз яшьтә эшкә тотондым.
Бик күңелле иде дәдәйләр белән
Бергәләшеп гомер итүе,
Җәйге көннәрдә таң нуры белән
Төялешеп эшкә китүе.
Күпкә бармады бәхетле көннәр,
Тиздән канлы сугыш башланды,
Кырык яшьтәге безнең әткәбез
Ут эченә илтеп ташланды.
Гомер күрмәгән тимер арбалар
Урамнарны узып киттеләр,
Туры атыбызны ишек алдыннан
Тотып алып җигеп киттеләр.
Дәү дәдәй китте кызыллар белән –
Дошманнардан илне сакларга,
Бәләкәй дәдәй мылтыгын алып
Үз иркеннән китте акларга.
Бердән-бер көнне кара урманда
Ишетелә мылтык тавышы,
Дәү дәдәй белән бәләкәй дәдәй
Атышалар кара-карышы.
– Атма, туганкай, куй мылтыгыңны,
Энекәең бит соң мин синең,
Юк минем энем бүгенге көннән,
Туганкаем түгел син минем.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Сезнең өметегез кан түгү,
Гомер буена коллыкка кереп,
Байлар өчен халык интегү.
Шулай диде дә, мылтыгын төзәп,

Чакмасын чагарга кыймады,
Ул җитешкәнче бәләкәй дәдәй
Китереп йөрәгенә кадады.
Бөгелеп төшә кызыл чәчкәләр
Урманнарда кояш кызуына,
Каргалар белән козгыннар гына
Калды дәдәкәйнең янында.
Шушы хәлләрне бәләкәй дәдәй
Жылый-җылый кайтып сөйләде,
Күп тә тормады, чыгып та китте –
Кабат өйгә кайтып кермәде.
Көн дә җил-давыл, тузаннар туза,
Ничек авылларда торырга,
Йорт-җиребезне байларга сатып,
Киттек эшкә, Себер иленә.
Себер илендә эш табалмадык –
Туры килдек үләт чиренә.
Бигрәк авыр шул чит илләрдә
Ялгыз башың нужа күрүе,
Туган илеңә
Туганнарсыз кайтып керүе.

*Алар районы Хареты авылы.*
*Антонова Ирина Георгиевна (1918 елгы)*

## ӘКИЯТЛӘР

### Мачы башлы ябалак

Бер заман кошлар патшасы җыя кошларны. Сораша:

– Мин сезне ни өчен җыйдым? – ди кошлар патшасы.

Тегеләр әйтә:

– Без белмибез, әйтсәң, белербез.

– Менә шуны беләсем килә минем, дөньяда коры агач күпме, чи агач күпме? Ирләр күпме дә, хатыннар күпме? Шуны беләсем килгәнгә, сезне җыйдым.

Берсе дә әйтәлми. Күплеген дә, азлыгын да.

– Берәр кош калмаганмы? – ди.

Берәү әйтә:

– Мачы башлы ябалак килмәгән, – ди, – ул тычкан саклап калды, – ди.

– Алай булгач, рәхим итеп барып китерегез әле, – ди, – бәлки, ул әйтер, – ди.

Хәзер тегене селкеттеләр, китерделәр.

– Нишләп килмәдең? – ди.

– Соң, вакытым булмады, ашасым килә иде, мин ашамаган идем, – ди, – менә хәзер килдем, – ди.

– Сине шуның өчен чакырттым, – ди, – менә шул кадәрле халык әйтәлмиләр, – ди, – бәлки, син әйтерсең, – ди, – менә шул сүзем, – ди. – Дөньяда коры агач күпме, чи агач күпме?– ди.

– Коры агач күп, – ди.

– Нишләп? Минемчә, чи агач күп булырга тиеш, – ди.

– Юк, коры агач. Менә мин шуны саныйм, – ди, – нинди генә чи агачта коры ботак бар, – ди, – аны мин саныйм корыга, – ди. Менә шуңа коры күп, – ди.

– Ну анысы ярый, – ди. – Риза. Менә син әйт әле, – ди, – дөньяда хатыннар күпме, ирләр күпме? – ди.

– Бит монда уйлыйсы да юк, – ди. – Әлбәттә, хатыннар күп, – ди.

Патша:

– Минемчә бит, ирләр күп булырга тиеш.

– Ә мин бит күп ирне хатыннарга саныйм, – ди.

Нишләп?

– Хатыннар сүзе беләнйөргән ирне мин хатынга саныйм, – ди.

– Дөрес, – ди, – димәк, хатыннар күп, – ди.

Шуннан соң кошлар патшасы Мачы башлы ябалакны, зирәклеге өчен, үзенең вәзире иткән, ди.

*Тайшет районы Тракт Кавказ авылы.*
*Аленгулов Лотфулла (73 яшь)*

## Ут гармуны

Борын заманда була бер карт. Аның була бердәнбер кызы. Бу картның хатыны үлә дә, ул өйләнә икенче хатынга.

Яшь хатын моның кызын яратмый. Картка әйтә:

– Син моны кая булса да илтеп ташла, – ди. – Аннан мин синең белән торырмын, – ди.

Ярар. Теге карт кызын җәлләсә дә, илтеп ташлый бер урманга. Бу кыз була инде унбиш-уналты яшәрлек.

Кыз байтак кына гомерләр йөри урманда, җәй көне була.

Бервакытны агач төбендә утырып торганда, үтеп баручы бер кеше күреп кала бу кызны.

– Син кем, – ди, – адәм баласымы, шайтан баласымы? – ди, кычкыра инде теге ир-ат.

– Мин адәм баласы булам, – ди кыз.

– Нишләп утырасың?

– Килмәгез, – ди, – минем өстем-башым алама, – ди, теге кыз кычкыра, – сез ир-ат, мин хатын-кыз, – ди.

– Ярар, алай булса, – ди, – мин киемнәр алып килим сиңа. Син шушында гына тор, – ди.

Теге ир-ат борыла да кайтып китә, аты белән чабып. Ул моңарга хатын-кызлар киеме алып килә. Кыз, киенгәч, килә моның янына.

Бу яшь була әле. Сораша башлый хәзер.

– Нишлисең син, каян килдең, нишләп монда ятасың? – ди.

– Әни үлде, – ди, – әти яшь хатынга өйләнде. Мин кирәк булмадым яшь әнигә, – ди. – Вәт, шуның өчен әти китереп ташлады мине шушында, – ди.

– Ярар, алайса, мин сине алып кайтам, – ди, – җәмәгатькә барырсыңмы миңа, яшь хатынга? – ди, бу ир әйтә.

Нишләсен инде бу хәзер. Уйлый да риза була:

– Барырмын, – ди.

Шулай дигәч, алып кайтып китә тегене.

Бай кеше була инде бу. Кызның үзенә салдыра бер өй, әйбәтләп. Олы хатыны да була моның, яшь хатыны да булды инде хәзер. Тора башлыйлар.

Бервакытны бу ир хаҗга барырга йөри. Олы хатынына керә дә:

– Син, – ди, – мин кайтуга нәрсә әзерләрсең? – ди.

– Мин сиңа, – ди, – дөньяда юк күлмәкне әзерләрмен, – ди. Хәзер яшь хатынга керә.

– Син нәрсә әзерләрсең? – ди.

– Мин, – ди, – син кайтуга пар бәбәй китерермен, – ди, – берсе малай, берсе кыз булыр, – ди.

Ярар, алайса. Булды. Хәзер бу җыена да китә хаҗга.

Теге карт хатын янына бер белемче-сихерче карчык йөри икән. Шул карчык моңарга дөньяда юк күлмәкне әзерләп китерә.

Яшь хатын да бәбәйли. Ике матур бала китерә. Берсе ир, берсе кыз бала. Әлеге сихерче карчык әби була моңарга.

Ярар. Хәзер теге карт хатын көнләшә бит инде. «Шулай да монықы әйбәтрәк, ике бала китерде, ди. Моны яратыр ул», – ди. Теге карчыкка әйтә инде:

– Нишләтергә бу хатынны? – ди.

– Аны, – ди, – эшлибез хәзер, – ди, – әле бернәрсә дә белми ул, – ди. Ике баланы ала да теге әби булучы, алар урынына ике эт баласы китереп куя.

– Менә син, – ди, – ике эт баласы китердең, – ди яшь хатынга.

Ә теге кендек әбие ике баланы сандыкка сала да суга агызып җибәрә.

Ярар. Балыкчылар тота бит бу сандыкны. Ачып карыйлар – эчендә балалар. Бер карт белән карчык була инде әлеге балыкчылар, бик сөенешәләр. «Безнең бала юк, үстерәбез боларның икесен дә», – диләр.

Карчык үстерә боларны карап, әйбәтләп.

Хәзер теге ир кайта инде хаҗ кылып. Олы хатыны янына керә: дөньяда юк күлмәкне әзерләгән.

Яшь хатын янына керә: моның куенында ике эт баласы.

Тота да, капка төбенә ясата бер йорт, төрмә кебек, ике эт баласы белән хатынны шунда куя. Кергән бер кеше, мыскыл итеп, шул өйнең почмагына сугып китәргә тиеш була. Шулай дип язып куя бу.

Ярар. Ай үсәсен көн үсеп, ел үсәсен ай үсеп, бу балалар үсеп җитәләр хәзер.

Теге хаҗ кылып кайткан ир аучы була. Бу малай да йөри башлый хәзер ауга. Бабасыннан мылтык алдыра, эт асрый. Бер көнне, ауга чыкса, карый, ирне өч бүре куып китерә, теге атасы булган кешене инде.

– Улым, – ди, – зинһар котылдыр мине бу бәлаләрдән, – ди. Теге малай өчесен дә атып ала бүреләрнең.

– Ну, улым, рәхмәт, котылдырган өчен, – ди, – миңа бер кунакка барып чыгарсың әле, – ди.

– Ярар, бабай, ярар, – ди.

Шуннан кайта бу малай. Ә убырлы карчык сизә бит инде хәзер моны, теге сихерче карчык. Үзенә зыян китермәсеннәр дип курка. Шуннан ары бу карчык уйлый хәзер: боларны ничек булса да үтертергә кирәк, бигрәк тә малайны, ди.

Боларны үстергән балыкчы карт белән карчык үләләр. Кыз белән малай хәзер икесе генә торалар инде. Малай ауга киткәч, сихерче карчык килә дә әйтә бу кызга:

– Кызым, – ди, – абыең үсте инде хәзер, – ди, – йортыгызда кеше юк, – ди. – Син кияүгә китәрсең, – ди. – Вәт, бер кәләш алып кайтса, бик шәп булыр иде аңарга, – ди. – Фәлән җирдә су кызы бар, – ди.

Шуннан малай кайта аудан. Сеңлесе әйтә инде моның:

– Абый, – ди, – бер әби килгән иде. Сезнең тормышыгыз бик шәптән түгел икән. Син кияүгә китәрсең, абыең берүзе калыр, – ди, – бер кәләш кирәк инде аңарга, дип әйтә, – ди. – Фәлән җирдә су кызы бар. Су уртасында чәчен тарап утыра торган, шуңа өйләнсен абыең, дип әйтә, – ди.

– Ярар, иртәгә барам, алып булса, – ди, малай әйтә. Иртәгесен бу әзерләнеп чыга. Моның аты телгә килә торган була, кеше теленә. Шундый яхшы ат була ул. Аты әйтә:

– Кая барабыз бүген? – ди.

– Вәт, фәлән җиргә, су кызын алырга барабыз, – ди.

– Ай-яй-яй, – ди, – бик кыенлык булыр, – ди. – Ул су уртасында тора, – ди, – ярый ла аның җилкәсенә эләгә алсаң, – ди. – Мин суны сикереп чыгып китәрмен, син, ат өстеннән сикереп төшеп, аның җилкәсенә эләгергә тырыш, – ди. – Җилкәсенә менеп ат-

лангач, чәченнән урап тот, – ди. – Ул сине алып төшеп китәр су төбенә, – ди. – Алып керер бер йортка, анда аның тора торган өе булыр, – ди. – Ул беренче бүлмәгә кергәч: «Мин синеке, син минеке – төш», – дип әйтер. Син төшмә. «Әйдә алдагысына» дип әйт, – ди. – Икенчесенә керерсең. Тагын шулай дип әйтер: «Мин синеке, син минеке – төш», – дип. Син төшмә, – ди. – Аннан өченчесенә кергәч: «Төш инде, мин синеке, син минеке», – дип әйтер, – ди. – Төшмә, – ди, – өстәлдәге китабын өч тапкыр үпмичә, – ди.

Ярар. Хәзер китә бу. Ат әйткән җиргә җиткәч, атка бик каты итеп суга. Ат сикерә. Шул вакытта бу атыннан төшеп, нәкъ җилкәсенә элгә кызның. Чәченнән урап алуы була – кыз дулап алып төшеп китә тегене су төбенә. Су төбенә төшеп җитә кыз. Алып керә тегене йортка. Кергәч әйтә:

– Төш инде, – ди, – мин синеке, син минеке булдың, – ди.

– Юк, әйдә алдагысына, – ди.

Икенче бүлмәгә керми тора кыз. Малай тегене каешлый әзрәк. Кыз чыдый алмый, керә.

– Ну, төш инде, – ди, – мин синеке, син минеке, – ди.

– Юк, әйдә алга табан, – ди. – Өченчесенә керик, – ди.

Тагы әзрәк каешлап ала тегене. Кыз кереп китә, чыдый алмагач, икенчесенә, аннан соң өченче бүлмәгә.

– Ну, егет, төш инде, – ди, – хәзер мин синеке, син минеке, – ди.

– Юк, – ди, – менә өстәлдәге китапны өч тапкыр үпмичә төшмим мин синнән, – ди.

Үпми. Бу тегене тагы каешлый бераз. Кыз чыдый алмагач барып үбә китапны өч тапкыр.

– Ну, төш инде, – ди, – мин синеке, син минеке, – ди.

– Менә хәзер төшәм инде, – ди.

Ярар. Чыгалар судан. Баралар ат янына. Атланып кайтып китәләр болар икәү. Кайтып керәләр хәзер. Теге кыз белән икесе тормыш итә башлыйлар болар. Егет һаман ауга йөри.

Бердәнбер көнне чыга ауга. Йөри торгач, өч-дүрт бүре теге картны тагын куып китерәләр.

– Әй, улым, – ди, – зинһар коткар бу бәлаләрдән мине, – ди. Ярар. Бүреләрен атып ала тегенең, бабайны коткарып җибәрә.

– Улым, миңа кунакка барырсың, – ди.

– Ярар, бер барып чыгарбыз, бәлки, – ди.

Кайта. Ә теге карчык тагы килә бу йортка, аучының хатыны суга киткәч кенә.

– Кызым, – ди, – абыеңның кәләше булды инде, – ди, – хәзер сезгә сөт күле кирәк, – ди. – Сыерыгыз юк, – ди. – Менә, – ди, – фәлән җирдә сөт күле бар, шуны алып кайтырга кирәк, – ди.

Теге хатын кайтып керә:

– Син, – ди, – берүк ул карчыкның сүзен абыеңа әйтә күрмә, – ди, – ул синең абыеңны үтертергә йөри, – ди каенсеңленә.

– Ярар, – ди кыз.

Әйтмим дигән була инде. Абыйсы капкадан кайтып керү белән бу аның каршысына чыгып әйтә:

– Абый, шундый-шундый хәл, әби килде, сөт күлен алып кайтырга куша, – ди.

– Ярар, Алла бирсә, барырбыз, – ди малай.

Хатыны җылый:

– Барма, – ди, – сине үтертергә йөри ул карчык, – ди, – мин беләм аның нәрсәгә йөргәнен, – ди.

Бу хатын да, су кызы булгач, тылсымчырак була инде, белә.

– Юк, – ди, малай әйтә, – Алланың язмышы, – ди, – үлсәм, үләм, барам, – ди.

Ярар. Хәзер чыга ат янына.

– Кая барабыз? – ди, ат әйтә.

– Менә, – ди, – сөт күле бар икән бер җирдә, шуңа барам мин, – ди.

Ат әйтә:

– Ай-һай, кыен эш бу, – ди. – Ала алырбызмы, юкмы, – ди. – Ала алмасак, икебез дә бетәбез, – ди.

Китте бу малай ат белән. Ат барган җиреннән сөйләшеп бара: «Сөт күле кырындарак булыр бер каен, – ди, – шуңа җиткәч, сугарсың миңа бик каты итеп, – ди, – мин очып китәрмен, – ди. – Очып барганда сөт күле уртасында үсеп утыра торган икенче бер каенга камчы белән сугып, кулыңа бер яфрагын эләктерә алсаң, сөт күле синеке, – ди, – эләктерә алмасаң, икебез дә беттек», – ди.

Шуннан, ярар. Бара-бара, ат әйткән җиргә барып җитә. Атка бик каты итеп суга.Үтеп киткәндә камчы белән теге каенга суга да бер яфрагын эләктереп ала учына.

Ат сикереп чыга. Борылып карыйлар: сөт күле дә юк, шайтан да юк. Борылалар да кайтып китәләр. Кайтсалар, моның ишек алдында инде сөт күле.

Ярар, монысы да булды хәзер. Малай кайтып бер көн ял итә дә тагы чыгып китә ауга.

Теге карчык тагы килә бит боларга.

– Менә, – ди, – абыеңның бар да булды хәзер, кәләше дә булды, сөтегез дә булды, – ди. – Инде үзе уйный торган пластинка бар бер җирдә, шуны да алып кайтса, бөтен илдә дан тотар, – ди.

– Син, – ди, хатыны әйтә кызга, – әйтмә абыеңа, – ди, – ул синең абыеңны үтертергә йөри, ди. Инде безнең бар да бар, җиткән, – ди.

Ярар. Хәзер малай кайта. Абыйсының каршысына тагы чыгып әйтә инде бу кыз:

– Абый, – ди, – сиңа әби шулай-шулай дип әйтте, – ди.

– Барам, – ди, малай әйтә.

Иртән тора да китә бу.

– Ай, – ди, – ат әйтә, бик ерак юлга китәбез без. Бик начар җир бу, – ди. – Бер имән агачы утыра, – ди. – Шуның очында сандык, сандык эчендә үрдәк, үрдәк эчендә күкәй, күкәй эчендә шул пластинка, – ди. – Ул агачны өч тапкыр җылан ураган, – ди.

Шуннан, ярар. Бу барып җитә хәзер. Барып керә бер карчыкка.

– Әби, – ди, – мин шундый йомыш белән килгән идем, – ди.

Бу убырлы карчык була.

– Менә, – ди, – миннән зуррак тутам бар, – ди. – Ул белсә белер, мин белмим моны, – ди карчык.

Ярар. Хәзер тутасына бара бу.

– Әби, – ди, – менә шундый-шундый йомыш белән килгән идем.

– Мин белмим, – ди, – миннән зуррак тутам белсә белер аны, – ди. Хәзер китә бу зур тутасына. Барып җитә.

– Минем, – ди, – кошларым бар, – ди, зур тутасы әйтә, – сорап карармын, – ди, – мин үзем анык белмим моны, – ди.

Хәзер җыя бу бөтен кошны, сораша башлый. Кошлар да белмиләр тегене.

– Минем суда балыклар бар, – ди карчык, – балыклар белсә, белер, – ди.

Чакыра судагы балыкларны. Сорый балыклардан:

– Шундый-шундый пластинканы беләсезме? – ди.

Бер балык әйтә:

– Мин беләм, – ди, – фәлән җирдә утрауда ул, – ди. – Анда утыра имән. Шуңарга өч тапкыр җылан уралган, – ди, – шунының башында сандык, сандыкта үрдәк, үрдәк эчендә күкәй, күкәй эчендә менә шул үзе уйный торган пластинка инде, – ди.

Ярар. Бу хәзер сикертә дә атны, утрауга чыга. Җәя-ук ясап ала егет. Теге сандыкны атып төшерә. Атып төшергән уңайга сандык ярыла. Үрдәк чыгып оча. Үрдәктән күкәй суга төшеп китә. Тагын булмады моның эше. Суда күкәй юк, табылмый инде.

Тагы бара карчыкка:

– Әби, булмады бит, – ди.

Карчык балыкларны җыя да әйтә:

– Кайсыгыз йотты? Эзләп алып килегез күкәйне, – ди.

Бер балык йоткан булган – косты.

Ярар. Күкәй ярыла. Күкәй эченнән үзе уйный торган пластинка килеп чыга. Алып кайтып китә бу моны хәзер, әбигә бик зур рәхмәтләр укый инде.

Ярар, монысы да булды хәзер. Бу бер көн ял итә дә тагын чыгып китәауга.

Теге сихерче карчык тагы килә бит боларга. Кызга әйтә:

– Абыеңа бар да булды хәзер, – ди, – кәләше дә, сөтегез дә булды, – ди, – үзе уйный торган пластинкагыз да бар, – ди. – Бер җирдә ут гармуны бар, – ди, – менә шуны алып кайтса абыең, – ди, – бик рәхәт торырсыз, – ди.

Ярар. Егетнең хатыны кайта хәзер. Әйтә каенсеңлесенә:

– Карчык килгәнне абыеңа әйтмә, – ди, – ул синең абыеңны үтертергә йөри, сихерче карчык ул, – ди.

– Әйтмәм, – дигән була инде сеңлесе.

Абыйсы кайтып керү белән, каршысына чыга да әйтә бу:

– Абый, – ди, – фәлән әби килгән иде, – ди, – шулай дип әйтте, – ди. – Ут гармуны бар фәлән җирдә, абыең шуны алып кайтса, сезгә инде бүтән бернәрсә дә кирәкмәс дип әйтте, – ди.

Абыйсы әйтә:

– Ярар, барам, – ди.

Хатыны җылый инде:

– Син китсәң, – ди, – аннан кайта алмыйсың, мине аерып кит, – ди.

– Юк, – ди, – аермыйм, – ди, – мин үләргә китмим, кайтырга китәм, – ди.

– Кайта алмыйсың син аннан, – ди, хатыны әйтә. – Үләсең син, – ди, – үтертергә йөртә ул карчык сине, – ди.

Моның хатыны җылап кала. Бу тагын китә атына атланып.

Ярар. Бераздан соң хатыны куып җитә моны.

– Менә сиңа кулъяулык, – ди, – фәлән җиргә барып җиткәч, ут тавы булыр, – ди. – Янар тау, әгәр шуңа менеп җитә алсагыз, анда булыр өч йорт, – ди. – Җизнәй килгән дә, җизнәй килгән дип, үзеңне каршы алырлар, – ди. – Керерсең икенче йортка, – ди, – анда да кызлар булыр, шулай ук, җизнәй килгән дип, каршы чыгып алырлар, кунак итәрләр үзеңне, – ди. – Өченче йортта, – ди, – бер кыз йоклап ятыр, шундый да матур булыр, дөньяда моның кебек кыз булмас, аңа карама, сокланма, – ди. – Икенче бүлмәсенә кер дә, анда булыр ут гармуны, футлярда, – ди, – футлярына тимә, гармунын гына алып чык, – ди. – Ә теге кыз яныннан үткәндә, битенә менә шушы кулъяулыкны сыпырып чык, – ди, – югыйсә сокланырсың син аңарга. Аңа сокландың – эшең бетте, ала алмыйсың гармунны, – ди.

Ярар. Хәзер китә бу, бара, хатын әйткән җиргә барып җиткәч, суга атына бик каты итеп. Ат сикерә. Менеп җитә ут тавына. Атның аягы эләкми янар тауга. Хатыны әйткәнчә бара бу хәзер. Күрә бер йорт, барып керә. Каршы чыга кызлар:

– Әй, җизнәй килгән дә, җизнәй килгән, – диләр. Алып керәләр, ашаталар-эчертәләр моны. Бу чыгып китә алардан

икенчесенә, ашагач-эчкәч инде. Анда кызлар тагын шулай ук. Алып керәләр моны, җизнәй килгән, дип. Алардан да шулай ук, ашап-эчеп чыгып китә инде.

Хәзер өченче йортка китә. Бара. Әй, шундый матур бер кыз йоклап ята караватта – бер бите ай, бер бите кояш, маңгаенда йолдыз. Бу кызның битен сыпыра кулъяулык белән дә кереп китә икенче бүлмәгә. Керә. Гармунны алып футлярын калдыра да чыгып китә борылып. Кыз йоклап кала.

Аты тора хәзер монын яр буенда, теге тау башында. Тиз генә атына менеп атлана да яхшы гына итеп суга. Тауны төшеп җиткәндә генә атның арт аягы эләгеп кала ут тавына. Егет мәтәлчек атып, алга барып төшә, утсыз җиргә. Ат кала янып.

Хәзер бу кайтып китә җәяү, гармуны белән. Бераз кайта торгач, бер карт очрый моңарга:

– Улым, кая бардың? Нәрсә алып кайтасың?

– Менә ут гармунына бардым, шуны алып кайтам, – ди.

– Әйдә алышыйк бу таяк белән, – ди.

– Бу таяк нәрсәгә ярый соң? – ди.

– «Дуй, дубинка» дип суксаң, – ди, – теләсә нәрсәне бәрә дә үтерә, – ди.

– Бир, алайса, – ди.

Гармунны бирә картка. Теге карт әзрәк киткәчтен «дуй, дубинка» дип җиппәрә теге картка. Картны суга да үтерә таяк. Хәзер гармунны барып ала да, таяк та булды, гармун да – кайтып килә бу.

Тагы бер карт очрый моңарга. Култык астына бер палас кыстырган.

– Улым, нәрсә алып кайтасың? – ди.

– Менә, гармун алып кайтам, ут гармуны, – ди.

– Алышыйк, улым, менә бу палас белән, – ди карт.

– Бу палас нәрсәгә ярый соң? – ди егет.

– Моны нинди генә үлекнең өстенә япсаң да, үлек терелә, – ди.

– Ярар, бабай, – ди, – мә алайса, минем ат үлгән иде, – ди.

Шуннан теге карт бераз киткәчтен, «дуй, дубинка» дип ыргыта теге таякны, таяк картны суга да үтерә. Хәзер палас та, гармун да, таяк та булды моның.

Кире китә хәзер егет. Бара аты янган җиргә, теге паласны аты өстенә каплый. Ат сикереп тора. Атлана да кайтып китә бу. Кайтып керә. Моның хәзер бөтен нәрсәсе булды инде. Тагын бер көн ял итә дә ауга чыгып китә бу. Теге картны – малайның әтисен – тугыз бүре куып китерә хәзер.

– Әй, улым, – ди, – коткар шушы бәлаләрдән, – ди.

Тугызын да теге «дуй, дубинка» таягы белән бәреп ала бу хәзер, картны котылдыра.

– Улым, миңа кунакка бар, – ди.

– Син, бабай, мине болай чакырма, – ди. – Минем хатыным бар, сеңлем бар. Без, барсак, өч тройка белән барырбыз. Син вакытын әйтеп чакыр, – ди.

– Менә фәлән числога барырсың, алайса. Мин читтән дә кунаклар чакырам, – ди.

– Менә шулай дип әйт син, – ди.

Кайта егет. Хәзер вакыты җитә моның кунакка барырга. Өч тройка ат җигә бу. Берсенә хатынының ата-аналарын ала, бабалары була инде бу егетнең, аннан сеңлесен, иң артта үзләре була болар.

Барып җитәләр картның йортына. Капка төбендәге йортның почмагына сугып керергә тиеш инде болар. Бу йортта әлеге егетнең анасы тора бит инде.

Теге картлар сукты, сеңлесе сукты почмакка, бу сугарга үрелгән иде – суктырмады моның хатыны.

– Сукма, – ди.

Моны часовойлар кереп әләклиләр бит:

– Менә бүтәннәр сукты, бу сукмады, – дип.

Монда мәҗлес җыелган хәзер. Көтеп утыралар боларны. Мәҗлестә моңа сүз була:

– Нишләп сукмадың да, нишләп сукмадың, нигә буйсынмыйсың син безгә?

– Юк, аңарга сугарга ярамый, – ди, моның хатыны әйтә, теге су кызы, ул белә инде, белемче. – Менә мин сөйлим, – ди, – кем дөрес түгел дип әйтә, шуны үтерергә боерыгыз, – ди.

– Ярар, әйдә сөйлә, – диләр.

– Мин теге төрмә кебек өйдәге хатын турында инде, башыннан аягына хәтле сөйлим, – ди.

Шуннан бу сөйләп китте инде теге кызны ничек атасы урманга китереп ташлаганын.

– Син бу кызга өйләнгәч, – ди, картка әйтә инде, – җыендың хаҗга барырга, – ди. – Олы хатыныңа: «Нәрсә әзерләрсең?» – дип әйттең, – ди. – Ул: «Дөньяда юк күлмәкне әзерләрмен», – дип әйтте, – ди. – Моңа кердең: «Син нәрсә әзерләрсең?» – дип әйттең, ди. Ул: «Бер ир бала, бер кыз бала табармын син кайтуга», – дип әйтте, – ди. – Син киттең хаҗга. Олы хатыныңа, дөньяда юк күлмәкне әзерләп бирде сихерче карчык, – ди. – Шул карчык кече хатыныңа әби булды. Хатының бер ир бала, бер кыз бала китергән иде. Карчык аларны суга агызып җибәрде дә хатының куенына ике эт баласы куйды, – ди. – Менә малаең шушы инде, – ди, – ә кызың менә бу, – ди, – төртеп күрсәтә. Аларны балыкчылар тотып алып үстерделәр, – ди. – Менә бу карчык шулай эшләде аларны, – ди.

– Юк, мин эшләмәдем, дөрес түгел бу, – дигән иде карчык, хатын:

– Чабыгыз шуның башын, дөрес бу, – ди. Аннан соң картка әйтә:

– Синең тугры хатының ул, безнең биәни булырга тиеш, – ди. Шулай итеп, төрмәдән бу хатынны чыгарта, картны яңадан аңа өйләндерәләр. Карт олы хатынны да, теге карчыкны да үтерткәч, болар үзләре кайтып китәләр. Бергә кунакка килешеп, әле дә булса гомер итәләр ие, хәзер беткәннәрдер инде.

*Чуна районы Тәрия авылы.*
*Вәлиев Фатих (50 яшь)*

## Чәчәк күлмәк

Борын заманда була бер патша. Бер баласы да булмый моның.

Бу бер дә бер көнне чыгып китә үзенең шәһәренә йөрергә. Шунда ул ике яшьлек бер баланы күрә, урамда туфрак арасында уйнап йөри торган.

Бу бала, моны күргәч тә, өенә кереп кача. Патша моның артыннан керә. «Бу нинди эш, ди, нишләп минем патшалыкта тәрбиясез балалар булырга тиеш?» – ди.

Керә. Керсә, пич башында утыра бер кортка, үзе патшадан курка, үзе шатыр-шотыр йонын йолка, ди.

– Патша исәнлек-саулык сораша.

– Әби, ди, нишләп ул балаңны азрак тәрбияләмисең? – ди.

– И улым, ди, үзем картайдым, ди, хәзер аның артыннан йөреп булмый инде, – ди.

– Әби, алайса сат миңа, ди, мин үзеңне дә карармын үлгәнче, ди, балаңны тәрбияләрмен, укытырмын, – ди.

Карчык риза була да малайны биреп җибәрә.

Хәзер бу патша карчыкны үз янына ала. Аның үзенә ясата бер йорт. Асраулар куеп, теге карчыкны караттыра инде.

Ярар. Хәзер бу малайны бер чуен подвал ясатып, бер укытучы биреп, унбиш ел укырга куя, беркая чыгармыйча. Малайга Биктимер дигән исем бирә, үлмәсен дип инде, патшаның малае булмый бит.

Теге Биктимер хәзер үсә. Китаптан карап рәсемнәр ясый: яшелчәләр, агачлар, үсемлекләр. Укытучы әйтә:

– Болар барысы да дөньяда бар, дөрес, – ди.

Ярар. Унбиш ел укып чыга бу малай. Ул унҗиде яшьлек егет була хәзер.

– Әти, – ди инде хәзер патшага, – каланы күреп йөрисем килә минем, ди, нинди кала бу безнең, ди. Минем күргәнем юк бит әле, – ди.

Чыннан да күргәне юк, беркая да бармагач.

– Ярый, бар, улым, ди, йөреп кайт, – ди.

– Юк, әти, ди, ат җигеп бирсеннәр дә миңа мин үзем йөрим, – ди.

– Ярар, алайса бар, йөр.

Биреп чыгаралар моңа ат, үзе тотып йөри инде хәзер атны. Шәһәрне бер әйләнеп чыга да китә шәһәр читенә чыгып.

Бара-бара юл белән, кичкә калынды, аты да арыды инде. Моның аты юл буенда үләннәр ашый. «Кара ди, нинди чүп ашый бу ат», – ди, белми инде нәрсә ашаганын да атның.

Ярар, атны хәзер тугарырга кирәк бит инде. Тугара белми. Кесәсендә пычагы була, сбруйны барысын да кискәләп тугара бу. Камытларын, ыңгырчакларын куя бер җиргә дә үзе арбасына менеп ята.

Караңгы төшә хәзер. Моның тәгәрмәченә уралды бер җылан.

Бу теге җыланнан куркып җылады-җылады да тагын ятып йоклады. Бер нәрсә күргән бала түгел бит, егет булса да.

Ярар. Хәзер моның төшенә бер кыз керә. «Менә сиңа бер китап, ди, шуны укырсың, ди, аннан менә шул юл беткәнче бар, ди, болынга килеп чыгарсың. Шул болында минем өем булыр, керерсең минем янга, – ди, кыз өйрәтә тегене.

Уянып китә, чыннан да күкрәгендә китап. Алып укый тегене. Укырга һәвәс инде бу. Тора, ат юк, ат киткән каядыр. Хәзер атта кайгысы юк, арбадан төшеп, китә бу юл белән. Бара-бара сукмакка әйләнә бу юл. Урман арасына кереп китте. Урманны чыкты: болын, шундый су буе – әйбәт. Күрә теге – ике генә өй тора. Барып керә, теге кыз өйрәткәнчә, өйгә.

– Йә, егет, килдеңме? – ди.

– Килдем.

– Ярар, килсәң, ди. Менә ашарга әзерләнгән, ди. Ашыйк-эчик тә ял итик бүген, – ди.

Тегене ашата-эчертә әйбәтләп. Ял итә хәзер теге егет.

– Иртән бабаң янына керерсең, – ди.

Анда бер карт була, кызның атасы буламы инде, белмим анысын. Чабата ясап утыра инде бу. Малай иртән керә:

– Кердеңме, улым?

– Кердем, – ди.

– Ну, әйдә эшкә, мин сиңа эш өйрәтәм, – ди. Чабатасын ыргытып бәрә дә бу, малай белән чыгып китәләр. Көне буе икесенә бер алма төбе өяләр болар.

– Ярар, җитте, улым, ди. Бүген бик каты эшләдек, болай эшләсәк, елына 365 көн, без никадәр алма төбе өябез, ди. Әйдә, улым, ди, бүгенге эш көнеңә хак күрсәтәм, ди, хезмәт көне, – ди.

Зур ат абзарына алып керә тегене: бер җөгән тора, – безнең атларга эшлиягә дә зур ул.

– Менә шушы җөгән булыр сиңа эш хакы, – ди карт. – Бар бүген кереп ял ит инде, теге тутаң янына, ди, иртән тагын керерсең, – ди.

Егет теге кыз янына керә. Ашарга-эчәргә әзерләгән кыз. Бу ашый-эчә дә ял итә инде. Йоклый.

Иртән тагы керә. Карт тагын чабатасын ыргытып бәрә дә:

– Әйдә, улым, чыгып киттек, – ди. Тагы бер алма төбе өяләр болар.

– Җитте, улым, ди, әйдә керик, ди. Бүген тагын эшләгәнеңә хезмәт көне бирәм, – ди.

Ияр күрсәтә бу моңарга. Теге малай селкетә дә алмый иярне, кая анда күтәреп ат сыртына салырга.

– Ярар, улым, ди, хәзер бар кереп ял ит, ди, күтәрә алсаң да, алмасаң да бу синеке булыр, – ди.

Теге малай керә хәзер. Кыз ашарга-эчәргә хәзерләгән. Ашый-эчә, ял итә.

Өченче көнне тора да тагын кереп китә бу карт янына. Карт тукып утырган чабатасын ыргытып бәрә тагын.

– Әйдә, улым, – ди.

Чыгалар болар, бер алма төбе өяләр тагы.

– Әйдә, улым, ди, хезмәт көне күрсәтәм инде бүген эшләгәнеңә, – ди.

Бер абзарны ачып җибәрә – айгыр тора анда. Пошкырып җибәрә – бу малай әллә кая чыгып оча, бер илле метр читкә.

– Булды-булды, бабай, яп, ди. Мин моның янына якын килә алмыйм, – ди.

– Юк, юк, – ди, атка әйтә карт, – син моңа тимә, бу синең хуҗаң булыр алдагы көндә, ди. Кил, улым, хәзер ат тимәс сиңа, – ди.

Килә. Атын сыпыра теге. Буе да җитми аның атка.

– Менә шушы булыр сиңа миннән, ди. Хәзер кайт, ял ит, иртәгә теләсәң нишлә, минем эшем бетте инде, – ди.

Ярар, кайта бу теге кыз янына. Кыз ашата-эчертә моны.

– Инде, егет, әйдә, иртәгә сахрага чыгабыз синең белән, ди. Хәзер эшең бетте синең, – ди.

Йоклыйлар болар. Иртән торып, ат җиктерә теге малайдан, икенче атны инде. Икесе утыралар да чыгып китәләр. Мылтык та алдыра бу малайдан.

– Син, ди, үрдәк атып йөрерсең, ди, мин чәчәк җыярмын, – ди.

Чыгып китәләр, барып җитәләр су буена. Чәчәк болыны шундый матур, әйбәт.

Бу малай йөри хәзер мылтык тотып. Бер-ике үрдәк атып алды инде. Ә кыз чәчәк җыйган да моңарга шул чәчәктән бәйләгән ыштан, күлмәк, пута, биленә буарга.

– Менә бу ыштанны киеп карале, – ди, кыз әйтә. Малай ыштанны киеп карый.

– Ничек хис итәсең үзеңне? – ди кыз.

– Мин, ди, тоткасы булса, шушы диңгезне күтәреп алыр идем хәзер, – ди.

Шундый көч кергән шикелле булды инде.

– Инде менә бу күлмәкне киеп җибәр, – ди. Күлмәген киеп җибәрә.

– Хәзер ничек хис итәсең үзеңне?

– Менә җир белән күкнең тоткасы булса, ди, икесен бергә ябыштырыр идем, – ди.

– Менә бу путаны буып кара хәзер, – ди. Путаны буа.

– Хәзер, ди, бөтен дөньяны учка сыйдырып бетерер идем, ди. Шундый көч керде хәзер, – ди.

– Путаң артыграк булыр, – ди кыз. – Монысын кесәңә тык, ди. Кайчан көчең җитми, шул вакыт буарсың, – ди.

Кайтып керәләр болар. Малайны кич кундыра. Иртән әйтә кыз:

– Менә миннән сиңа бүләк шушылар булыр, ди. Бу әйберләр турында син гомерең буена хатын-кызга сөйләмә, ди. Өйләнерсең, ди, хатының белән мунча кермә, ди, бу чәчәк күлмәкләрең турында аңа да сөйләмә, ди. Әгәр дә хатыныңа сөйләп тегеләй-болай уңайсыз хәлгә төшсәң, ди, бу нәрсәләр яңадан булмас, – ди.

Ярар. Малай теге карт белән чыга хәзер. Карт җөгәнне бирә. Бу малай атны җөгәнли, иярли, менеп атлана, өч тапкыр ишегалдын урый да чыгып чаба ат белән.

Бу хәзер кая барганын да белми, бер юлга төшә дә сыпыра шуның белән. Барып җитә бер шәһәргә. Бу шәһәрдә кара флаг асылган була.

Шәһәр башында бер карчыкка керә бу квартир сорап. Карчык берүзе генә тора.

– Кер, улым, ди, өем иркен, мин берүзем генә, – ди. Ярар. Теге малай керә, атын җибәрә. Аты аңа бер йөзек бирә. Малай шул йөзек белән генә сызгыра – ат килеп җитә кирәк вакытта.

Ярар. Керә, ял итә.

– Әби, ди, ашарга пешерсәң иде син, – ди.

– Әй, улым, ди, ашарга бик пешерер идем дә, ди, бездә, ди, җиде башлы аждаһа ята суда, ди, беркемгә дә су бирми, ди, төнлә бер чиләк бирә, ди, артыгын бирми, – ди.

– Кайда тора соң ул, әби? Бир әле чиләкләреңне, мин барып килим суга, – ди.

Ике чиләк ала да бу бара суга. Теге аждаһа чыга инде.

– Нишләп ике чиләк тотып килдең? – ди.

– Мин, ди, кунак, читтән килгән кеше, ди, эчәсем килә, ашыйсым килә минем, ач мин, – ди.

– Ярый, кунак булсаң, ал ике чиләк.

Ике чиләк су апкайта. Бу әби хәзер бер чиләген шунда ук эчеп бетерә, бер чиләк суы кала моның.

Ярар. Бу малайны ашата-эчертә инде хәзер.

– Әби, нишләп, ди, кара флаг асылынган сездә? – ди.

– Асылынмыйча, ди, ул аждаһа чиратлап кеше ашый, ди. Ансыз бер грамм да су бирми ул, ди. Бүген патша кызына чират, шуңа кара флаг асылынган, кайгылы көне патшаның, – ди.

Ярар. Бу малай кич белән китә аждаһа янына. Үзе белән кылычын ала. Бара. Су буенда махсус бер йорт бар. Шунда китереп куялар кешене, шуннан гына ашый инде аждаһа, судан чыгып. Шул өйдә патша кызы җылап утыра.

– Ник җылыйсың, кызый? – ди бу малай.

– Җыламыйча, ди, бүген азаккы көннәрем, азаккы минутларым. Аждаһа йота мине. Бар, егет, ди, каян килдең, шунда кит, югыйсә икебезне дә йота ул, – ди.

– Ярый, йотмас әле, ди. Мин юлдан арып килгән кеше, әзрәк йоклап алыйм, – ди.

– Йоклап китсәң, мин сине ничек уятырмын соң? – ди.

– Менә сиңа без бирәм, ди, әгәр дә, аждаһа-фәлән килеп чыкса, уята алмасаң, төртерсең шуның белән тәнемә, – ди.

Ярар. Хәзер бу йоклап китте. Күпме-әзме гомер үтмәде – аждаһа чыгып җитте дә ишекне ачты.

– Патша, ди, берне сорап, икене җибәргән, – ди.

Кыз җылый инде хәзер. Теге без белән төртергә жәлли егеткә.

Ярар, күп вакыт үтмәде – кызның кайнар яше тама тегенең битенә – малай уяна бит.

– Фу, ди, соңга калганмын, ди, нишләп иртәрәк уятмадың? – ди.

Аждаһа тагын:

– Патша, берне сорап, икене җибәргән миңа йотарга, – ди.

Малай әйтә:

– Берсе белән дә тыгылырсың, берсе дә үтә алмас әле, – ди.

Шулай дигәч, йотып җибәрим дигән иде аждаһа, егет кылычын тотты да, тегенең авызына кереп, урталай ярып ук чыкты. Аждаһа селкенгән иде – урталай ярылды.

Ярар. Хәзер бу аждаһаның башларын чапкалый да таш астына кыстырып куя инде, зур таш астына.

Кыз әйтә:

– Әйдә безгә, ди, әти сине бүләкләр, – ди.

– Юк, мин бармыйм, ди, мин читтән килгән, юлаучы, кереп тормыйм, – ди.

– Алайса, менә минем төсем итеп тотарсың, – ди, кулъяулыгын бирә патша кызы.

Кулъяулыгын алып кесәсенә тыга да кайтып китә инде бу хәзер теге әбигә. Ике чиләк су апкайта кайтышлый. Әби суга туйды хәзер.

– Бар, әби, барып ал су, аждаһа бетте, – ди.

– Юк, улым, алар чиратлашып чыгалар, ди. Бүген җиде башлысы иде, ди, хәзер аның тугыз башлысы чыга, ди. Бүген патшаның икенче кызына чират, ди. Өч кызын да ашый хәзер, өч аждаһа, – ди.

Егет көне буе йоклый да кич белән тагын китә су буена. Бара. Кыз елап утыра инде. Кыз белән утыралар сөйләшеп. Ярты төннәрдә теге аждаһа чыга. Килә.

– Фу, ди, патша, берне сорап, икене җибәргән, – ди.

– Ярар-ярар, ди, берсе дә тамагыңа утырыр синең, – ди.

– Алыш бармы, ди, көрәш бармы, – ди, аждаһа әйтә, – давай көрәшәбез алайса, бик көчле булсаң, – ди.

– Давай, – ди теге егет. – Була көрәшергә, – ди.

Болар тотыналар көрәшергә. Аждаһаны җиңә теге малай. Үтерә. Тугыз башын да чаба да таш астына кыстырып куя. Гәүдәсен тураклап суга ыргыта.

Ярар. Кыз хәзер ялына инде:

– Әйдә, ди, безгә кайтыйк, ди, әти сине бүләкләр, – ди.

Егет әйтә:

– Юк, мин барып йөрмим, мосафир кеше мин, юл кешесе, ди, кайтып ял итәргә кирәк, – ди.

– Алайса, ярар, кайтмасаң. Менә минем исемле балдагым бар, шуны бүләк итәм сиңа, – ди.

Егет балдакны кесәсенә алып тыга да, ике чиләк суны алып, әбигә юнәлә.

Бу хәзер кайтарып әбигә ике чиләк суны бирә. Әби сөенә инде, суга туйды. Ашарга-эчәргә әйбәтләп әзерли. Малайны аша-

та, егет ятып ял итә көне буена, бүген инде азаккысына барырмын, ниһаять, дип.

Кич белән тора, ашый-эчә дә китә тагын кыз янына. Хәзер инде монда патшаның кече кызы елап утыра.

– Менә хәзер, ди, унике башлы аждаһа мине ашарга тиеш, – ди.

Бу кыз белән утыралар сөйләшеп, аждаһа килеп җитә ярты төннәрдә.

– Фу, патша, ди, берне сорап, икене җибәргән, – ди.

– Берсе дә тамагыңа утырыр, – ди.

– Йә, әйдә сугышабыз.

Тотыналар сугышырга. Бу егет тәмам арыгач, башларын чабып өзә башлый. Унбер башын чаба, берсе калгач, аждаһа ялына хәзер:

– Калдыр мине, зинһар, ди, мин сиңа тимәм, ди, сиңа тегеләйболай сүз салмам, ди, хәзер кая куйсаң, шунда куярсың, ди. Нишләтсәң эшләтерсең, тик бер башымны калдыр, – ди.

Бу жәлли инде, бер башын калдыра. Аждаһаны патшага алып бара. Чуен подвал ясатып, шул подвалга ябып куялар моны.

Патша кече кызына өйләндерә малайны, Чәчәк күлмәкне. Туй ясый. Туенда мин дә булдым, иләкләп тә чиләкләп эчтек.

Болар тора башлыйлар хәзер кыз белән. Яхшы гына гомер итәләр.

Бер дә бер көнне кыз теге подвалны карыйсы итә бит. Караса, теге аждаһа шундый да матур егеткә әйләнгән. Аның кебек егет дөньяда юк, шундый матур. Теге кызның күзе кызыга бит моңарга.

– Эх, син, шуның белән торасыңмы? – ди, аждаһа әйтә. – Аның чәчәк күлмәк белән чәчәк ыштаны гына бар, ди, шуның белән генә көчле булып йөри ул, ди. Аның болай һич тә көче юк, ди. Менә син миңа барсаң, ди, минем үземнең көчем ичмаса, – ди.

– Ә ничек барырга соң сиңа? – ди, кыз әйтә. – Ничек аны үтерергә, аны җиңеп булмый бит, – ди.

– Чәчәк күлмәген ал син аның, – ди.

– Аны ничек алырга? – ди, кыз әйтә. Аждаһа аңа:

– Мунча кергәне юк бит аның синең белән, – ди.

Юк, – ди.

– Менә яктыр мунча, ди, барыгыз мунчага, ди, үпкәләгән бул, ди, мине яратмыйсың, тегеләй-болай, минем белән мунча кермисең, әллә кемнәр белән кереп йөрисеңдер син мунча, дип, үпкәләгән бул, – ди.

Кыз кайта да мунча яктыра. Ире эштән кайта инде, теге егет.

– Бүген мунча яктым мин, мунча керербез, – ди.

– Юк, ди, мин гомеремдә дә мунча кергәнем юк, – ди.

– Нишләп, ди, мунча кермичә кеше торамыни, ди, син икенчеләрне тапкан булырсың, ди. Шулар белән кереп йөрисеңдер мунча, ди, мине яратмыйсың син, ди, минем белән кермисең шуңа күрә, – ди.

– Юк, ди, мин кермим, – ди.

Хатыны тагын үпкәләгән була инде. Шулай итә торгач, егет риза була. Баралар мунчага. Бу хәзер күлмәкләрен салды, чәчәк күлмәген салмый.

– Сал моны да, нигә салмыйсың моны? – ди хатыны.

– Юк, ди, моны салырга ярамый, – ди.

– Алайса, мин тотып торыйм өй алдында, ди, син сал, кер, юынып чык, ди, аннан мин кереп чыгармын мунча, – ди.

Салып бирә хатынына чәчәк күлмәген, ыштанын, үзе керә юынырга. Теге кереп киткәч тә, хатыны күлмәкне илтә дә бирә аждаһага подвал тәрәзәсеннән генә. Аждаһа – юха егет киеп ала күлмәк-ыштанны да бер генә селкенә – подвалны ватып та чыга. Тагын да көчләнә бу.

Ярар. Хәзер инде аждаһа моның янына мунчага килде, ишеккә башын салды:

– Менә хәзер мин сине тотам, ди, теге вакытны булмаган иде, ди. Хәзер мин сине ашыйм, ди, азаккы минутларың. Синең чәчәк күлмәкләрең миндә инде, – ди.

Теге егет нәрсә эшләсен инде, бу көенә бернәрсә дә эшли алмый инде.

– Ярар, ди, ашасаң ашарсың, ди, хәзер юынып бетәм инде мин, – ди.

Егет чыга мунчадан. Аждаһага әйтә:

– Минем йөзегем бар кесәмдә, ди, шуны сызгыртыгыз, ди, минем айгырым килер, ди. Айгырның ияр астында сумка бар, ди, шул сумкага сөякләремне салырсың, – ди.

Ярар. Аждаһа егетне ашый, сөяген ашарга кушмады инде, сөяген ашамады. Йөзеген алып сызгыртуга айгыр килеп тә җитә. Бу айгырны тотарга карый – айгыр тоттырмый тегеңәрдән, башын бирми. Аждаһа атның ияр астындагы сумкага егетнең сөякләрен сала да айгыр шунда ук чыгып та чаба.

Хәзер тегеләр икесе тора башлыйлар инде юха егет белән бу хатын. Айгыр кешнәп-җылап кайтып керә теге йортка, чыгып киткән иде бит әле кызлардан, шунда кайтып керә хәзер бу.

– Эх, ди, нәрсә булса да булды егеткә, – ди кыз, йөгереп чыга.

Кыз егетнең сөякләрен тезеп сала. Белгәннәрен укый торгачтын, егетне кире терелтә бу.

– Фу, ди, озак йоклаганмын, – ди егет.

– Йоклагансың менә, – ди, теге кыз әйтә, – мин сиңа әйттем бит, ди, хатының белән мунча кермә, хатыныңа сөйләмә, нәрсә булса да эшләтерләр үзеңне дип, ди. Менә үтергәннәр үзеңне, ди. Хәзер көч юк инде синдә, ди. Хәзер мин сиңа бүтән нәрсәкәй бирә алам. Менә сиңа өч чәчәк бирәм, – ди.

Ак, кызыл, яшел чәчәк бирә инде тегеңәргә.

– Кайтканда очрар җыланнар, ди, яшел җылан очрар, ди, менә бу яшел чәчәкне кабып чык, ди. Аннан кызыл җыланнар килерләр сиңа уралырга, ди. Кызыл чәчәкне капсаң, алар сиңа тимәс, ди. Ак җыланнар чыкса, ак чәчәк кабарсың, ди. Айгыр юк хәзер сиңа, ди, айгырны тота алмыйсың син хәзер, ди, көчең юк синең, – ди.

Ярар. Егет чәчәкне ала да кайтып китә. Чыннан да, юлда яшел җыланнар очрый моңа. Киләләр инде моны ашарга дип. Бу теге яшел чәчәкне каба авызына да яшел җылан патшасы булып чыгып китә араларыннан.

Кайта-кайта, хәзер кызыл җыланнар киләләр моны йотарга. Бу теге кызыл чәчәкне каба да кызыл җылан патшасы булып чыгып китә араларыннан.

Хәзер кайта-кайта, ак җыланнар очрый инде моңа. Бик күпләр, йотарга киләләр. Бу ак чәчәкне каба да чыгып китә ак җылан патшасы булып.

Ярар, тагын китә бу юл белән. Бара-бара, барып керә бер шәһәргә. Бер карттан квартир сорап, квартирга керә. Моңа теге кыз әйткән иде: «Шул чәчәкләрне авызыңа капсаң, нәрсә буласың килсә, шул булырсың», – дип. Хәзер бу картка әйтә:

– Бабай, ди, бар, син кибеттәнме, базарданмы, апкайт бер яхшы гына җөгән, ди, мин яхшы айгырга әйләнерем, ди. Мине сатарсың, ди, патша алыр инде, бүтән кеше ала алмас, ди, бүтән кешенең көче җитмәс, бик кыйбатлы айгыр булырмын мин, – ди.

Карт базарга чыга да яхшы гына җөгән алып кайта.

– Бабай, ди, сатканда син җөгәнне кулыңнан җибәрмә, җөгән үзем булырмын, ди. Күпме акча бирсәләр дә, җөгәнне бирмә, – ди.

Бу хәзер айгыр булды. Алтын яллы, көмеш койрыклы шундый матур айгыр инде, кәртинкә кебек. Карт базарга апчыгып китә тегене. Бара. Байлар да кызыгалар, акчалары җитми. Бик кыйбат сорый бу – илле мең тәңкә.

Юха килә хатыны белән, кызыгалар моңарга. Хатыны инде бигрәк тә кызыга.

– Шундый да матур, ди, нәрсә тора, ди, бер утырып йөрсәң дә, – ди.

Алалар илле меңгә. Карт әйтә:

– Мин җөгәнне сатмыйм, минем үземнең шундый ук айгырым бар, бер генә җөгән минем икесенә, ди, җөгәнне күпме сорасаң да бирмим, – ди.

Ә теге юха җөгәне белән аласы килә: ул белә кем икәнен моның, айгырның. Ә хатын әйтә:

– Кирәкмәс җөгән белән, ди, без табарбыз әле, әллә кайлардан ясатып алырбыз заказ белән, – ди.

– Юк, – ди, юха әйтә, – мин алам җөгәне белән, ди. Күпме сорыйсың, бабай, ди, менә бер капчык акча бирәм мин сиңа, – ди.

Бабай кызыга бер капчык акчага да җөгәнне дә биреп җибәрә тегеңә.

Ярар. Болар хәзер кайтып китәләр. Айгырны да бәйләп куялар. Керәләр өйгә.

– Менә син шулай дип әйтәсең, – ди, хатынына теге юха әйтә, – бу бит теге Чәчәк күлмәк егет, ди. Бу безнең башка җитәргә йөри. Моны үтерергә кирәк, – ди.

– Ничек үтерергә соң моны?

– Ничек кенә булса да, ул егетне юк итәргә кирәк, – ди. Боларның була бер хезмәтче кызлары. Шул кыз күрә дә:

– Эх, ди, Чәчәк күлмәк, сине бит әрәм итәләр хәзер, – ди, айгырга барып сөйли инде теге кыз.

– Мине жәлләсәң, – ди, айгыр әйтә, – тешемне төшергәндә, ди, бер тешемне ничек булса да эләктереп ал да өй артына күмеп куй, тәрәзә турына, – ди.

Ярар. Шуннан ары соң тегенең тешләрен хәзер сугып коялар. Кыз моның бер тешен эләктерә дә, шунда булышкан булып йөреп, күмеп куя өй артына. Хәзер юха моның гәүдәсен яндырта.

Иртән торуларына теге күмелгән теш матур чәчәк булып үсеп утыра өй артында.

– Эх, карт, ди, кара әле, без теге егетне бетергәч, безнең икәү кавышулыкка шундый да матур чәчәк үскән бит, өй артына, – ди, хатын әйтә.

– Әй, бу, ди, теге Чәчәк күлмәк, ди. Аның нәрсәседер төшеп калган булган, шуннан чәчәк үсеп чыккан, ди. Аны хәзер тамыры белән төпләп алып керергә дә пичкә ыргытырга, яндырырга кирәк, – ди.

Теге кыз чыга тагы тегенең янына.

– Эх, ди. Чәчәк күлмәк, тагын бетерәләр сине, – ди.

– Әгәр мине жәлләсәң, ди, бер яфрагымны ал да суга ташла, – ди тегеңә.

Алардан ерак түгел генә зур су була. Кыз ала да бер яфракны суга ыргыта.

Юха чыга, чәчәкне төпләп ала да пичкә ыргыта. Бетте хәзер бу.

– Ах, карчык, ди, чәчәкне казып алганда пычрандым, ди, су кереп алырга кирәк, – ди.

Ярар. Бу китә су буена, теге Чәчәк күлмәк егетнең кылычын кадап куя, чәчәк күлмәк-ыштаннарын салып куя да су керергә төшә инде хәзер.

Төште бу суга. Теге кыз ташлаган яфрак хәзер әйләнде үрдәккә, канаты сынган үрдәк булып, суда йөзеп йөри.

Юха күрә:

– Әһә, ди, теге Чәчәк күлмәк һаман калган икән, ди, тукта, мин тотып үтерим әле аны, – ди.

Юха тота алмый. Ул кергән саен, үрдәк суның уртасынарак китә. Шуннан теге үрдәк очып чыга да кылычка бәреләә – кеше була. Чәчәк күлмәк белән чәчәк ыштанны кия, кылычны эләктереп ала да:

– Йә, хәзер чык монда, – ди.

Теге чыкмый. Чыкмагач, суда көенә чабып өзә башын юханың.

Хатыны моның чардактан карап тора икән. Егет юханы бетергәч, куркудан ике катлы чардактан үзен үзе ыргытып башын бетерә.

Тегеләр беткәч, бу керә дә хезмәтче кызны ала үзенә җәмәгатькә, чәчәк күлмәкне киеп, батыр патша булып, әле дә булса гомер итәләр, ди.

*Чуна районы Тәрия авылы.*
*Вәлиев Фатих (1921 елгы)*

## Ялкау карчык

Карт белән карчык торган. Карчыгы бик ялкау булган. Моңа карты җеп эрләргә куша.

Бик эшлекле кыяфәт белән һәркөн карты эшкә киткәндә җеп эрләп кала ул. Ире китүгә, йокларга ята. Ире кайтуга, тагы кабасы янына утыра. Шулай итеп, ул ел буена бер орчык җеп эрләгән. Подаукага йомгакка охшаган әйберләр тутыра барган.

Хәзер бердән бер көнне җепне кайнатырга җыеналар. Карчык картына әйтә:

– Мин җепне кайнатырга салам, син морҗа турыннан кошларны очырма, бүл. Әгәр дә бер генә кош очсын, җепләребез мунчалага әйләнер, – дигән.

Карт өй түбәсенә менеп китә. Очып барган кошларны ничек туктатсын, ди инде ул. Карты кычкыра:

– Карчык, бер дә тота алмыйм, – дип.

Ә карчыгы казанга мунчала тутыра, аны болгата-болгата:

– Мунчалага әйләндереп бетерәсең бит инде, – дип кычкыра.

Шулай итеп, карчык ялкаулыгын яшереп калган, ди.

*Нокыт районы Хареты авылы.*
*Фролова Елена (43 яшь)*

## Теге дөнья кунагы

Карт белән карчык булган, аларның бер малайлары булган. Малай үлгән. Карт базарга киткәч, килеп керә бер солдат. Әбидән ашарга сорый. Әби:

– Ашарга юк безнең, – ди. Аннан сорый:

– Син улым каян килдең? – ди.

– Мин теге дөньядан, – ди солдат.

– И улым, безнең малай да шунда бит, күрмәдеңме? – ди.

Солдат әйтә:

– Без аның белән бергә көтү көтәбез, – ди.

Әби хәзер солдатка ашарга әзерли. Ашата-эчертә.

– Улым, синең артыңнан күчтәнәч җибәрер идем, – ди.

– Алып барырмын, нигә алып бармаска, тульке тизрәк, – ди.

Әби күчтәнәч әзерләп бирә.

– И улым, мин акча да җибәрер идем, – ди.

– Ярый-ярый, тульке тизрәк, – ди, сизә ул картның кайтып керерен.

Солдат әйберләрен ала да китә чыгып, шәп-шәп атлап. Хәзер карт кайтып керә. Карчык сөйли инде:

– Менә, карт, безгә теге дөньядан бер кеше килде бит әле, – ди.

– Соң, килеп ни булды?

– Ул теге дөньяда безнең малай белән көтү көтә икән, – ди. – Күчтәнәчләр дә җибәрдем әле, – ди.

Карт сукрана.

– Ахмак карчык, – ди, берне чыбыркы белән сыдырып ала. – Кая таба китте ул? – ди.

Карт атны туарып алып атлана да алдакчы артыннан чаба. Солдатны куып җиткәч кенә чыбыркысы төшеп кала. Ул алдакчы кешенең солдат икәнен белми бит инде, сикереп төшә дә аттан:

– Мә, атны тотып тор әле, – ди.

Карт чыбыркысын алган арада, солдат тиз генә атланып ала да чаба. Карт нишләсен хәзер, йөгереп тә карый, куып җитә алмый.

Хәзер кайта инде өенә.

– Йә, ничек? – ди карчык.

– Ул, карчык, чыннан да теге дөньядан килгән икән, – ди, – мин атны да биреп җибәрдем әле, – ди.

– Менә! Ә син сукранган буласың, – ди карчык.

*Чуна районы Тәрия авылы.*
*Сәлимҗанова Бибигайшә (57 яшь)*

## Тиле Таз

Элек бар иде, ди, бер әби. Аның өч улы булган. Берсе булган тиле Таз. Болар аерылышканнар. Аерылгачтын, әби калган тиле Таз белән.

Шуннан әби моны базарга җибәргән.

– Ит ал, май ал, – дигән, – кашык, тоз.

Тиле Таз барган, алган.

Алып кайтып бара икән бу, урманда бер төп күреп:

– Бабай, яраларың күп икән, – дигән.

Аңа маен сылап киткән.

Шуннан моңа бер су очрый. Таз суны эчеп караган да:

– Тозың юк икән, – дип, тозын салып киткән.

Кайтып барганда кашыклар шалтырый.

– Сугышып кайтасыз, – дип, кашыкларны ташлаган.

Хәзер юлда моңар бер эт өрә.

– Аша менә, – дип, итен биреп киткән эткә.

Кайтып җиткән. Әбигә сөйләгән. Сатып алган әйберләрнең берсе дә юк. Шуннан әби салмалы аш пешергән дә тиле Тазны урманга алып киткән.

Барганнар урманга. Әлеге төп утыра. Тиле Таз сорый:

– Бир минем майны, – ди.

Теге дәшми. Бу тибеп җибәргән икән – төп астыннан чүлмәк белән акча килеп чыккан.

Инде кайтып барганда эткә килеп җиткәннәр.

– Бир минем итне, – ди тиле Таз эткә.

Эт һаман кабалый моны. Бу тәпрәне алган да куып киткән этне. Эт чыдый алмыйча мунчага барып кергән. Мунчаның багана төбеннән казый икән бу – акча килеп чыккан чүлмәк белән.

Шуннан әби үзе алып барган салмалы ашны чәчә башлаган.

– Әни, әни, карәле, тишекле яңгыр ява, – ди Таз.

– Аша, балам, аша, – ди әби.

Кайтканнар болар. Акча алып кайттылар инде. Моның агалары тиле Тазны чакыралар.

– Сез ничек баедыгыз? – диләр.

– Әнә, тишекле яңгыр яуды бит, шул чагында чабып кайттык та шуннан баедык, – дип әйткән, ди, бу.

Шуннан: «Тишекле яңгыр буламы соң инде?» – дип, аптырап калган агалары, белмәгәннәр.

*Нокыт районы Хареты авылы.*
*Антипова Елизавета (78 яшь)*

## Урман буры

Яшь вакытта этәй белән урманга барып, усак кисеп, чанага салып торадыр идек, килеп чыкты урман хуҗасы.

Инде нишләргә? Безгә хәзер хәл чамасы юк качарга да. Бары мөмкин булды атыбызга утырып чабарга гына авылга. Тотындык этәй белән чабарга, һичкем күрсен, бураннар гына уйнап тора безнең арттан.

Урман хуҗасы безнең арттан чаба, ну аты бик начар булгачтын, безнең арттан җиталмый.

Кайтабыз да усакны яшереп базга ыргытабыз. Урман хуҗасы килеп, безне тикшереп карый да табалмый кире кайтып китә.

Бик күп вакытлар үтә, онытабыз теге агачны, усакны. Бу тегендә тамыр җәеп үсәргә керешә. Үсә-үсә тишеп чыга сайгакны, өйдә үсеп утыра, түшәмне тишеп чыга, аннары түбәне дә тишеп чыга.

Моны нишләтәбез инде хәзер? Мин карап торам-торам бу усакка: «Туктале, мәйтәм, менеп карыйм әле, моның очы ерак микән?». Карасам – ул һаваны да тишеп чыгып киткән. Менсәм – анда бер чебенгә бер сыер бирәләр. Мин сөенечтән бик тиз генә төшеп, бер чирекле шешәгә тутырып, чебеннәр алып менәм дә һәрбер чебенгә бер сыер алышып алам. Чебеннәрне алышып беткәннән соң, яллыйм бер ун-унбиш көтүче, бу сыерларны куып төшерергә усак буенча.

Килсәм, усакны екканнар, калдым бит мин һавада. Хәзер нишләргә? Әйтәм көтүчеләргә:

– Суеп тунагыз да, ите үзегезгә булыр, тиресе – миңа.

Бу сыерларның һич санын да, хисабын да белмим. Надан чак, минем мөмкинлек юк санына чыгарга, һәр чебенгә сыер алгач...

Сыерларны суйдырып тунатам да, тиреләрен машинага илтеп ярдырам да, берсенә берсен ялгап, бер башын бәйләп, җибәрәм җиргә төшереп. Аннары шул каеш буйлап тотынып төшеп китәм. Очына төшеп җиттем: каеш җиргә җитмәгән.

Ерак түгел бер карт тары җилгәрә, җил миңа кибәкне очырып тора, мин шуларны тотып аркан ишә башладым. Бер-ике метр иштем дә: «Туктале, беркадәр төшкәч, күбрәк тә ишәрмен»,– дип тотынганыем – өзелде китте минем кибәк арканым. Килеп төштем дә тездән хәтле баттым,– сазлык урынга туры килгәнмен. Шунда килде дә бер бүдәнә башыма күкәй салып китте.

Хәзер нишләргә? Килә бер бүре. «Йа Хода, мәйтәм, бу бүре белән мин нишләрмен инде. Мине ашый бит хәзер», һич кузгала алмыйм. Бу бүре килә дә, бүдәнә күкәен кабып йота да борылып китеп бара. Койрыгын эләктереп, «һайт» дип кычкырган идем,

мин дә чыктым, бүре дә тиресеннән чыгып, торды да чапты. Тары иләгән карт та, теге бүредән куркып, торды да йөгерде өенә таба. Мин артыннан йөгерәм, ул миннән куркып йөгерә. Ул миннән курыкмый икән – бүредән.

Шул көе мин, кайтып, өйгә керәм.

Шуның белән әкият тәмам.

*Чуна районы Тәрия авылы.*
*Гыйлаҗетдинов Фәтхетдин (63 яшь)*

## Авторлар турында кыскача белешмә

**Хисамов Олег Ришат улы,** филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фән эшләре буенча директор урынбасары. ohisamov@mail.ru

**Бобкова Галия Ивановна** (1950 – 2011), журналист, җәмәгать эшлеклесе, галим

**Габдерәшит Ибраһимов** (1857–1944), татар сәясәтчесе, дин әһеле

**Герасимова Наталья Владимировна,** сәнгать фәннәре кандидаты,ТР ФА Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре. natal-040183@mail.ru

**Гомәров Илһам Госман улы,** филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире. ilham05@bk.ru

**Закирова Илсөяр Гамил кызы,** филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре. ilzakirova@mail.ru

**Макогон Бибигайшә Кәлимулла кызы (Галина Николаевна),** Залари районы туган якны өйрәнү музее директоры, Иркутск өлкәсенең Залари поселогы

**Нургаянова Найлә Хәбибулла кызы,** педагогика фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һә музыка бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре. naila-n@mail.ru

**Рәхимова Асия Ризван кызы,** филология фәннәре кандидаты, тәрҗемәче

**Хөсәинова Алинә Җәмил кызы,** филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре husainova_alina@mail.ru

## ЭЧТӘЛЕК • СОДЕРЖАНИЕ


КЕРЕШ • ВВЕДЕНИЕ
6

СҮЗ БАШЫ • ПРЕДИСЛОВИЕ
20

ИРКУТСК ТАТАРЛАРЫ ТАРИХЫ
(2018 ЕЛГЫ ЭКСПЕДИЦИЯ МАТЕРИАЛЛАРЫ НИГЕЗЕНДӘ)
*Олег Хисамов, Илсөяр Закирова*
*28*

ВОЗНИКНОВЕНИЕ И РАЗВИТИЕ ЭТНИЧЕСКИ
ОДНОРОДНЫХ ТАТАРСКИХ ПОСЕЛЕНИЙ
НА ТЕРРИТОРИИ ИРКУТСКОЙ ГУБЕРНИИ
В КОНЦЕ XIX – НАЧАЛЕ XX В.
*Галия Бобкова*
*49*

О ХРОНОЛОГИЧЕСКОМ И ФАМИЛЬНОМ СОСТАВЕ ТАТАР-
СКОГО НАСЕЛЕНИЯ В ЗАЛАРИНСКОМ РАЙОНЕ
ИРКУТСКОЙ ОБЛАСТИ
*Бибигайша Макогон*
*88*

ГАЛӘМ-Е ИСЛАМ
*Габдерәшит Ибраһимов*
*(Сүз башы авторы А. Рәхимова)*
*120*

МЕЦЕНАТ ШӘЙХУЛЛА ШӘФИГУЛЛИННЫҢ
ИРКУТСК ТАТАРЛАРЫ ТОРМЫШЫНДА ТОТКАН УРЫНЫ
*Олег Хисамов, Илһам Гомәров, Илсөяр Закирова*
*136*

ФОНЕТИЧЕСКИЕ И ЛЕКСИЧЕСКИЕ ОСОБЕННОСТИ
ТАТАРСКИХ ПЕРЕСЕЛЕНЧЕСКИХ ГОВОРОВ
ИРКУТСКОЙ ОБЛАСТИ
*Алина Хусаинова*
*149*

ИРКУТСК ӨЛКӘСЕ ТАТАР ФОЛЬКЛОРЫ (ИНСТИТУТНЫҢ
2018 ЕЛДА ИРКУТСК ӨЛКӘСЕНДӘ УЗГАН ЭКСПЕДЕЦИЯСЕ
МАТЕРИАЛЛАРЫ НИГЕЗЕНДӘ)
*Илсөяр Закирова*
*196*

МУЗЫКАЛЬНЫЕ ТРАДИЦИИ КАК ФОРМА СОХРАНЕНИЯ
ЭТНОКУЛЬТУРНОЙ ИДЕНТИЧНОСТИ ТАТАР
ИРКУТСКОЙ ОБЛАСТИ В УСЛОВИЯХ
ПОЛИЭТНИЧЕСКОГО ПРОСТРАНСТВА
*Неля Нургаянова*
*229*

МАТЕРИАЛЬНАЯ КУЛЬТУРА,
ДЕКОРАТИВНО-ПРИКЛАДНОЕ ИСКУССТВО И РЕМЕСЛА
ТАТАР ИРКУТСКОЙ ОБЛАСТИ
*Наталья Герасимова*
*309*

ИНСТИТУТНЫҢ 1971 ЕЛГЫ ФОЛЬКЛОР ЭКСПЕДИЦИЯСЕ
ВАКЫТЫНДА ТУПЛАНГАН ХАЛЫК ИҖАТЫ ҮРНӘКЛӘРЕ
332

Научно-популярное издание
*Серия «Из сокровищницы научных экспедиций»*

Двадцать первая книга

**Национально-культурное наследие**
**ТАТАРЫ ИРКУТСКОЙ ОБЛАСТИ**

Фәнни-популяр басма
*«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе*

Егерме беренче китап

**Милли-мәдәни мирасыбыз**

**ИРКУТСК ӨЛКӘСЕ ТАТАРЛАРЫ**

Редакторлар: *Л. Г. Шәрифуллина, Д. Р. Галиуллина*
Компьютерда биткә салучы *Д. Р. Галиуллина*

Китапта *О.Р. Хисамов, И.Г. Закирова, Н.В. Герасимова, И. Г. Гомәров*
фоторәсемнәре файдаланылды

Басарга кул куелды 12.12.2021
Форматы 60×84 $^1/_{16}$. Офсет кәгазе. Times New Roman гарнитурасы.
Офсет басма. Нәшер-хисап табагы 15,6. Шартлы басма табагы 22,6.
Тиражы _____ д. Заказ

Оригинал-макет
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнде
420111, Казан, К. Маркс ур., 12

Искәрмәләр өчен

Для заметок